УДК 28.3
ББК 86.38

ISBN 000000000000

Раббысының кичерүендә мохтаҗ колы,
Пәйгамбәребез мәчете каршындагы әл-Харам институтының
элеккеге профессоры
Хәйсәм ибн Мөхәммәд Сәрханның кулъязмасы

http://www.alsarhaan.com
Аллаһ аны, аның әти-әнисен һәм әлеге китапны нәшер итүдә ярдәм иткән һәркемне кичерсен.
Беренче басма
Барлык нәшрият хокукларына барча мөселманнар да ия.
Islamtorrent@gmail.com

ISBN 000000000000

УДК 28.3
ББК 86.38

# КЕРЕШ СҮЗ

# КЕРЕШ СҮЗ

**Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһ исеме белән башлыйм**

Барча мактау Аллаһка, без Аны гына мактыйбыз, бары Аннан гына ярдәм һәм кичерүен сорыйбыз. Җаннарыбызның әшәкелегеннән һәм начар гамәлләрдән без Аллаһка сыенабыз. Аллаһ туры юлга күндергән бәндәне һичкем ялгыш юлга кертә алмас. Ә кемне ялгыштырса, аны һичкем туры юлга күндерә алмас. Һич тиңдәше булмаган Аллаһтан башка табынырга лаеклы башка һичнинди зат юк һәм Мөхәммәд Аның колы һәм рәсүле, дип шәһәдәт бирәмен. **«Әй иман китергән бәндәләр! Аллаһтан чын курку белән куркыгыз һәм бары тик мөселманнар булып кына үлегез!» «Әй кешеләр! Сезне бер кешедән яралткан, аның парын яралткан һәм алардан туган бик күп ирләрне һәм хатыннарны җир буенча тараткан Раббыгыздан куркыгыз! Аның исеме белән бер-берегездән сораган Аллаһтан куркыгыз, һәм туганлык җепләрен өзүдән куркыгыз. Хакыйкатьтә Аллаһ сезне күзәтә!» «Әй сез, иман китергән бәндәләр! Аллаһтан куркыгыз һәм дөресен генә сөйләгез! Ул сезнең өчен эшләрегезне төзәтер һәм сезнең гөнаһларыгызны кичерер. Ә кем Аллаһка һәм Аның Илчесенә буйсынса, ул бөек уңышка ирешер!»**

Шуның соңында:

Әлеге «Мәнхаҗәс-саликин уә таудых әл-фикх фи-д-дин» исемле китап хокук [фикх] буенча иң тулы аңлатмаларның берсе, ул, каршылыкларга мөрәҗәгать итмичә, дөресрәк дип табылган фикх мәсьәләләрен үз эченә ала. Шулай ук әлеге китабында автор үзе өстен күргән мәсьәләләрне Коръән һәм Сөннәттән алынган дәлилләр белән дәлилләргә омтыла. Һәм әлеге эшне ул бик яхшы булдырып чыккан, Аллаһ Тәгалә аны кичерсен. Бер төркем галимнәр әлеге хезмәтне игътибар белән өйрәнергә тәкъдим итә. Шуңа күрә гыйлем эстәү юлына әле яңа гына басканнар өчен без ул китапның яңа вариантын чыгарырга карар кылдык, әлеге китапта каралачак мәсьәләләр аерым темаларга бүленгән. Әлеге китапны язу методы шуннан гыйбарәт:

— Тиешле игътибарны биреп текстны бирү;

— Текстны зәңгәр төстәге таблицага урнаштыру;

— Комментарий бирүченең өстәмәләрен текст эчендә кара төстәге шакмаклы җәяләрдә, ә кырыйларын зәңгәр төс белән бирү;

— Автор тарафыннан, Аллаһ аны кичерсен, өстәмә аңлатмалар бирү;

Аллаһ Тәгаләдән әлеге хезмәтебезне кабул итүен, Аллаһ ризалыгы өчен ихластан булуын һәм һәр укучы өчен файдалы булуын сорыйбыз, чөнки ул — Ишетүче, Белүче.

# АВТОРНЫҢ КЕРЕШ СҮЗЕ

## АВТОРНЫҢ КЕРЕШ СҮЗЕ

**Рәхимле һәм Рәхмәтле Аллаһ исеме белән башлыйм**
**Аллаһтан ярдәм сорыйм**

Барча мактау Аллаһка, без Аны гына мактыйбыз, бары Аннан гына ярдәм һәм кичерүен сорыйбыз. Җаннарыбызның әшәкелегеннән һәм начар гамәлләрдән без Аллаһка сыенабыз. Аллаһ туры юлга күндергән бәндәне һичкем ялгыш юлга кертә алмас. Ә кемне ялгыштырса, аны һичкем туры юлга күндерә алмас. Һич тиңдәше булмаган Аллаһтан башка табынырга лаеклы башка һичнинди зат юк һәм Мөхәммәд Аның колы һәм рәсүле, дип шәһәдәт бирәмен.

Шуның соңында:

Бу фикх буенча кыскартылган китап, әлеге хезмәттә мин сорау һәм дәлилләрне берләштердем, аларның иң мөһим һәм файдалыларын гына китердем. Әлеге темалар бик мөһим һәм мин бик еш Коръән һәм Сөннәттән текстлар китерү белән генә чикләндем, чөнки фикх мәсьәләләре ачык һәм анык, җиңел истә кала һәм аңлаешлы. Һәм менә ни өчен:

— **Белем** — ул хакыйкатьне дәлилләр аша табу.

— **Фикх** — ул шәригать кануннарын Коръән һәм Сөннәттә булган дәлилләр, галимнәрнең бердәм уртак бер фикере [иджмагъ] һәм аналогия буенча дөрес чагыштырулар [кыяс] аркылы танып белү.

Шулай ук мин, китапның артык озын булуыннан куркып, гомум билгеле дәлилләрне китерү белән генә чикләндем. Ә фикер каршылыклары булган мәсьәләләр очраган вакытта, шәригать дәлиләреннән чыгып, үзем кайсы фикерне өстен дип санадым, шул фикерне язу белән чикләндем.

| **Мөһим сорау**: ни өчен без фикхны өйрәнәбез?<br>**Җавап**: гыйбадәтебез ошбу ике сыйфаттан башка кабул ителмәячәк: | |
|---|---|
| **Эчкерсезлек**<br>Риясыз һәм тиңдәш кылмыйча Бер Аллаһка якынаю теләге. Тәүхид фәнен дә без шул сәбәпле өйрәнәбез. | **Иярү**<br>Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ алып килгән шәригатькә иярү. Фикхны без шул сәбәпле өйрәнәбез. |

Шәригать кануннары ике төргә бүленә:

— Әл-Әхкам [әт-таклифия (җаваплылык йөкләтелү критерие буенча карарлар )], алар бишәү:

| Карар | Билгеләмәсе | Чикләре | Башкача атамасы |
|---|---|---|---|
| 1. Вәҗиб (үтәлергә мәҗбүри) | Үтәлгән өчен лаеклы әҗер, ә үтәлмәгән өчен лаеклы җәза булачак гамәл. | Кануннарны язучы (Аллаһ) тарафыннан үтәлергә мәҗбүри дип билгеләнгән гамәлләр. | Фарыз, фарида, хәтм, ләзим. |
| 2. Харам (тыелган) | Вәҗиб [үтәлергә мәҗбүринең] капма-каршысы | Кануннарны язучы тарафыннан калдыру, үтәмәү мәҗбүри булып тыелган гамәлләр. | Мөхәррам, мәмнугъ. |
| 3. Мәкрух (үтәлмәсә яхшырак) | Үтәлмәгән өчен әҗер-савап билгеләнгән гамәлләр, ләкин үтәгән очракта кеше җәзага тартылмаячак. | Кануннарны язучы бу гамәлләрне калдырырга кушкан, ләкин мәҗбүри түгел. | Мубаггаз кабул ителмәгән). |
| 4. Мәснун (кирәкле) | Мәкрухның [үтәлмәсә яхшырак] капма-каршысы. | Кануннарны чыгаручы үтәргә кушкан, ләкин үтәү мәҗбүри булмаган гамәлләр. | Сөннәт, мөстәхәбб, нәфел, мәндуб, рагибә, фәдылә. |
| 5. Мөбәх (рөхсәт ителгән) | Үтәлгән өчен дә, үтәлмәгән өчен дә бер нәрсә дә каралмаган. | Аңа карата боеру да, тыю да килмәгән гамәлләр. | Хәләл, җәиз. |

— Әл-Әхкәм әл-уадгийа (хокукый карарларның үтәлешен характерлаучы шәригать тарафыннан билгеләп куелган критерийлар һәм сыйфатлар), аларга түбәндәгеләр керә:

| Сахих (ышанычлы, дөрес) | Фәсид (дөрес булмаган, яраксыз) | Сәбәб (сәбәп) | Шарт (шарт) | Мәнигъ (киртә) |
|---|---|---|---|---|

Мөкәлләф [гакыллы, бәләгатькә ирешкән кеше] гыйбадәттә, кешеләр белән мөнәсәбәтләрдә һәм башкаларда кирәкле булган бар нәрсәне дә өйрәнергә тиеш.

Аллаһның рәсүле ﷺ әйтте: «***Кемгә Аллаһ яхшылыклар теле, шуңа Ул динне аңлауны бирә***» (Киңәшелгән хәдис).

**Китапның эчтәлеге**

| Беренче: гыйбадәт | Икенче: кешеләр белән мөнәсәбәт |
|---|---|
| Гыйбадәт беренче булып өйрәнелә, чөнки ул бар нәрсәдән әһәмиятлерәк. Бу исламның әркәннәре һәм шуннан соң җиһад (көрәш).<br>**Бүлекләрнең исемнәре:**<br>— Пакьлану китабы<br>— Намаз китабы<br>— Җеназа китабы<br>— Зәкәт китабы<br>— Ураза китабы<br>— Хаҗ китабы<br>— Көрәш китабы (автор әлеге бүлекне, китапны кыскарту ниятеннән төшереп калдырды). | Кешеләр белән мөнәсәбәт тәртибе мөкәлләфкә бик кирәк, шуңа күрә әлеге бүлектәге китаплар тәртибе дә кирәклелек күзлегеннән чыгып бирелде. Кешеләргә ризык, эчемлекләр кирәк, алар аны сату-алу мөнәсәбәтләре аша ала. Тамак туйгач, никях турында да уйларга мөмкин, никах булган җирдә аерылышулар да була, аның да үзенең кагыйдәләре. Кемнеңдер күңелен тәкәбберлек хисләре биләп алырга мөмкин, аларны бетерү мәслихәт. Шулай ук үч алу, чикләмәләр һәм хөкем эше хакында да белү тиештер.<br>**Бүлекләрнең исемнәре:**<br>— Финанс мөнәсәбәтләр китабы<br>— Милек китабы<br>— Никах китабы<br>— Никах бүләге китабы<br>— Талак китабы<br>— Гидда һәм истибра (көтү чоры) китабы<br>— Ризык китабы<br>— Җинаятьләр китабы<br>— Җәзалар китабы<br>— Хөкем эше, дәгъва, дәлил һәм шаһитлек китабы. |

| Ни өчен фикх галимнәре үз китапларын «Тәһарәт китабы»ннан башлыйлар? | | | |
|---|---|---|---|
| Чөнки бу бүлек исламның беренче әркәне белән бәйләнгән, шуңа күрә эчке пакьлануны тышкы пакьлануга караганда иртәрәк башларга кирәк | Чөнки «бушану» «матурлык»тан алданрак була. | Чөнки Пәйгамбәребезгә ﷺ эчкерсез иярүдән башка гыйбадәт кабул булмаячак. | Чөнки ул намазга керешкәнче башкарыла торган бер шарт булып тора. |

| Фикх галимнәре үз китапларын нинди тема белән тәмамлыйлар? | |
|---|---|
| **Икърар бүлеге белән** (һәм бу иң яхшысы), әлеге бүлектә соңгы сулышны алганда тәүхид сүзләре әйтү теләге хакында әйтелә | **Колны ирекккә җибәрү бүлеге белән** Әлеге бүлектә җәһәннәм утыннан котылу теләге чагыла |

| Гомуми кагыйдәләргә нигезләнеп, гыйлем эстәүчеләргә җиңеллек китерү йөзеннән, китап ошбу тәртиптә төзелде: | | | |
|---|---|---|---|
| Китап өлешләргә бүленде | Өлешләр бүлекләргә бүленде | Бүлекләр үз чиратында темаларга бүленде | Темалар исә төрле мәсьәләләрдән тора. |

# ИКЕ ШӘҺӘДӘТ БҮЛЕГЕ

## [ИКЕ ШӘҺӘДӘТ] БҮЛЕГЕ

### Ике шәһәдәт бүлеге

Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Ислам биш әркәнгә нигезләнә — Аллаһтан башка гыйбадәткә лаелы зат юк һәм Мөхәммәд аның илчесе, дип шәһәдәт әйтү, намаз уку, зәкәт түләү, Хаҗ кылу, Рамазан аенда ураза тоту»*** (Килешенгән хәдис).

Аллаһтан башка гыйбадәткә лаеклы башка зат юк, дип шәһәдәт әйтү — ул колның Аллаһтан башка беркем дә гыйбадәткә лаек түгел һәм Аның тиңнәре юк, дип инануы.

Бу инану колны түбәндәге гамәлләрне кылырга мәҗбүр итә: эчкерсез рәвештә динебезне Раббыбыз Аллаһка багышлау; барлык эчке һәм тышкы гыйбадәтне Аңа юнәлтү; һәм дин мәсьәләләрендә Аңа бер нәрсәне дә тиңдәш кылмау.

Барлык пәйгамбәрләр алып килгән диннәрнең нигезе әнә шундый булды. Аллаһ Тәгалә бу хакта менә нәрсә диде: **«Без сиңа кадәр бер генә пәйгамбәрне дә: «Миннән башка табынырга лаеклы зат юк. Миңа гыйбадәт кылыгыз!» кәлимәсен төшендермичә җибәрмәдек».**

Мөхәммәд ﷺ Аллаһның илчесе дип шәһәдәт әйтү ул колның Мөхәммәднең ﷺ Аллаһ тарафыннан барлык кешелек дөньясына һәм җеннәргә шатлыклы хәбәр һәм вәгазьләүче итеп җибәрелүенә инануы. Ул кешеләрне һәм җеннәрне Аның сүзләренә инанырга, тәүхидкә, бер Аллаһка табынырга, Ул тыйганнардан тыелып, кушканнарын үтәп яшәргә чакырды; ул кешеләргә Аллаһка инанудан һәм Аңа табынудан башка бу дөньяда да, киләчәк дөньяда да бәхет-сәгадәткә ирешеп булмаячагын аңлатты; үзенә, баласына һәм башка кешеләргә караганда да Аллаһны күбрәк яратырга вәгъдә бирде; Аллаһ Үзенең пәйгамбәренә ﷺ илче булуын белгертүче төрле могҗизалар белән ярдәм итте; Ул аңа камил белем, югары дәрәҗәдәге әхлак, туры юл, рәхим-шәфкать, хакыйкать, шулай ук Ислам дине алып килгән дини һәм дөньяви мәнфәгатьләр белән яньип-көю сәләтен бүләк итте.

Ә Аның могҗизаларының иң бөеге Изге Коръән булды, әлеге Китапта Аның хак сүзе, хакыйкый боерулар һәм тыюлар.

Ә Аллаһ бу хакта яхшырак белә.

| Диннең өч баскычы | | |
|---|---|---|
| **1. Ислам** | **2. Иман (инану)** | **3. Ихсан (ихласлылык)** |
| Аллаһның берлеген тану, гыйбадәт аркылы Аңа буйсыну, шулай ук ширектән һәм ширек кылучылардан ерак булу. Биш әркәне, баганасы бар. | Алты әркәне, баганасы бар: Аллаһка, Аның фәрештәләренә, Китапларына, Пәйгамбәрләренә, Соңгы көнгә һәм яхшысы да, яманы да Аллаһтан булуына. | Бер әркәне, баганасы бар: Аллаһка Аны күргән кебек гыйбадәт кылу. Син Аны күрмәсәң дә, Ул сине күрә. |

# ТӘҺӘРӘТ КИТАБЫ

# ТӘҺӘРӘТ КИТАБЫ

<table>
<tr><th colspan="6">Пакьлану төрләре</th></tr>
<tr><td rowspan="3">Рухи пакьлану — ширектән, дингә яңалык кертүдән (бидгать) һәм гөнаһлардан пакьлану.</td><td colspan="5">Физик яктан пакьлану:</td></tr>
<tr><td colspan="2">Яманнан чистарыну</td><td colspan="3">Пычрактан чистарыну</td></tr>
<tr><td>Олы (госел коену)</td><td>Кече (тәһәрәт)</td><td>Тән</td><td>Кием</td><td>Урын</td></tr>
<tr><td>Пычрану</td><td colspan="5">Намаз укуга һәм башка төр гыйбадәтләргә киртә булып торучы тән пычрануы, әлеге гыйбадәтләрне кылу өчен госел һәм тәһәрәт шарт булып тора, әйтик, Кәгъбә тирәли тәваф кылу.</td></tr>
<tr><td>Нәҗес нәрсәләр</td><td colspan="5">Чистарыну тиешле булган теләсә-нинди пычрак әйбер. Мәсәлән, кеше бәвеле, тәрәте һәм башкалар.</td></tr>
</table>

<table>
<tr><th colspan="3">Чистарыну башкарыла:</th></tr>
<tr><td colspan="2">Су ярдәмендә (төп чара), ул ике төрле була:</td><td rowspan="2">Җир ярдәмендә (икенче чара, тәяммүм вакытында кулланыла).<br>Су булмаган очракларда яки аны куллану мөмкин булмаган вакытларда җир ярдәмендә кече, шулай ук олы пычракларны да бетерергә мөмкин.</td></tr>
<tr><td>1. Чиста һәм чистарта торган, ул госел һәм тәһәрәт өчен яраклы</td><td>2. Пычрак, госел һәм тәһәрәт өчен яраклы түгел</td></tr>
</table>

<table>
<tr><td colspan="2">Кече яки олы йомышны башкарганнан соң Шәригать ике гамәл башкаруны канунлаштырган, әмма аның берсен башкару белән дә чикләнергә мөмкин:</td></tr>
<tr><td>1.Истинҗа кылу — су ярдәмендә генә юыну</td><td>2. Сөртенү — өч таш яки бәвел, тәрәт юлларын чистарта алырдай шуңа охшаш башка каты предметлар белән чистарыну, сөртенү.</td></tr>
</table>

| **Нәҗес** (пычрак) — чистарыну тиеш булган теләсә-нинди пычрак әйбер, аннан чистарыну ысуллары өч төргә бүленә: | | |
|---|---|---|
| Катлаулы: эт нәҗесе. Пәйгамбәребез ﷺ эт ялаган савытны җиде тапкыр юарга, ә беренче тапкырында хәтта җир белән юарга боерды. | Җиңел: бу нәҗес киемне юмыйча һәм сыкмыйча су бөркү юлы белән генә бетерелә. Бу гел күкрәк сөте белән генә туенучы кечкенә малайның бәвеленә, спермага кагыла. Сперма үзе чиста, әмма Пәйгамбәребез ﷺ аңа, әгәр ул юеш булса, су бөрки иде, әгәр ул кипкән булса, ышкып бетерә иде. | Уртача: бу нәҗес киемне юу һәм сыгу юлы белән бетерелә. Бу «катлаулы» һәм «җиңел» категорияләренә кермәүче теләсә-кайсы нәҗескә кагыла, мәсәлән, ир-ат яки хатын-кыз бәвеле һәм башкалар. |

| **Кешенең табигатенә кагылышлы эшләргә кирәк булган 10 гамәл:** |
|---|
| **1.Сөннәткә утырту** — пычрак җыелуны булдырмау һәм бәвел калдыкларыннан тулаем чистарынып бетү өчен ир-ат җенес әгъзасының кырый тиресен кисеп алу. Бу гамәл ир-атларга мәҗбүри, ә хатын-кызларга, ихтыяҗ булганда, кирәкле булып тора. |
| **2.Мыекларны кыру** |
| **3.Тырнакларны кисү**, чөнки тырнакларны үстерү алар астында пычрак туплануга китерә. |
| **4.Култык астындагы йоннарны йолку, кыру һәм башкалар,** чөнки бу гамәлләрне башкару тәнгә чисталык бирә, начар ислардән арындыра. |
| **5.Җенес әгъзасы тирәли үсүче йоннарны кыру.** Аларны кыру юлы белән генә түгел, ә депиляция чаралары белән дә бетерергә мөмкин.<br>Әнәс, Аллаһ аннан риза булсын, сүзләреннән китерелә, ул әйтте: ***«Безнең өчен мыекларны кыру, тырнакларны кисү, култык астындагы һәм җенес әгъзасы тирәсендәге йоннарны йолку өчен, әлеге гамәлләрне башкару кырык төннән дә озаккарак сузылмасын өчен, бер вакыт билгеләнде. Мөслим.***<br>**6.Сакалны үстерү.** Шәригатьтә сакал мәсьәләсе болайрак: аны үстерү мәҗбүри, ә кыру — иң авыр гөнаһларның берсе. |

| |
|---|
| **7.Сивак куллан**у — ул тешләрне чистарту өчен Арак агачының ботагын куллану. Шәригатьтә сивак куллану теләсә-кайсы вакытта да тиешле, зарури гамәл булып тора. Тәһәрәт, госел коенганда, намаз алдыннан, йортка кергәндә, Коръән укыганда, йокыдан торгач һәм авыздан әшәке ис килгәндә аны куллануның зарурлыгы арта, шулай ук вафат булган кешене юган вакытта да тешләрен сивак ярдәмендә чистарту тиешле. |
| **8.Борынны юу һәм тамакны чайкату.** |
| **9.Бармак буыннарын юу.** |
| **10.Истинҗа кылу,** чөнки әлеге гамәлгә Гайшә, Аллаһ аннан риза булсын, хәдисе күрсәтә, әлеге хәдисне Мөслим китерә. |

## ПАКЬЛАНУ ТӨРЛӘРЕ

Намазга керешкәнче кайбер шартларны үтәргә кирәк. Тәһарәт алу — әлеге шартларның берсе. ***Пәйгамбәребез ﷺ бу хакта болай диде: «Аллаһ тәһарәтсез башкарылган намазны кабул итми».*** Килешенгән хәдис. Намазы кабул булмас шул кешенең, кем чистарынмас:

| **1. Зур һәм кече нәҗестән** | **2. Пычрактан** |
|---|---|
| **Беренче төр пакьлану**: су белән читарыну (төп чара). | **Икенче төр пакьлану**: җир белән чистарыну (икенчел чара). |

**Су төрләре**: дөреслектә су бары тик ике генә төрле була: чиста — чистартучы һәм пычрак.

| | |
|---|---|
| 1.Күктән ява яки җир астыннан чыга торган һәртөрле су чиста була һәм һәртөрле пычрактан һәм нәҗестән чистарта, хәтта аның төсе, тәме һәм исе нинди дә булса чиста нәрсә белән кушылып үзгәрсә дә. Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: «Су — чиста, һәм аны бернәрсә дә пычрата алмый». Хәдис дөрес һәм «Сунан» китапларының барысында да китерелә. | 2.Әгәр пычрак, нәҗес нәрсәләр эләгеп, суның тәме, төсе һәм исе үзгәрә икән, бу су пычрак була һәм аны кулланудан сакланырга кирәк. |

Нигездә барлык нәрсәләр дә чиста һәм кулланырга яраклы, әгәр:

| | |
|---|---|
| 1.Мөселман кешесе суның, киемнең, урынның һәм башкаларның чиста булуында шикләнсә, алар чиста була. | 2.Мөселман кешесе чиста хәлəттә булуында шикләнмәсә яки, киресенчә, пычранганлыгында шикләнсә, ул ритуаль чисталык халәтендә була. |

Чөнки Пәйгамбәребез ﷺ газлары бүленеп чыккан кебек тоелган кеше хакында болай диде: ***«Тавышын ишетмичә яки исен сизмичә торып мәчеттән чыгып китмәсен».*** Килешенгән хәдис.

Моны фикх кагыйдәсе дә (ә аның белән барлык галимнәр дә килешә) дәлилли: «Ныклы ышанычны шикләнү юкка чыгармый»,— бу кагыйдә ныклы ышанычны бары тик ныклы ышаныч кына юкка чыгара ала, һәм аннан да кечерәк булган шикләнү юкка чыгара алмый дигәнне аңлата.

Аллаһның илчесе ﷺ диңгез суы хакында болай диде: ***«Аның суы чиста, ә андагы үлгән хайваннар рөхсәт ителгән». Бохари.***

## САВЫТ-САБА

**Ни сәбәпле савыт-саба Тәһарәт китабында телгә алына?**

Су — ага торган байлык, аны бары тик савыт-сабага салып кына сакларга мөмкин. Шул сәбәпле савыт-саба темасы су темасыннан соң китерелә. Билгеле ки: әгәр теге яки бу әйбернең ике аналогы булса, аның беренчесе турында сөйләгәндә икенчесен дә телгә алу яхшырак булыр, әгәр киресенчә булса, файдасы булмас.

**Алтын һәм көмеш яки бу ике металл кушылып эшләнгән савыт-сабадан тыш, теләсә-нинди савыт-саба рөхсәт ителгән. Кирәк булганда бераз көмеш кушылган савыт-саба бу кагыйдәдән чыгарма булып тора.** ***[Гасым әйтте: «Мин Әнәс ибн Мәликтә Пәйгамбәрнең ватылган савытын күрдем, аның өлешләре көмеш чыбык белән бәйләнгән иде»].***

**Савыт-сабада көмеш кулланырга рөхсәт ителгән шартлар:**

| **1.Ямау өчен:** савыт-сабадагы ярыкларны ямау өчен көмеш чыбык куллану | **2.Аз күләмдә** | **3.Көмеш** | **4.Кирәк чакта** |
|---|---|---|---|

Чөнки Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«...алтын һәм көмеш савытлардан эчмәгез, алтын һәм көмеш табаклардан ашамагыз, чөнки, дөреслектә, болар барысы да алар өчен бу дөньяда, ә сезнең өчен киләчәк тормышта хәзерләнгән».*** Килешенгән хәдис.

**Имансыз кешеләрнең савыт-сабаларына кагылышлы хөкемнәр:**

| | | |
|---|---|---|
| Чиста буларак билгеле булган савыт-саба чиста була һәм аны кулланырга ярый. | Пычрак буларак билгеле булган савыт-саба чиста булмый һәм аны куллану алдыннан юарга кирәк. | Шик тудырган савыт-саба. Бу очракта кагыйдәләргә таянырга һәм аны чиста дип санарга кирәк. |

**Имансыз кешеләрнең кигән киемнәренә кагылышлы хөкемнәр:**

| нигездә мондый киемнәр рөхсәт ителә, әмма түбәндәгеләрне ачыклап киту кирәк | |
|---|---|
| Чисталыкка артык игътибар бирмәгәннәрнең киемнәрен, мәсәлән, христианнарның, киемнәрен кимәсәң яхшырак. | Үзенең чисталыгы белән билгеле булган кешеләрнең киемнәре безгә рөхсәт ителгән. |

**Дупланган тирегә кагылышлы хөкемнәр:**

| | |
|---|---|
| Тирене барлык зыянлы, пычрак нәрсәләрдән теләсә-нинди чистарткыч ярдәмендә чистару, мәсәлән, тоз һәм башкалар. | Итен ризыкка кулланырга яраклы теләсә-кайсы үле хайванның тиресе, дупланганнан соң чистага әйләнә. |

## ИСТИНҖА ҺӘМ БӘДРӘФКӘ ЙӨРҮ КАГЫЙДӘЛӘРЕ

**Бәдрәфкә кергәндә:**

| | |
|---|---|
| 1.Сул аяктан керергә тиешле | 2.Ошбу сүзләрне әйтергә кирәк: بسم الله اللّٰهُمَّ إني أعوذ بك من الخبث والخبائث *Мәгънәсе: Аллаһ исеме белән! Я Аллаһ, чынлыкта, мин явызлыктан һәм начар гамәлләрдән Синең ярдәмеңә сыенам.* |

**Бәдрәфтән чыкканда:**

| | |
|---|---|
| 1.Уң аяктан чыгарга тиешле | 2.Ошбу сүзләрне әйтергә кирәк: غفرانك، الحمد لله الذي أذهب عني الأذى وعافاني Мәгънәсе: *«Гафу кыл! Мине газаплаучы нәрсәләрдән арындырганы һәм минем халәтемне җиңеләйткәне өчен Аллаһка барча мактаулар».* |

| |
|---|
| **Искәрмә:** «Әл-хәмду ли-Лләһ» сүзләре көчсез хәдистә китерелә, һәм шуңа күрә аларны әйтү Шәригатьтә канунлаштырылмаган, Аллаһ Тәгалә бу хакта яхшырак белә. |
| Бәдрәфтә йомышны башкарганда сул аякка таянып, ә уң аякны турайтып утырырга кирәк. Чит күзләрдән дивар яки башка нәрсә артына яшеренү, ә йомыш ачык җирдә башкарылса, кешеләрдән ераграк киту мәҗбүри. |
| Җиргә таба чүгәләгәнче киемне салмаска кирәк. |

**Йомышны башкарырга ярамый:**

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1.Юл өстендә | 2.Кешеләр утырган җирдә. | 3.Җимеш китерүче агачлар төбенә. | 4.Кешеләргә төрле уңайсызлыклар тудырырга мөмкин булган урыннарда | 5.Акмый торган суга. |

| |
|---|
| Йомышны башкарган вакытта кыйбла тарафына арка яки йөз белән борылырга ярамый, бу хакта Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Сезнең берәрегез кече яки зур йомышын башкарырга теләсә, кыйбла тарафына аркасы яки йөзе белән борылмасын. (Мәдинәнең) көнчыгышына яки кынбатышына таба борылсын».*** Килешенгән хәдис. |
| Йомышын башкарган кешегә түбәндәгеләр рөхсәт ителми:<br>— Җенес әгъзасына уң кул белән кагылу яки истинҗа кылу.<br>— Бәдрәфкә Аллаһның исеме язылган берәр предметны алып керү.<br>Ярамас, кирәкмәс эш: йомышны башкарган урында кирәгеннән артык тору. |

**Йомышны башкарганнан соң:**

| | |
|---|---|
| 1.Өч таш яки шуларга охшаш чистарта торган предметлар белән сөртенергә кирәк. | 2.Шуннан соң су белән юынырга, истинҗа кылырга кирәк. |
| Әлеге гамәлләрнең икесенең берсен үтәү белән дә чикләнергә мөмкин. | |

**Сөртенергә ярамый:**

| | |
|---|---|
| 1.Тирес яки сөякләр белән, чөнки пәйгамбәребез ﷺ моны тыйды. | 2.Кагылгысыз булган теләсә-кайсы әйбер белән. |

**Сөртенү шартлары:**

| | | |
|---|---|---|
| 1.Сөртенү сан ягыннан өч тапкыр яки аннан да күбрәк булырга мөмкин. Бер үк төрле өслек белән әллә ничә мәртәбә сөртенергә ярамый. | 2.Сөртенергә дигән предмет чистарта торган булырга тиеш. Бу таш яки салфетканың чираттагы сөртенүдән соң чиста булып калуы белән билгеләнә. | 3.Пычрак яки кагылгысыз булган нәрсәләр, мәсәлән, ризык, сөяк яки тирес белән сөртенү ярамый. |

**Басып кече йомышны башкару хөкемнәре.**

| Түбәндәге шартлар булганда рөхсәт ителә: | |
|---|---|
| 1.Бәвелнең тән һәм киемгә эләгүеннән саклану мөмкинлеге булганда | 2.Гаурәт җирләрнең ачылуыннан саклану мөмкинлеге булган очракта. |

Хузайфа хәдисендә, Аллаһ аннан риза булсын, болай диелә: ***«(Бервакыт) Аллаһның илчесе кешеләр чүп ташлый торган урынга барды һәм кече йомышын басып башкарды».*** Килешенгән хәдис.

**Телефон һәм йомышны башкаруга кагылышлы искәрмәләр:**

—Звонок тавышына Аллаһны зикер итү: аятьләр, азан якидога сүзләрен куймаска, чөнки телефон йомышны башкарган вакытта шалтырарга мөмкин.

—Йомышны башкарган вакытта телефон кулланмаска, чөнки бу бәдрәфтә кирәгеннән артыгын утыруга китерә, ә бу кирәкмәс эш.

—Телефонда Аллаһны зикер итү сүзләре язылган булырга тиеш түгел, чөнки бу да Аллаһны искә алу сүзләре язылган предметны бәдрәфкә алып керүгә тиң. Әгәр Аллаһны зикер итү сүзләре телефон экранында икән, аны бәдрәфкә алып керергә ярамый, әгәр зикер сүзләре ниндидер бер папкада сакланса, телефонны бәдрәфкә алып керергә ярый, ләкин, әгәр кеше аны югалтудан курыкмаса, тышкы якта калдыру хәерлерәк.

## [ПЫЧРАКНЫ ЧИСТАРТУ ҺӘМ ПЫЧРАК ӘЙБЕРЛӘР]

Тәннән, киемнән, нинди дә булса урыннан һәм башкадан пычракны юган вакытта әлеге пычрак булган урынны гына юу да җитә.

Аллаһ Тәгалә барлык төр пыракны да билгеле бер тапкыр юуны шарт итеп куймады. Ләкин эттән эләккән пычракны җиде тапкыр юарга боерды, ә беренче тапкырында исә, [килешенгән хәдистә әйтелгәнчә], җир кулланып юарга кирәк.

**Нәҗес, пычрак нәрсәләр:**

<table>
<tr><td>1.Кеше бәвеле</td><td>2.Тәрәт</td><td>3. Кан, әмма әгәр аның күләме аз булса, ул чиста буларак кабул ителә. Шулай ук итен ризык итеп кулланырга яраклы малның каны да пычрак нәрсәләр рәтенә керә, әмма итнең үзендә һәм кан тамырларында калган кан чиста санала.</td></tr>
<tr><td colspan="2">4.Эякуляция — хисләнү һәм җенси акт вакытында бүленеп чыгучы үтә күренмәле сыеклык.</td><td>5.Кече йомышны башкарганнан соң ук бүленеп чыгучы куе сыеклык.</td></tr>
<tr><td colspan="3">Эякуляция яки кече йомышны башкарганнан соң бүлендеге чыккан кеше истинҗа кылырга һәм тәһәрәт алырга тиеш, госел коену мәҗбүри түгел.</td></tr>
<tr><td colspan="3">Пычрак, нәҗес әйберләргә шулай ук түбәндәгеләр керә:</td></tr>
<tr><td>6.Итен ризык итеп куллану тыелган теләсә-нинди хайванның бәвеле һәм тәрәте.</td><td>7.Барлык ерткыч хайваннар да пычрак булалар.</td><td>8.Барлык төр үлекләр пычрак, кеше гәүдәсеннән, каннары акмаган бөҗәкләр, балыклар һәм саранчадан тыш, алар үлгәннән соң да чиста булып кала.</td></tr>
</table>

**Аллаһ Тәгалә әйтте: «Сезгә үлгән хайваннар һәм кан тыела...»**

— Башка төр пычрак, аз күләмдә булса, гафу ителә.

— Аз күләмдә булса, гафу ителә торган нәҗесләргә, аннан сакланырга мөмкин булмаганлыктан, бәвелне тота алмау (энурез) авыруыннан интегүче кешенең аз күләмдәге бәвеле керә.

— Намаз вакытында яки тәһарәт алгач, бәвел бүленеп чыктымы яисә юкмы икән, дип шикләнгән кеше шуны белергә тиеш: мондый уйлар шайтаннан булырга яки бернинди нигезсез гади шикләнү генә булырга мөмкиннәр. Бу хакта уйларга кирәкми, мондый уйлардан качып, Аллаһ Тәгаләнең саклавына сыенырга кирәк, Ул мондый коткылардан аралар, ин шәә Аллаһ.

Пәйгамбәребез ﷺ әйткән: ***«Иманлы кеше бер вакытта да пычрак булмас, исән вакытында да, вафат булгач та».*** [Даракутни, ләкин аның нигезе «Сахихайн»да килә].

Шулай ук ул әйткән: ***«Безгә ризык итеп ике төрле үлгән хайван һәм ике төрле кан кулланырга рөхсәт ителде. Ике төрле үлгән хайванга килгәндә, ул балык һәм саранча, ә ике төрле кан турында әйткәндә, ул бавыр һәм талак (селезенка)».*** Әхмәд һәм ибн Мәджә.

| | |
|---|---|
| **1.Итләрен ризыкка кулланырга рөхсәт ителгән хайваннарның бәвел һәм экскрементлары чиста булып санала.** | **2.Кешенең мәние дә шулай ук чиста. Пәйгамбәребез ﷺ юеш сперманы су белән юа иде, ә кипкәнне уа иде.** |

Киемгә әнинең күкрәк сөте белән генә тукланучы кечкенә малайның бәвеле эләккән очракта, аны су белән бөркеп алу да җитә, бу хакта Пәйгамбәребез ﷺ хәбәр итте: ***«Киемгә кыз баланың бәвеле эләксә, юарга кирәк, ә ир баланың бәвеле эләксә, аңа су бөркеп алу да җитә».*** Әбу Давыд һәм ән-Нәсаи.

Әгәр пычраклары чистарса, теге яки бу урын чиста булып санала, ә пычракның исе һәм төсе калудан зыяны юк, чөнки Пәйгамбәр ﷺ күрем каны хакында Хауләгә болай дигән: ***«Аны су белән юу җитә, ә юганнан соң калган эзләре сиңа һич зыян салмас».*** [Әбу Давыд һәм Әхмәд].

## ТӘҺӘРӘТ ШАРТЛАРЫ

<table>
<tr><th colspan="4">Тәһәрәт шартлары барысы: 10</th></tr>
<tr><td>1.Ислам</td><td>2.Гакыл</td><td>3.Эшкә сәләтле булу</td><td>4.Ният</td></tr>
<tr><td>5.Ниятне тәһәрәт ала башлаганнан алып алып бетергәнчегә кадәр уйда саклау.</td><td colspan="2">6.Дөя ите ашыйашый яки кече йомышны башкара-башкара тәһәрәт алырга ярамый. Башка әлеге гамәлләрне эшләп тәгәлләргә, бары шуннан соң гына тәһәрәт ала башларга кирәк.</td><td>7.Тәһәрәт алганчы сөртенергә яки су белән истинҗа кылырга кирәк. Тәһәрәт алу арт юлдан һава чыгарудан соң, йокыдан торганнан соң яки дөя ите ашаганнан соң башкарылса, истинҗа кылу кирәк түгел.</td></tr>
<tr><td>8.Су чиста, чистарта торган һәм рөхсәт ителгән булырга тиеш.</td><td colspan="2">9.Тирегә суны үткәрми торган бар нәрсәләрне бетерү, чистарту.</td><td>10.Һәрвакыт пычрак халәттә булучыларга намаз вакыты керү.</td></tr>
</table>

<table>
<tr><th colspan="3">Тәһәрәт алуның мәҗбүри гамәлләре барлыгы алты (шуларның дүртесе тәһәрәт турындагы аятьтә тәртип белән һәм өзлексез китерелә):</th></tr>
<tr><td colspan="2">1.Борынны һәм авызны чайкауны да кертеп, битне юу</td><td>2.Терсәкләрне дә кертеп, ике кулны юу</td></tr>
<tr><td>3.Колакларны да кертеп, юеш кул белән башны сыпыру</td><td>4.Тубыктан ике аякны юу</td><td>5.Тәһәрәт алу тәртибен саклау</td></tr>
<tr><td colspan="3">6.Тәһәрәтне өзлексез алу — тәһәрәт алганда бер гамәлдән соң икенче гамәлне башкарганчы юешләнгән урын кибәрлек озак вакыт үтәргә тиеш түгел.</td></tr>
</table>

| [Тәһарәт ул]: |
|---|
| 1.Кечкенә пычракны бетерү нияте яки намаз һәм башкалар өчен тәһарәт алу. Ният — теләсә кайсы гамәлнең, шул исәптән тәһарәтнең дә, шарты булып тора, чөнки Пәйгамбәр ﷺ болай дигән: ***«Чынлыкта, гамәлләр ниятка карап бәяләнә, һәм һәркем үз ниятенә ирешәчәк».*** Килешенгән хәдис. [Ниятнең урыны йөрәк, ә аны тел белән әйтү бидгать гамәл]. |
| 2.Шуннан соң: Бисми-Ләһ (Аллаһның исеме белән) дигән сүзләрне әйтергә. |
| 3.Шуннан соң кул чукларын өч тапкыр юарга кирәк. |
| 4.Шуннан соң өч уч су белән авыз һәм борынны чайкатырга кирәк. |
| 5.Шуннан соң өч тапкыр битне юарга кирәк. |
| 6.Кулларны терсәккә кадәр өч тапкыр юарга. |
| 7.Маңгайдан алып баш артына кадәр башны сыпырырга, кулларны янәдән сыпыру башланган урынга кире кайтарырга кирәк. Моны бер тапкыр эшләргә кирәк. |
| 8.Шуннан соң күрсәтү бармагы белән колак эчләрен, ә колакның тышкы ягын баш бармак белән юарга кирәк. |
| 9.Тубыклары белән аякларны өч тапкыр юарга кирәк. |

Бу Пәйгамбәребез ﷺ башкара торган камил тәһарәт. Телгә алынган гамәлләрдән ошбулары мәҗбүри булып тора:

| | | |
|---|---|---|
| 1.Бер тапкыр юу | 2.Аллаһ Тәгалә әлеге сүзләрдә әйткәнчә тәртипне саклау: **«Әй иман китергән бәндәләр! Намазга басканда битләрегезне һәм терсәкләрегезгә кадәр кулларыгызны юыгыз, башларыгызны сөртегез һәм тубыкка кадәр аякларыгызны юыгыз».** | 3.Тәһарәт алганда бер гамәлне икенче гамәлдән аермау, бигрәк тә бу өзлексез башкару шарт булып торган гамәлләргә кагыла. |

# КҮН ОЕКЛАРНЫ ҺӘМ БӘЙЛӘВЕЧЛӘРНЕ СЫПЫРУ (МӘСЕХ ИТҮ)

Әгәр кеше күн оеклар яки шуларга охшаш нәрсәләр кисә, тәһәрәт алган вакытта, әгәр теләсә, ул аларны сыпырырга мөмкин:

| | |
|---|---|
| 1.Өйдәге кеше тәүлек дәвамында мәсех итә ала. | 2.Сәфәргә чыккан кеше өч тәүлек дәвамында мәсех итә ала. |

**Ошбу шартлар булганда:**

<table>
<tr><td colspan="2">1.Оекларны тәһәрәтле килеш кию кирәк.</td><td>2.Оекларны бары тик тәһәрәт бозылганда гына сыпырырга мөмкин.</td></tr>
<tr><td>3.Алар чиста булырга тиеш.</td><td>4.Алар табан астының күбрәк өлешен каплап торырга тиеш.</td><td>5.Мәсех итүне билгеле бер вакыт арасында гына башкарырга мөмкин (өйдә булучыларга 24 сәгать, сәфәрдә булучыларга 72 сәгать дәвамында).</td></tr>
</table>

Пәйгамбәрнең ﷺ Әнәстән килгән бер хәдисендә болай диелә: ***«Әгәр кем дә булса тәһәрәт алып күн оеклар киеп куйса, госел таләп ителгән очраклардан тыш, салмыйча алга таба аларны сыпырырга һәм кигән килеш намаз укырга мөмкин».*** Әлеге хәдисне Хәким китергән һәм дөрес хәдис дип атаган.

Әгәр тәннең юыла торган өлеше имгәнгән булса яки өстенә дару сөртелгән ярасы булып өстеннән бәйләвеч куелса, ә аны юу сәламәтлеккә зыян салса, бу очракта авыру кеше тулаем сәламәтләнеп беткәнче, тәһәрәт алганда да, госел коенганда да бәйләвечләр өстеннән су белән сыпырырга тиеш.

**Сыпыру ысуллары:**

| | |
|---|---|
| 1.Күн оеклар: аларның тышкы ягының күбрәк өлешен сыпыру тиешле. | 2.Бәйләвеч: тулаем сыпырырга кирәк. |

| | **Күн оеклар** | **Бәйләвеч** | **Чалма/яулык** |
|---|---|---|---|
| Кием нәрсәгә киелә | Аяк | Тәннең теләсә-кайсы әгъзасы | Баш |
| Сыпыру аралыгы | Өйдә 24 сәгать Сәфәрдә 72 сәгать | Сәламәтләнгәнче | Билгеле бер вакыты юк |
| Сыпыру ысулы | Тышкы яктан сыпырырга | Тулаем сыпырырга | Башны сыпыру |
| Сыпыру вакыты | Тәһарәт алган вакытта | Тәһарәт алганда һәм госел коенганда | Тәһарәт алганда. |

## ТӘҺӘРӘТНЕ БОЗУЧЫ ГАМӘЛЛӘР

**Бу гамәлләр түбәндәгеләр:**

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1.Ал һәм арт юллардан бүлен-декләр чыгу | 2.Көчле кан агу | 3.Йокы яки башка сәбәпле аңны югалту. | 4.Ризыкка дөя итен куллану |
| 5.Хатын-кызга көчле шәһвәт белән кагылу | 6.Җенес органна-рына кагылу | 7.Вафат кешенең җәсәден юу. | 8.Диннән язу, чөнки ул барлык гамәлләрне дә юкка чыгара |

**Искәрмә: көчле кан агу, хатын-кызга кагылу, җенес органына кагылу һәм вафат кешенең җәсәден юу тәһәрәтне бозмый, дип санау дөресрәк.**

Аллаһ Тәгалә әйтте: **«...әгәр берәрегез бәдрәфтән килсә һәм әгәр хатын-кыз белән якынлык кылса».**

Шулай ук Пәйгамбәрдән ﷺ: ***«Дөя ите ашаганнан соң мин тәһәрәт алырга тиешме?» — дип сорадылар. Ул: «Әйе»,— дип җавап бирде».*** Мөслим.

Күн оеклар турында ул болай диде: ***«Сыпыруны кече яки олы йомышны эшләгәннән соң, шулай ук йокыдан торгач башкарырга кирәк».*** Тирмизи һәм Нәсаи, һәм Тирмизи аны дөрес хәдис дип атады.

## ГОСЕЛНЕ МӘҖБҮРИ ИТҮЧЕ ГАМӘЛЛӘР ГОСЕЛНЕҢ ТАСВИРЛАМАСЫ

**Госел ошбу гамәлләрдән соң мәҗбүри:**

| 1.Женси якынлык, ә ул: | | 2.Хәез яки бала туганнан соң килүче кан чыгуы | 3.Вафат булгач. Шәхид киткәннәр искәрмә булып тора | 4.Әгәр имансыз кеше Ислам динен кабул итсә. |
|---|---|---|---|---|
| А. Якынлык кылу яки башка ысул нәтиҗәсендә мәни чыгу | Б. Ир-ат һәм хатын-кыз женес әгъзаларының бер-берсенә орынуы | | | |

Аллаһ Тәгалә әйтте: **«Әгәр сез якынлык кылсагыз, чистарыныгыз».**

Ул шулай ук әйтте: **«...алар чистармыйча торып, аларга якын килмәгез. Ә алар чистарынгач, алар янына Раббыгыз кушканча килегез»,**— ягъни алар госел коенгач.

Пәйгамбәр ﷺ мәетне юганнан соң һәм Ислам динен кабул итүчеләргә госел алырга кушты.

Пәйгамбәрнең ﷺ якынлык кылганнан соң госел коену тасвирламасы.

Ул ошбу гамәлләрне кыла иде:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1.Башта женес әгъзасын юды | 2.Шуннан соң тулаем тәһарәт алды | 3.Шуннан соң өч тапкыр башына су койды һәм башын юды | 4.Шуннан соң тәненең башка өлешләренә су койды | 5.Һәм иң соңыннан башка урында аякларын юды. |

**Әлеге гамәлләрдән мәҗбүри булып тора:**

| | |
|---|---|
| 1.Бөтен тәнне юу | 2.Куе булса да, сирәк булса да чәчнең астындагы тирене юу. |

Аллаһ бу хакта яхшырак белә.

## ТӘЯММҮМ (ҖИР ЯРДӘМЕНДӘ ТӘҺӘРӘТ АЛУ)

| | |
|---|---|
| Бу чистарынуның икенче төре, ул теге яки бу сәбәпләр аркасында су куллану мөмкин булмаган очракларда су белән чистарынуны алыштыра, ягъни: | |
| 1.Су булмаганда | 2.Су куллану кешенең сәламәтлегенә зыян салырга мөмкин булган очракларда. |

**Җир суны алыштыра, әгәр**:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1.Пычрактан арыну нияте булса. | 2.«Бисми-Лләһ» (*Аллаһ исеме белән*) сүзләрен әйтсәң. | 3.Җиргә уч төпләре белән бер суксаң. | 4.Әлеге уч төпләрең белән бөтен битеңне һәм кул чукларын сөртсәң. |

**Искәрмә: җиргә аңлы рәвештә ике тапкыр сугу рөхсәт ителми дигән фикер дөрес булып санала, чөнки Пәйгамбәребезнең ﷺ сүзләрендә моңа дәлил юк. Нигездә, гыйбадәтне ничек килгән шулай, ягъни үзеңнән яңалык кертмичә һәм булган әйберне төшереп калдырмыйча башкарырга кирәк, Аллаһ бу хакта яхшырак белә.**

**Аллаһ Тәгалә әйтте: «...су тапмасагыз, чиста җиргә юнәлегез һәм шуның белән битләрегезне һәм кулларыгызны сөртегез. Аллаһ сезгә авырлык теләми, ә сезнең чиста булуыгызны тели һәм сезгә карата Үзенең шәфкатен җиренә җиткереп үтәргә тели,— бәлки сез шөкер итүчеләрдән булырсыз».**

Җәбир сүзләреннән килә, Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: «***Миңа моңарчы бер генә пәйгамбәргә дә бүләк ителмәгән биш нәрсә бүләк ителде: безне бер айлык юл аеруына карамастан, миңа ярдәм йөзеннән, дошманнарымның йөрәгенә курку салынды; гадәти җир миңа намаз уку урыны итеп һәм чистарыну ысулы итеп бирелде, шуңа күрә минем өммәтемнән булган кеше, намаз вакыты җитүгә, шул җирдә намаз укысын; миңа хәрби яулардан ганимәт малын алырга рөхсәт ителде; миңа мөселманнарны яклау хокукы бирелде; һәм әгәр моңарчы килгән пәйгамбәрләр бары үз халкына гына җибәрелгән булса, мин барча кешелеккә җибәрелдем***». Килешенгән хәдис.

**Тәһәрәте булмаган кешегә ошбу гамәлләрне эшләргә тыела:**

| | | |
|---|---|---|
| 1.Намаз укырга | 2.Кәгъбәтуллаһ тирәли тәваф кылырга | 3.Коръәнгә кагылырга |

**Госеле бозылган кешегә санап кителгән өч гамәлгә өстәп түбәндәгеләр ярамый:**

| | |
|---|---|
| 1.Коръәннән нәрсә дә булса укырга | 2.Госелсез килеш мәчеттә булырга |

**Хәез һәм нифас вакыты башланган хатын-кызга санап кителгән биш гамәлгә өстәп түбәндәгеләрне башкарырга ярамый:**

| | | |
|---|---|---|
| 3.Ураза тотарга | 4.Якынлык кылырга | 5.Аерылышырга |

Әмма бу халәтләрдә хатын-кыз Коръән укый ала һәм Кәгъбәтуллаһ тирәли саубуллашу тәвафы аның өчен мәҗбүри булудан туктый. Әгәр хатын-кыз Олы хаҗның яки Гомрәнең башка гыйбадәтләрен үтәп өлгергән булып, шуннан соң аның хәез вакыты башланып ул өйгә кайтыр вакытка кадәр дәвам итсә, бу очракта ул саубуллашу тәвафын башкармый, чөнки Ибн Габбастан килгән хәдистә әйтелгәнчә, Аллаһ алардан риза булсын, болай диелә: ***«Кешеләргә Мәккәдән кайтып киткәнче соңгы гыйбадәт итеп Кәгъбәтуллаһ тирәли саубуллашу тәвафы үтәргә боерылды, һәм бу мәсьәләдә бары тик хәез вакыты башланган хатын-кызларга гына искәрмә бар».*** Килешенгән хәдис.

## ХӘЕЗ

Нигездә, хатын-кыздан бүленеп чыккан кан хәез була һәм аның озаклыгында, дәвамлылыгында һәм цикллылыгында чикләүләр юк.

Әмма әгәр хатын-кызның каны бик озак вакыт килсә һәм, әз вакытка гына туктап торып, бик еш кабатланса, бу нинди дә булса авыруга ишарәли. Мондый очракларда Пәйгамбәребез ﷺ хатын-кызга гадәттә хәез булган вакытта алдагы бүлектә санап үтелгән 8 гамәлдән тыелып торырга боерды. Әгәр ул вакытны билгеләү мөмкин булмаса, бүленеп чыккан канның төсе үзгәрүен (ачыграк төскә керүен) көтәргә кирәк. Әгәр бу да кыенлык тудырса, башка сәламәт хатын-кызларныкы кебек 6–7 көн көтәргә кирәк.

Аллаһ бу хакта яхшырак белә.

<table>
<tr><td>Хәез</td><td>Бала тудырганнан соң булган бүлендекләр (нифас)</td><td colspan="3">Авыру сәбәпле кан чыгу(истихада)</td></tr>
<tr><td rowspan="2">Төп кан чыгу.<br>Аның озаклыгында, дәвамлылыгында һәм цикллылыгында чикләүләр юк</td><td rowspan="2">Хатын-кызның бала тудырганчы, тудырган вакытта яки тудыргач бүленеп чыга торган кан. Бу бүлендекләрнең хөкеме хәез каны хөкеме кебек үк.</td><td colspan="3">Бик озак вакыт бүленеп чыккан яки аз вакытка гына туктап бик еш бүленеп чыга торган кан.<br>Мондый авыруы булган хатын-кыз өч төрле хөкемдә була:</td></tr>
<tr><td>Үзенең гадәти циклын белүче. Мондый хатын-кыз намаз укымыйча һәм ураза тотмыйча хәез вакыты үтеп китүен көтә.</td><td>Хәез канын төсе, исе һәм консистенциясе буенча авыру сәбәпле чыккан каннан аера алучы.</td><td>Аера алмаучы. Хәез вакытының гадәттә кайчан башланганын һәм ике төрле канны аера белми. Мондый хатын-кыз башка хатын-кызларның циклына таянырга тиеш һәм ай календаре буенча һәр ай башында көтәргә тиеш.</td></tr>
</table>

— Бала тудырганнан соң бүленеп чыгучы нифас канының дәвамлылыгы буенча чикләүләре юк, аның минималь вакыты да, максималь вакыты да билгеләнмәгән. Әгәр, мисал өчен, бала тудырган хатын-кызның бүлендекләре кырык көннән артык дәвам итсә, алар барыбер нифас каны булып санала.

— Әгәр хатын-кызның хәез халәте теге яки бу намаз вакытында төгәлләнсә, аңа һич кичекмәстән госел коенырга һәм намазын укырга кирәк. Әгәр хатын-кызның хәез вакыты кичке намазга азаннан соң башланса һәм бу аралыкта бер рәкәгать намаз укырга өлгерерлек вакыт үткән булса, госел коенганнан соң ул әлеге намазын каза кылырга тиеш була, чөнки ул намаз вакытына ирешкән, тик укырга өлгермәгән булып санала.

## ТӘҺӘРӘТ КИТАБЫ БУЕНЧА СОРАУЛАР

| Сорау: | Дөрес | Дөрес түгел |
|---|---|---|
| — Пакьлануга нәҗестән, бөтен пычрактан һәм фәхештән арыну кирәк. | | |
| — Пычрак савыт-сабаны куллану катгый тыела. | | |
| — Алтын савыт-саба куллану катгый тыела. | | |
| — Алтын һәм көмеш савыт-сабадан ашарга һәм эчәргә бары тик ир-атларга гына тыела, ә хатын-кызларга рөхсәт ителгән. | | |
| — Савыт-сабага алтын ямау салырга рөхсәт ителгән. | | |
| — Имансыз кешеләрнең һәртөрле савыт-сабасын кулланырга рөхсәт ителгән. | | |
| — Алтын яки көмеш савыт-сабадагы су белән тәһәрәт алу дөрес түгел. | | |
| — Пычрак турындагы хөкем, ул пычрак бер нәрсәне пычратмаса да, гамәлгә керә. | | |
| — Җанлы заттан аерылган һәртөрле әйбер бернинди искәрмәләрсез үләксәгә тиң. | | |
| — Ите ризык итеп кулланылмаган һәртөрле хайван пычрак санала. | | |
| — Әгәр пакьлану белән бәйле гамәлләрнең өзлексез баруы бозылса, тәһәрәт дөрес булмый. Әгәр тәһәрәт белән бәйле гамәлләрнең өзлексез баруы бозылса, тәһәрәт дөрес булмый. | | |
| — Тәндәге яра төзәлүгә, бәйләвечләр өстеннән тәһәрәт алу дөрес булмый. | | |
| — Әгәр тәндәге яра бәйләвечләр белән бәйләнгән икән, аны сыпырырга мөмкин. Әгәр бәйләвеч бәйләнгән булуга карамастан, шул рәвешле сыпыру сәламәтлеккә зыян салса, бу очракта, яра бәйләнмәгән вакыттагы кебек, су белән тәһәрәт алуны җир белән тәяммүм кылуга алыштырырга кирәк. | | |

— Чалмага охшаш бар нәрсә дә, салырга авыр булганлыктан, чалма хөкемендә була.

— Госел коенырга мәҗбүриткән гамәлләр тәһарәт алуга да мәҗбүр итәләр.

— Ниятне кычкырып түгел, ә эчтән әйтү яхшырак.

— Коенганда өч тапкыр юу яхшырак.

— Намаз вакыты үтүгә, тәяммүм гамәлдән чыга.

— Әгәр тәяммүм яра булганлыктан кылына икән, аңа су юклык та, тәртип тә, өзлеклелек тә шарт була алмый.

— Тәяммүм фарыз чистарынуга гына күрсәтмә була ала.

— Адәм баласының теләсә-нинди калдыклары нәҗес булып санала.

— Хәез темасы — фикх буенча иң катлаулы тема.

— Авырлы вакытта хәез була алмый.

— Нигездә хатын-кызлар чисталык халәтендә түгел, ә хәез халәтендә булалар.

— Гыйбадәт кылынганнан соң гыйбадәт кылу нияте тукталу әлеге гыйбадәтне юкка чыгармый. Шулай ук шикләнү дә, инанганлыктан аермалы буларак, гыйбадәтне кылганнан соң аны юкка чыгармый.

— Пәйгамбәр заманында билгеле булган һәм ул кылмаган һәртөрле гамәл сөннәт түгел.

— Сөннәткә муафыйк гамәл кылу бик күп яхшы гамәлләр кылудан яхшырак.

— Гомуми формада кул сүзе кулланылса да, аны уч төбе буларак кабул итәргә кирәк.

— Тәһарәтне бозучы гамәлләр дә, госелне бозучы гамәлләр дә тәяммүмне боза.

— Аз күләмдә булган пычрак гафу ителә.

— Хәезнең башлану һәм тәмамлану вакытын билгеләү дөрес түгел. Әгәр хатын-кыз үзенә газап китерүче кан чыгуын күрсә, бу хәез була да инде.

— Әгәр авырлы хатын-кыз гадәттә хәез башлана торган вакытта кан чыгуын күрсә, бу — хәезһәм ул аның идда вакытына тәэсир итми.

— Әгәр Аллаһ безгә ниятсез гамәл кылырга йөкләгән булса, ул безгә эшли алмаслык гамәл йөкләгән булыр иде.

— Башны чистартуга карата берникадәр җиңеллек бирелгән.

— Бәвел һәм тәрәттән кала ал юлдан да, арт юлдан да чыгучы бүлендекләр, күп чыгуына да, аз булуына да карамастан, тәһәрәтне дә, госелне дә бозмый.

— Хәез кичергән хатын-кызга: ураза тотарга___, намаз укырга___, икесе дә___тыела.

— Хатынының хәез вакыты булган ир кешегә түбәндәгеләр тыела:

Аның белән аерылышырга___, якынлык кылырга___, икесе дә___.

— Пакьлану:

ике___, өч___ төрле була.

— Пакьлану китабы, ягъни: физик___, рухи___.

— Су: ике___, өч___ төрле була.

— Су: аңа пычрак эләксә___,

Үзгәреш кичерсә___ пычрана.

— Әгәр кеше кайсы суның чиста, кайсы суның пычрак булуында буталса:

Икесен дә калдыра___, икесен дә тикшерә___, икесен бергә болгата___.

— Истинҗа кылуны өч таш белән төгәлләү: тиешле____, фарыз___.

— Ураза тотучы кешегә зәвәлдән соң сивак куллану: тиеш түгел___, рөхсәт ителгән___.

— Күн оекларны сыпыру аларны киеп тәһәрәт бозылгач____, аларны сыпыру вакытыннан___ башлана.

— Әгәр ир кеше чалма өстеннән сыпырса, шуннан соң аның бер учма чәче төшсә, бу чәчләрне сыпыру: фарыз___, тиешле___.

— Күн оеклар өстеннән сыпыру вакыты төгәлләнгәч: тәһәрәтне яңартырга кирәк___, тәһәрәт бозыла___, күн оекларны сыпыру бозыла.

| | | |
|---|---|---|
| — Кем тәһарәтендә инанса һәм пычрануында шикләнсә, яки киресенчә булса: инанганлыгында калырга тиеш___, янәдән тәһарәт алса, яхшырак___.<br>— Йокы: кайсы очракта да тәһарәтне боза___, бер очракта да тәһарәтне бозмый___, ачыкларга кирәк___.<br>— Хатын-кызга кагылу: госел һәм тәһарәтне боза____, бозмый___.<br>— Тәяммүм: кечкенә пычракны бетерә___, тәһарәт һәм госел кирәк булган гамәлләрне рөхсәт итә ___.<br>— Дуңгызның пычрагы: җиңел___, катлаулы____, уртача___.<br>— Кеше каны: чиста___, пычрак___, аз күләмдә булса гафу ителә___, арт яки ал юлдан чыкмаса, чиста ___.<br>— Хәез башлануны билгеләргә ярдәм итүче билгеләр: берәү___, өчәү___, дүртәү___.<br>— Нифас каны килүнең максималь вакыты: 40 көн___, 60 көн___.<br>— Нифас каны килгәндә аерылышу: бидгать___, Сөннәткә муафыйк___. | | |

**Күренекле галим ибне Са'адиның, Аллаһ аны кичерсен, кайбер хезмәтләрен атагыз:**

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

**Сул баганадагы сүзләрне, дөреслеккә туры килерлек итеп, уң баганадагы сүзләр белән тоташтыр:**

| | |
|---|---|
| — Йоклаганда сперма чыгу ... | — Кечкенә нәҗесләр дип атала |
| — Госел коенуга сәбәп булучы пычраклар... | — Хәез каны дип атала |
| — Тәһәрәт алуга сәбәп булучы пычраклар... | — Нифас каны дип атала |
| — Хатын-кызның бала тудырганнан соң килә торган каны... | — Зур нәҗесләр дип атала |
| — Кыз бала бәлигатькә җиткәннән соң килә торган кан... | — Поллюция |

# НАМАЗ КИТАБЫ

# НАМАЗ

**Намаз** — ул тәкбир әйтеп башланучы һәм тәслим белән тәмамланучы билгеле бер хәрәкәтләр һәм сүзләрдән торучы гыйбадәт.

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Мәҗбүри (фарыз).<br>Һәр мөселманга: бәләгатькә ирешкән, гакыллы булган һәм хәез һәм нифас вакыты кичермәгән хатын-кызга мәҗбүри булган намаз. | | | | | Үтәргә тиешле.<br>Фарыз булмаган, әмма үтәлергә тишле намаз. Моный намазлар күп, һәм алар ике категориягә бүленә. | |
| 1. Иртәнге: 2 рәкәгать | 2. Төшке: 4 рәкәгать | 3. Кояш баеганчы: 4 рәкәгать | 4. Кичке: 3 рәкәгать | 5. Төнге: 4 рәкәгать | 1.Гадәти үтәргә тиешле — Аллаһның колы кайчан теләсә, шунда: көндезен һәм төннәрен, тыелган вакытлардан гайре башкарыла торган намаз. | 2. Чикләнгән үтәргә тиешле — теләсә-кайсы ихтыяри ләкин билгеле бер вакыты яки сәбәбе булган намаз. Аларга ратибат намазлары керә. |

# [НАМАЗ ШАРТЛАРЫ]

| Намаз шартлары | | |
|---|---|---|
| 1.Ислам | 2.Гакыл | 3.Эшкә яраклы, сәләтле булу |
| 4.Пычраклардан арыну | 5.Нәҗесләрне бетерү | 6. Гаурәт җирләрне каплау |
| 7. Вакыты җитү | 8. Кыйблага йөз белән борылу | 9. Ният |

— Югарыда намазның бер шарты булыпчистарыну тора диелде.
— Аның шартларына шулай ук вакыт җитү дә керә.

Әлеге мәсьәләдә нигез итеп Җәбраил хәдисе тора. Әлеге хәдистә аның намаз башланган һәм беткән вакытта Пәйгамбәр ﷺ белән бергә намаз укылганлыгы хәбәр ителә, шуннан соң ул болай ди: ***«И Мөхәммәд, намаз шушы ике вакыт арасында укыла».*** Әхмәд, Нәсаи һәм Тирмизи.

Габдулла ибн Гамр сүзләреннән хәбәр ителә, Пәйгамбәр ﷺ болай диде:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1. ***Көндезге намазны кояш зәвәлдән авышкач укырга мөмкин (ягъни кояш күк уртасыннан көнбатышка таба авышкач һәм кешенең шәүләсе аның буена тигез булган вакытта) һәм икенде намазының вакыты җиткәнче.*** | 2. ***Икенде (Өйлә намазының вакыты чыкканнан соң) — кояш саргайганчыга кадәр.*** | 3. ***Кичке — (кояш баеганчы) кичке шәфәкъ кызыллыгы юкка чыкканчы.*** | 4. ***Төнге — (кичке шәфәкъ кызыллыгы юкка чыккач) төн уртасына кадәр.*** | 5. ***Иртәнге — [икенче] таң беленгәннән алып кояш чыкканчыга кадәр.*** Мөслим. |

Кеше икенче намазның вакыты кергәнче намазның бер рәкәгатен укырга өлгерсә, ул намазга өлгерде, дигән сүз, чөнки Пәйгамбәребез ﷺ әйткән: ***«Кем бер рәкәгать укырга өлгерсә, ул намазга өлгерде».*** Килешенгән хәдис.

Намазны сәбәпле һәм сәбәпсез аның вакыты чыкканчы кичектерү рөхсәт ителми. Бары тик сәфәрдә, яңгыр булу яки авыру һәм башка шуның кебек нигезле сәбәп аркасында икенче намаз белән берләштерү өчен кичектерү генә рөхсәт ителә.

| Намазны вакыты керүгә үк уку хәерле булыр, ошбу намазлардан тыш: | |
|---|---|
| 1.Төнге намаз, әгәр кыенлык тудырмаса. | 2.Өйлә намазын бик каты эссе булганда. |

Пәйгамбәр ﷺ әйтте: ***«Әгәр эсселек куәтләнсә, намазны бераз көн сүрелгәчрәк вакытка калдырыгыз, чөнки, чынлыкта, каты эсселек — Җәһәннәмнең сулышы». Бохари.***

Кайсы да булса намазны төшереп калдырган кеше аны кичекмәстән, тәртибен саклап укырга тиеш.

Әгәр кеше намазларның тәртибен онытса, яки тәртипне саклау тиешлеге хакында белмәсә, яки киләсе намазның вакыты чыгып китүеннән курыкса, намазлар тәртибен бозарга ярый.

| **Намаз вакыты кергәч түбәндәгеләрне эшләү тиешле:** | |
|---|---|
| **1.Азан әйтергә**<br>Хөкеме: авыл яки шәһәрнең ирләренең уртак гомуми бурычы, алар биш вакыт намазга чакырырга тиешләр.<br>Вакыты: намаз вакыты кергәннән соң, кешеләргә бу хакта белгертү һәм аларны җәмәгать белән укырга дип, намазга чакыру.<br>Рәвеше:<br>Аллаһу әкбәр,<br>Аллаһу әкбәр,<br>Аллаһу әкбәр,<br>Аллаһу әкбәр<br>Әшһәду әл ләә иләәһә иллә-лаах<br>Әшһәду әл ләә иләәһә иллә-лаах<br>Әшһәду әннә Мүхәммәдәр-расүүлүл-лаах<br>Әшһәду әннә Мүхәммәдәр-расүүлүл-лаах<br>Хәй'йә гәләс-саләәһ<br>Хәй'йә гәләс-саләәһ<br>Хәй'йә гәләл-фәләәх<br>Хәй'йә гәләл-фәләәх<br>Аллаһу әкбәр<br>Аллаһу әкбәр<br>Ләә иләәһә иллә-лаах | **2.Камәт әйтү**<br>Хөкеме: сөннәт.<br>Вакыты: намазга керешкәнче, беренче тәкбирне әйткәнче.<br>Рәвеше:<br>Аллаһу әкбәр,<br>Аллаһу әкбәр,<br>Аллаһу әкбәр,<br>Аллаһу әкбәр<br>Әшһәду әл ләә иләәһә иллә-лаах<br>Әшһәду әл ләә иләәһә иллә-лаах<br>Әшһәду әннә Мүхәммәдәр-расүүлүл-лаах<br>Әшһәду әннә Мүхәммәдәр-расүүлүл-лаах<br>Хәй'йә гәләс-саләәһ<br>Хәй'йә гәләс-саләәһ<br>Хәй'йә гәләл-фәләәх<br>Хәй'йә гәләл-фәләәх<br>Каде каамәтис-саләәһ<br>Каде каамәтис-саләәһ<br>Аллаһу әкбәр<br>Аллаһу әкбәр<br>Ләә иләәһә иллә-лаах |

| **Намаз вакыты кергәч түбәндәгеләрне эшләү тиешле:** |
|---|
| **Мәзин булмаган кешегә тиешле:**<br>— Мәзин артыннан «Хәйя ʻаля-с-саләһ» сүзләренә кадәр азан сүзләрен кабатлау. «Хәйя ʻаләл-фәләх» сүзләрен әйткәндә: «лә хәулә уә лә куввәтә илля би-Лләһ» дияргә, җәмәгать намазын укырга ниятләргә һәм Аллаһтан бу ниятнең тормышка ашуында ярдәм сорарга.<br><br>— Пәйгамбәребезгә ﷺ салават әйтергә.<br><br>— Азаннан соң ошбу доганы кылырга:<br>اَللّٰهُمَّ رَبَّ هَذِهِ الدَّعْوَةِ التَّامَّةِ وَالصَّلَاةِ الْقَائِمَةِ آتِ مُحَمَّدًا الْوَسِيلَةَ وَالْفَضِيلَةَ وَابْعَثْهُ مَقَامًا مَحْمُودًا الَّذِى وَعَدْتَه<br>*Мәгънәсе: Йә Аллаһ, әлеге камил чакыруның һәм булачак намазның Хуҗасы! Мөхәммәдкә Үзең вәгдә иткән Җәннәттәге иң югары баскыч булган «әл-Вәсилә»не бир һәм аны «Мәкам-Мәхмуд»тә (мактауга лаеклы урында) терелт.*<br><br>— Азан һәм камәт арасында Аллаһка яраткан догалар белән мөрәҗәгать итәргә. |

— Гаурәтне каплау (тәннең ачыклыгын каплаучы, тәнне күрсәтми торган кием кию) — намазның бер шарты булып тора.

| **Шәрәлек өч төрле була:** | | |
|---|---|---|
| **1.Житди**<br>Бу бәләгатькә ирешкән ирекле хатын-кызның гаурәте: намаз вакытында аның йөзеннән тыш бөтен тәне капланган булырга тиеш. | **2.Җиңелчә**<br>Бу 7 яшьтән алып 10 яшькәчә булган балаларның гаурәте: җенес органнары. | **3.Уртача**<br>Бу, әле генә телгә алынган ике категориядән тыш, башка категория кешеләрнең гаурәтләре: кендектән алып тезләргә кадәр. |

Аллаһ Тәгалә әйтте: **«И Адәм балалары! Мәчетләргә кергәнче зиннәтләрегезгә киенегез».**

— Намазның тагын бер шарты — йөз белән Кыйблага юнәлү.

Аллаһ Тәгалә әйтте: **«Кайдан гына килеп чыксаң да, йөзеңне Харам мәчетенә юнәлт».**

— Әгәр авыру яки башка сәбәпле болай эшләү мөмкин түгел икән, бу шарт башка шундый фарыз гамәлләрне үтәү мөмкин булмаган кебек төшеп кала. Аллаһ Тәгалә әйтте: **«Аллаһтан үз мөмкинлекләрегездән чыгып куркыгыз».**

— Сәфәрдә булганда, Пәйгамбәр ﷺ дөя өстендә утырган килеш ихтыяри намазлар башкара иде һәм йөзен дөясе кай тарафка борылса, шул тарафка юнәлтә иде. Килешенгән хәдис.

Әлеге хәдиснең башка версиясендә болай диелгән: ***«Әмма ул фарыз намазларын бу рәвешле башкармады».***

— Намазның шартларына ният кирә. Ниятнең урыны йөрәктә һәм аны тел белән әйтү бидгать була.

— Намазны ошбу урыннардан башка барлык җирдә дә укырга мөмкин:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1. Пычрак урында | 2. Хаксыз рәвештә милекләнгән, тартып алынган урында | 3. Җирләү урыннарында, зыяраттә | 4. Юыну бүлмәсендә | 5. Дөяләр өчен булган абзарларда |

«Сунан»да Тирмизи Пәйгамбәргә ﷺ барып тоташучы мондый хәдис китерә, Пәйгамбәребез ﷺ әйткән: ***«Зиярат урыннарыннан һәм мунчалардан тыш бөтен җир мәчет».***

## НАМАЗНЫҢ ТАСВИРЛАМАСЫ

Намазга [сүзләрдә һәм хәрәкәтләрдә] тынычлык һәм [тышкы кыяфәттә] абруй сакланган хәлдә керешү тиешле.

Мәчеткә кергәндә ошбу сүзләрне әйтергә кирәк:

بسم اللهِ وَالصّلاةُ وَالسّلامُ عَلَى رَسُولِ اللهِ اللَّهُمَّ اغفِر لِي ذُنُوبِي وَ افْتَحْ لِي أَبْوَابَ رَحْمَتِكَ

*Мәгънәсе: «Аллаһ исеме белән. Аллаһның илчесенә Аның рәхмәте һәм сәламе булсын. Йә Аллаһ минем гөнаһларымны кичер һәм минем өчен Үзеңнең рәхмәт ишекләреңне ач.».*

| | |
|---|---|
| 1.Мәчеткә уң аяктан атлап керү тиешле. | 2.Мәчеттән чыкканда сул аяктан чыгу зарур. |

**Искәрмә:** Мәчеткә кергәндә яки чыкканда укыла торган догадагы«Вә с-соләт» (Аллаһның сәламе булсын!) сүзен әйтү бер дөрес хәдистә дә китерелми.

Әлеге доганы болай укырга кирәк:

اللَّهُمَّ افْتَحْ لِي أَبْوَابَ فَضلِكَ

*Мәгънәсе: «Йә Аллаһ, миңа Үзеңнең рәхмәт ишекләреңне ач» — бу хактаӘхмәд һәм Ибн Мәджә китергән хәдистә әйтелә.*

Намазга баскач, «Аллаһу әкбәр» сүзләрен әйтергә кирәк, бу вакытта куллар күтәрелә [бармаклар бер-берсенә тыгыз урнаша, уч төпләре Кыйблага юнәлдерелә]:

| | |
|---|---|
| 1.Җилкәләргә кадәр | 2.Колакларга кадәр |

Дүрт урында:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1.Кереш тәкбирдә | 2.Рокугъта | 3.Рокугътан торганда | 4.Беренче тәшәххудтән торганда |

| |
|---|
| Шуннан соң ул, уң кул чугын сул кул чугының аркасына, шулай ук беләзеккә һәм беләкләргә куя, яки уң кулы белән сул кулының беләзеген [уң кулының учы белән сул кулының тышкы ягын җиңелчә генә кысып]тота, кулларны кендек өстенә, яки астына, яки күкрәккә баглый. |
| **Искәрмә: Кулларны күкрәкләргә баглау Сөннәткә муафыйграк, ә калган ике вариант хакында Пәйгамбәребездән ﷺ килгән дөрес хәдисләр юк.** |

| |
|---|
| Намаз укучы үзенең күз карашын сәҗдә урынына юнәлтә һәм намаз вакытында читкә борылмый |
| Шуннан соң ошбу сүзләрне әйтергә кирәк:<br>سُبْحَانَكَ اللَّهُمَّ وَبِحَمْدِكَ و تَبَارَكَ اسْمُكَ، وَتَعَالَى جَدُّكَ وَلَا إِلَهَ غَيْرُكَ<br>*Мәгънәсе: «Барча олугълаулар сиңа, йә Аллаһ, һәм барча мактаулар! Синең исемең бик мөбарәк, даның олугтыр, вә Синнән башка иләһ юк»,*— яки Пәйгамбәрдән ﷺ килгән башка төрле намазны «ачучы» доганы кылырга [бары тик беренче рәкәгатьтә]. Соңыннан истигазә әйтелә:<br>أَعُوذُ بِاللهِ مِنَ الشَّيْطَنِ الرَّجِيْمِ<br>*[Мәгънәсе: «Аллаһның рәхмәтеннән ерак булган шайтаннан сакланып, Аллаһка сыенамын]».*<br>Һәм бәсмәлә:<br>بِسْمِ اللهِ الرَّحْمنِ الرَّحِيمِ<br>*[Мәгънәсе: «Рәхимле һәм рәхмәтле булган Аллаһның исеме белән башлыйм»],*— Шуннан соң «Әл-фатиха» сүрәсен укырга кирәк.<br><br>«Әл-фатиха»дан соң 4 яки 3 рәкәгатьле намазларның беренче ике рәкәгатендә истигазәдән башка гына теләсә-кайсы сүрәне укырга кирәк, ягъни: |

| | | |
|---|---|---|
| 1.Иртәнге намазда (озын булган «муфассаль» (аерылган) сүрәләрнең берсен) | 2.Кичке намазда (Кыска сүрәләрнең берсен) | 3.Башка намазларда (уртача озынлыктагы сүрәләр) |

| «Аерылган» («муфассаль») сүрәләрнең өлешләре | | |
|---|---|---|
| **Озын**:«әл-Мурсаләти» га кадәр «Каф» сүрәсе | **Уртача**: «әл-Ләйль» гә кадәр «ән-Набаъ» сүрәсе | **Кыска**: «ән-нәс» кә кадәр «әд-Духа» сүрәсе |

| **Намазларда уку тәртибе:** | |
|---|---|
| 1.Төнге намазлар кычкырып укыла. | 2.Көндезге намазлар, җомга һәм бәйрәм намазларыннан, шулай ук ай, кояш тотылу сәбәбе белән кычкырып укылучы намазлардан кала, эчтән укыла. |

Шуннан соң рокугъка китү өчен тәкбир әйтелә.

Кулларны [терсәкләрдән бөкләмичә] тезләр өстенә куярга кирәк.

Башны туры итеп арка тигезлегендә тотарга кирәк.

Бу халәттә түбәндәге сүзләр әйтелә:

سُبْحَانَ رَبِّيَ الْعَظِيمِ

1 тапкыр [мәҗбүри], яки берничә тапкыр кабатларга [тиешле].

Әгәр рокугъ вакытында һәм сәҗдәдә ошбу доганы кылсаң, яхырак:

*Мәгънәсе: «Йә Аллаһ, син пакьсың, Раббыбыз безнең, барча мактаулар Сиңа. Йә Аллаһ, мине кичер».*

سبحانك اللّٰهُمَّ ربنا و بحمدك اللّٰهُمَّ اغفر لي

Шуннан соң, әгәр кеше үзе генә яки имам булып намаз укыса, шушы сүзләрне әйтә-әйтә, рокугътан күтәрелергә кирәк:

سمع اللّٰه حمده

*Мәгънәсе: Аллаһ Үзен мактаучыларны ишетә.*

Шуннан соң барлык намаз укучыларга да [туры басып]дога кылырга кирәк:

مِلْءَ السَّمَاء وَمِلْءَ الأَرْضِ، وَمِلْءَ مَا شِئْتَ مِنْ شَيْءٍ بَعْدُربنا ولك الحمد حمداً كثيراً طيباً مباركاً فيه

*Мәгънәсе: «Йә Аллаһ, Раббыбыз безнең, барча мактаулар Сиңа. Иң яхшы, иң саф һәм мөбарәк мактаулар бары тик Сиңа! Һәм шушы мактаулар бөтен күкләрне, җирне һәм Син теләгән бар нәрсәләрне тутырсын».*

Шуннан соң сәҗдә кылына Пәйгамбәребез ﷺ әйткәнчә, гәүдәбезнең җиде өлеше белән сәҗдә кылына: ***«Миңа сәҗдәне җиде сөягемә таянып кылырга боерылды: маңгайга (моны әйтеп ул үзенең борынына күрсәтте), кулларга, тезләргә һәм аяк бармаклары очларына».*** Килешенгән хәдис.

Шул ук вакытта гәүдәдән култык асларын, корсакны — ботлардан, ботларны тезләрдән аерырга, беләкләрне иләннән күтәрергә кирәк.

Һәм ошбу доганы кылырга:

سُبْحَانَ رَبِّيَ الْأَعْلَي

*Мәгънәсе: «Минем бар нәрсәдән бөегрәк булган Раббым бар нәрсәдән чиста»*) — 1 тапкыр [(мәҗбүри) яки берничә тапкыр кабатларга (тиешле), шулай ук өстәмә рәвештә хәдисләрдә китерелгән башка догаларны кылырга кирәк].

Шуннан соң тәкбир әйтергә, сул аякка утырып уң аякның табан астын турайтырга кирәк («әл-ифтираш» торышы). Намазлардагы барлык утыруларда да, соңгы тәшәххудтән башка, шул торышны алырга кирәк. Соңгы тәшәххудне уку өчен «таваррук» торышына утырыла, ягъни идәнгә утырганда сул аякның табан асты уң аяк табан астыннан күренеп торырга тиеш.

Бу кыяфәттә утырганда ошбу дога укыла:

رب اغفر لي و ارحمني و اهدني و ارزقني و اجبرني و عافني

*Мәгънәсе: «Раббым, кичер мине, ярлыка, туры юлга күндер һәм яшәү өчен ризык бир»,* — һәм беренчесе кебек үк икенче сәҗдә кылына.

Шуннан соң, тәкбир әйтә-әйтә, торып басарга, тураерга һәм беренче рәкәгатьне үтәгән кебек үк икенче рәкәгатьне башкарырга кирәк, [әмма икенче рәкәгатьтә ачучы дога укылмый].

Шуннан соң утырырга һәм беренче тәшәххудне укырга кирәк. Ул ошбу рәвешле укыла:

التَّحِيَّاتُ لِلّٰهِ وَ الصَّلَوَاتُ وَ الطَّيِّبَاتُ اَلسّلاَمُ عَلَيْكَ اَيُّهَا النَّبِيُّ وَ رَحْمَةُ اللّٰهِ وَ بَرَكَاتُهُ اَلسَّلاَمُ عَلَيْنَا وَ عَلٰى عِبَادِ اللّٰهِ الصَّالِحِينَ اَشْهَدُ اَنْ لاَ اِلاَهَ اِلاَّ اللّٰهُ وَ اَشْهَدُ اَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَ رَسُولُهُ

*Мәгънәсе: «Тел гыйбадәтләре дә, тән гыйбадәтләре дә, мал гыйбадәтләре дә — һәркайсы Аллаһы Тәгалә өчен. Әй Пәйгамбәребез, Сиңа Аллаһының сәламе, рәхмәте һәм бәрәкәте булсын. Сәлам безгә дә һәм Аллаһы Тәгаләнең һәрбер изге бәндәләренә дә булсын. Күңелемнән гуаһлык бирәмен ки, дөреслектә, Аллаһы Тәгаләдән башка Илаһи зат һич юк. Шулай ук гуаһлык бирәмен ки, дөреслектә, Мөхәммәд — Аллаһы Тәгаләнең колы һәм илчесе».*

Шуннан соң тәкбир әйтергә һәм намазны, һәр рәкәгатьтә «әл-фатиха»сүрәсен укып, ахырга укып бетерергә кирәк. Ахырда беренчесе кебек үк соңгы тәшәххуд укыла һәм аңарга әлеге догалар өстәлә:

| 1 | 2 | 3 |
| --- | --- | --- |
| اللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ، كَمَا صَلَّيْتَ عَلَى إِبْرَاهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْرَاهِيمَ، إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ، اللَّهُمَّ بَارِكْ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ، كَمَا بَارَكْتَ عَلَى إِبْرَاهِيمَ و علي آلِ إِبْرَاهِيمَ، إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ.<br><br>*Мәгънәсе: «Йә Рабби, Ибраһимга һәм аның гаиләсенә рәхмәтеңне биргән кебек, Мөхәммәдкә һәм аның гаиләсенә дә рәхмәтеңне бир. Дөреслектә, Син мактаулы һәм олуг зат. Йә Рабби, Ибраһимга һәм аның гаиләсенә бәрәкәтеңне биргән кебек, Мөхәммәдкә һәм аның гаиләсенә дә бәрәкәтеңне бир. Дөреслектә, Син — мактаулы һәм олуг зат».* | اللَّهُمَّ إِنِّي أَعُوذُ بِكَ مِنْ عَذَابِ جَهَنَّمَ، وَ مِنْ عَذَابِ الْقَبْرِ، و مِنْ فِتْنَةِ الْمَحْيَا وَالْمَمَاتِ و مِنْ شر فِتْنَةِ المسِيحُ الدَّجَّالِ<br><br>*Мәгънәсе: «Йә Аллаһ, чынлыкта, Җәһәннәм газабыннан, кабер газабыннан, бу дөнья һәм үлем коткысыннан, дәҗҗәл коткысыннан һәм явызлыгыннан Синә сыенам».* | Аллаһка төрле догалар, үтенечләр белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин, ләкин Пәйгамбәребездән ﷺ килгән башка догалар уку яхшырак булыр. |

Шуннан соң уң һәм сул якларга «тәслим» әйтелә:

السلام عليكم و رحمة الله

Чөнки бу хакта Әбу Давыдтан килгән Ваил ибн Худжр хәдисендә әйтелә.

Югарыда әйтелгән **теләдән әйтелә торган әркәннәр**: кереш тәкбир, имам булмаган кешегә фатиха сүрәсен уку, соңгытәшәххуд һәм тәслим.

Беренче тәшәххудтән һәм аны уку өчен утырудан тыш намазның башка гамәлләре **хәрәкәт әркәннәре** була, чөнки алар намазның мәҗбүри үтәлергә тиешле гамәлләренә керә.

| Намазның әркәннәре 14: | | |
|---|---|---|
| 1.Мөмкинчелектән чыгып басып тору | 2.Кереш тәкбир | 3.«Әл-фатиха» сүрәсен уку |
| 4.Рокугъ | 5.Рокугътан тору | 6.Гәүдәнең җиде өлеше белән сәҗдә кылу |
| 7.Сәҗдәдән тору | 8.Ике сәҗдә арасында утырып тору | |
| 9.Барлык хәрәкәтләрне башкарганда тыныч һәм салмак булу | 10.Әркәннәрне үтәгәндә тәртипне саклау | 11.Соңгы тәшәххуд |
| 12.Соңгы тәшәххудтә утыру | 13.Пәйгамбәргә ﷺ салават әйтү | 14.Ике тәслим |

| Намазның мәҗбүри үтәлергә тиешле гамәлләре 8: | | |
|---|---|---|
| 1.Беренче тәшәххуд. | 2.Беренче тәшәххудкә утыру. | 3.Кереш тәкъбирдән кала барлык тәкъбирләр. |
| 4.Рокугъ вакытында «Субхәнә раббия ль-'азым» сүзләрен әйтү. | 5. Сәҗдә вакытында берәр тапкыр «Субхәнә раббия ль-агъля» дип әйтү. | 6. Ике сәҗдә арасында берәр тапкыр «Рабби гъфир ли» дип әйтү. Барлык өстәмәләр үтәргә тиешле була. |
| 7.Имам өчен һәм намазны ялгызы гына башкарган кеше өчен «Сәмига Ллаху ли-мән хәмидәху» сүзләрен әйтү. | | 8.Барлык намаз укучыларга да «Раббәнә уә ләкә аль-хәмд»,— дип әйтү. |

Бу мәҗбүри үтәлергә тиешле гамәлләр онытылу яки белмәү сәбәпле үтәлмәсә, алар төшеп кала, әмма «Сәху сәҗдәсе» (намаз ахырында өстәмә ике сәҗдә) ярдәмендә тулыландырыла.

Намаз әркәннәренең берсе дә онытылу сәбәпле дә, белмәү сәбәпле дә яки аңлы рәвештә төшерелеп калдырыла алмый.

Калган үтәргә тиешле булган сүзләр һәм гамәлләр намазны тулыландыра.

Әркәннәргә шулай ук барча әркәннәрне дә тыныч һәм салмак итеп үтәү кирә.

Әбу Хурәйрадан килә, Аллаһ аннан риза булсын, Пәйгамбәребез ﷺ болай дигән: ***«Намазга торган вакытта тәһарәтне тиешле дәрәҗәдә итеп ал, шуннан соң кыйблага юнәл һәм тәкъбир әйт. Шуннан соң Коръәннән сиңа җиңел бирелгән сүрәләрне укы, шуннан соң тынычлыкка ирешерлек итеп рокугъка кит. Шуннан соң рокугътан күтәрелеп тураеп бас. Шуннан соң тынычлыкка ирешерлек итеп сәҗдә кыл, шуннан соң аннан күтәрел һәм тынычлыкка ирешерлек итеп утыр, шуннан соң тынычлыкка ирешерлек итеп сәҗдәгә кит. Шул рәвешле намазыңның калган өлешен кыл».*** Килешенгән хәдис.

Шулай ук ул әйтте: ***«Мин ничек укыдым, намазыгызны шул рәвешле кылыгыз».*** Килешенгән хәдис.

Намазын тәмамлагач, ул өч мәртәбә истигъфар әйтеп, болай дия иде:

| 1 | 2 | |
|---|---|---|
| اَللّهُمَّ أَنْتَ السَّلامُ وَمِنْكَ السَّلامُ تَبارَكْتَ وَتَعالَيْتَ يا ذَا الْجَلالِ وَالْإِكْرامِ<br>*Мәгънәсе: «Йә Аллаһ, Син — Тынычлыкның үзеһәм тынычлык — Синнән, Синдә иминлек, әйбөеклек һәм юмартлык Иясе!»* | لا إله إلا الله وحده لا شريك له، له الملك وله الحمد، وهو علي كل شيء قدير، لا اله إلا الله ولا نعبد إلا إياه له النعمة وله الفضل وله الثناء الحسن، لا إله إلا الله مخلصين له الدين ولو كره الكافرون"<br>*Мәгънәсе: «Бер Аллаһтан башка табынырга лаеклы илаһ юк. Бар хакимлек Аның кулында, Аңа барча мактау, Ул барысын да булдыра! Аллаһтан башка бүтән бер кемдә дә көч вә куәт юк, һәм без Аңардан башка һичкемгә дә табынмыйбыз. Ул игелек һәм рәхимлелек күрсәтә, һәм Аңа гына лаеклы дәрәҗәдә мактаулар ирештерергә тиешбез. Аллаһтан башка табынырга лаеклы илаһ юк, һәм без Аның каршында динне үтәүдә турылыклы, хәтта бу гамәлебез имансызларның нәфрәтен уятса да!»* | سبحان الله و الحمد لله و الله أكبر<br>33 тапкыр, ә бу сүзләрне:<br>لا إله إلا الله وحده لا شريك له، له الملك وله الحمد، وهو علي كل شيء قدير<br>— йөзенче тапкырында әйтү |

<table>
<tr><td colspan="4">Фарыз намазлары белән укылырга тиешле ратибәт-намазлар барлыгы 10, һәм алар Ибн Гомәр, Аллаһ аларның икесеннән дә риза булсын, хәдисендә китерелә, ул әйтте: «Мин Аллаһның илчесеннән ﷺ 10 рәкәгать отып калдым:</td></tr>
<tr><td>1.Өйлә намазына кадәр ике рәкәгать һәм аннан соң ике рәкәгать;</td><td>2.Кичке намаздан соң ике рәкәгать, аларны өйдә башкару хәерле;</td><td>3.Төнге намаздан соң ике рәкәгать, аларны өйдә башкару хәерле;</td><td>4.Иртәнге намазга кадәр ике рәкәгать».<br>Килешенгән хәдис</td></tr>
</table>

Әлеге намазлар «раватиб» (ратибәт) дип атала, чөнки алар мәҗбүри намазлар белән бергә укыла:

| **Намаз** | **Иртәнге** | **Өйлә** | **Кичке** | **Төнге** |
|---|---|---|---|---|
| Рәкәгатьләр саны | 2 | 4 яки 6 | 2 | 2 |
| Намазга кадәр | 2 | 2 яки 4 | - | - |
| Намаздан соң | - | 2 | 2 | 2 |

**Ратибәт-намазларны башкаруның асыл мәгънәсе шунда:**

— Мәҗбүри намазларны укыган вакытта Аллаһның колы тарафыннан җибәрелгән хата-кимчелекләрне төзәтү;

— Иманның артуы, чөнки иман гыйбадәт кылу нәтиҗәсендә арта, ә гөнаһлар күбәю нәтиҗәсендә кими.

Катгый үтәлергә тиешле ратибәт-намазлар — иртәнге намаз алдыннан булган сөннәт, һәм ул башка ратибәт-намазлардан түбәндәге билгеләр белән аерылып тора:

| 1.Дәрәҗә | 2.Җиңеллек | 3.Даимилек | 4.Уку рәвеше | 5.Аны укыганнан соң кырын яту. |
|---|---|---|---|---|
| Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Иртәнге намаз алдыннан укылган ике рәкәгать, бөтен дөньяга һәм анда булган бөтен нәрсәләргә караганда да хәерлерәк».*** | Әркәннәрдә кимчелекләргә юл куелмау. Гайшә, Аллаһ аннан риза булсын, болай диде: ***«Азан ишетүгә, ул фарыз намазына кадәр һәрвакыт, җиңеләйтеп, ике рәкәгать намаз укый иде».*** | Бу намаз сәфәрдә булганда да, өйдә дә укылмыйча калмый. | Үзенчәлекле рәвештә укыла, ягъни анда «Кәфирун» һәм «Ихлас» сүрәләре укыла. | Аны укыганнан соң, әгәр кеше өйдә булса һәм төнне намазларда үткәрсә, уң як белән кырын яту тиешле. |

# СӘХҮ СӘҖДӘСЕ, ТИЛӘВӘТ ҺӘМ ШӨКЕР СӘҖДӘЛӘРЕ

**Сәхү сәҗдәсе шушы очракларда кылына:**

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1.Кеше үзенең намазында онытылып китеп сәҗдә һәм рокугъларын, шулай ук утыруларын һәм басып торуларын артыграк кылса. | 2.Яки әле санап кителгәннәрнең берәрсен эшләмәсә. Бу очракта онытылган гамәл-хәрәкәтне эшләргә һәм сәхү сәҗдәсен кылырга кирәк. | 3.Онытылып китеп намазның мәҗбүри гамәлләренең берсен үтәмичә төшереп калдырса. | 4.Тегe яки бу хәрәкәтне кирәгеннән артык яки кимрәк эшләвендә шикләнсә. |

**Дөрес хәдисләрдән килә, Пәйгамбәребез ﷺ:**

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1.Онытылып китеп, беренче тәшәххудкә утырмыйча торып баса иде һәм сәхү сәҗдәсен кыла иде. | 2.Онытылып китеп, өйлә һәм икенде намазларын ике рәкәгатьтән соң тәмамлады. Ә бу хакта аңа әйткәч, ул намазларны ахырына кадәр укып тәмам итте һәм ахырдан сәхү сәҗдәсе кылды | 3.Өйлә намазын 5 рәкәгать итеп укыды, ә бу хакта аңа әйткәч, ул сорады: ***«Ничек алай?»*** ***Аңа: «Син 5 рәкәгать укыдың»***, — диделәр, шуннан соң ул ике сәҗдә кылды һәм тәслим әйтте. Килешенгән хәдис | 4.***«Әгәр сезнең кайсыгыз да булса намаз вакытында үзенең ничә: өчме, дүртме рәкәгать укуында шикләнсә, шикләрен кире каксын һәм ничә рәкәгать укыдым, дип уйласа, шул санга таянсын. Шуннан соң аңа сәлам биргәнче ике сәҗдә кылырга кирәк. Әгәр шуның нәтиҗәсендә ул биш рәкәгать намаз укыган булса да, ике сәхү сәҗдәсе аның намазының рәкәгатьләр санын җөп санга тутырыр. Әгәр аның намазы дөрес булган булса, әлеге сәҗдәләр шайтан өчен түбәнчелек булыр».*** Әхмәд һәм Мөслим. |

Әлеге ике сәҗдәне тәслимгә кадәр яки аннан соң кылырга рөхсәт ителә.

**Бу гамәлләрне дә үтәү тиешле булып тора:**

<table>
<tr><td>1.Коръән укыганда, намаз эчендә булса да, намаздан тыш булса да, укучы өчен дә тыңлаучы өчен дә тиләвәт сәҗдәсен кылу.</td><td>2.Әгәр кешегә берәр хәерлелек килсә яки ул бәла-казадан котылса, сәҗдә кылу.</td></tr>
<tr><td colspan="2">Шөкер сәҗдәсе дә тиләвәт сәҗдәсе кебек үк үтәргә тиешле гамәл булып тора.</td></tr>
<tr><td colspan="2">Кагба ибн Мәлик риваятендә, Аллаһ аннан риза булсын, шул хакта хәбәр ителә: аңа Аллаһ тәүбәңне кабул итте, дигән шатлыклы хәбәр ирештергәч, ул сәҗдә кылды.</td></tr>
</table>

<table>
<tr><td colspan="6">Сәхү сәҗдәсен кылу өчен сәбәпләр өчәү:</td></tr>
<tr><td rowspan="3">1.Арттыру<br><br>Рокугъ яки сәҗдә, утыру яки басып тору һәм башкалар сан буенча артыграк кылынса.</td><td rowspan="3">2.Киметү<br><br>Намаз фарызларының кайсы да булса берсе үтәлмичә төшеп калса.</td><td colspan="4">3.Рәкәгать ләр санына кагылышлы шикләнү: 3 яки 4.<br>Шикләнү ике төрле була:</td></tr>
<tr><td rowspan="2"><u>Гыйбадәтне тәмамлаганнан соңгы шикләнү</u><br>Мондый шикләнүгә, ышаныч туганчыга кадәр, игътибар бирелми</td><td colspan="3"><u>Гыйбадәтне кылган вакытта шикләнү.</u> Аның хөкеме:</td></tr>
<tr><td>Әгәр рәкәгатьләр саны күбрәк булса, моңарга игътибар итмәскә кирәк.</td><td>Әгәр рәкәгатьләр саны әзрәк булса, кеше ничә рәкәгать дип уйласа, рәкәгатьләре шул санча була дигән фикердә тору.</td><td>Әгәр кеше рәкәгатьләр саны артык кылдыммы яисә кимме, дип шикләнсә, бу очракта аз санда тукталырга кирәк.</td></tr>
</table>

# НАМАЗНЫ БОЗУЧЫ ГАМӘЛЛӘР ҺӘМ НАМАЗ ЭЧЕНДӘ ҮТӘЛМӘСӘ ЯХШЫРАК БУЛГАН ГАМӘЛЛӘР

**Намазны боза:**

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1.Намазның әркәнен яки шартын аны үтәргә мөмкинлекләр була торып та аңлы рәвештә, онытылып яки белмичә үтәми калдыру. | 2.Фарыз гамәлне аңлы рәвештә үтәмичә калдыру. | 3.Аңлы рәвештә [болай эшләү тыелган икәнлеген белә торып һәм истә тотып] чит-ят сүзләр әйтү. | 4.Кычкырып көлү. | 5.Берөзлексез һәм зарурияtsыз чит-ят хәрәкәтләр ясау, чөнки беренче очракта кеше аны үтәмичә намаз дөрес булмаган хәрәкәтне төшереп калдырса, ә соңгы ике очракта тыелган гамәлләр башкара. |

**Боларны эшләү тиеш түгел:**

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1.Намаз вакытында як-якка борылу, чөнки бу хакта Пәйгамбәребездән ﷺ сорагач, ул болай диде: ***«Бу — урлашу. Шул рәвешле шайтан колның намазыннан урлый». Бохари.*** | | | 2.Уйнау (кызык өчен төрле хәрәкәтләр эшләү). | |
| 3.Кулларны билгә таяну | 4.Бармакларны бер-берсеннән аеру | 5.Бармакларны шартлату | 6.Эт шикелле утыру [аякларны турайту һәм алар арасына идәнгә утыру]. | 7.Фикерне читкә җибәрүче нәрсәләргә таба юнәлү: [күзге яки телевизорга юнәлү] |

| 8.Калебнең намаздан читкә юнәлгән вакытында намазга керешү: | | 9.Шулай ук Пәйгамбәребез ﷺ ир-атларга сәҗдә вакытында идән буйлап терсәкләрне җәюне тыйды |
| --- | --- | --- |
| — бәдрәфкә барасы килү теләге белән | — яки өстәлдә ризык булып, бик нык ашыйсы килү теләге булганда, чөнки ﷺ әйтте: «***Ризык китерсәләр һәм кече яки зур йомышны башкарасы килгән вакытта намазга урын юк***». Килешенгән хәдис. | |

| **Намаз барышындагы хәрәкәтләрнең биш төрле хөкеме бар:** | | | | |
| --- | --- | --- | --- | --- |
| 1.Тыелган<br><br>Берөзлексез һәм заруриятсез күп чит-ят хәрәкәтләр эшләү, мәсәлән, ашау. | 2.Үтәлергә тиеш түгел<br>Заруриятсез генә әз хәрәкәт ясау, мәсәлән, башны читкә бору. | 3.Рөхсәт ителгән<br>Зарурлыгы булган хәрәкәт, мәсәлән, сакалны сыпыру. | 4.Үтәлергә тиеш<br>Намазның тулылыгы бәйле булган хәрәкәтләр, мәсәлән намаз укучылар рәтендә буш урынны алу. | 5.Мәҗбүри<br><br>Намазның дөреслеге аларга бәйле булган хәрәкәтләр, мәсәлән, нәҗесне бетерү. |

| **Шарт** | **Әркән** | **Мәҗбүри гамәл** | **Үтәргә тиешле булган гамәл** |
| --- | --- | --- | --- |
| Гыйбадәтнең үзенә керми | Гыйбадәтнең үзенә керә | | |
| Гыйбадәт тәмамланганчы гамәлдә була | Гыйбадәтнең билгеле бер өлеше белән чикләнә | | |
| Белмәү сәбәпле дә, онытылу сәбәпле дә калдырырга ярамый. | | Белмәү яки онытылу сәбәпле, әмма аңлы рәвештә түгел, үтәлмичә калырга мөмкин | Белмәү, онытылу сәбәпле яки аңлы рәвештә түгел, үтәлмичә калырга мөмкин |
| Сәһү сәҗдәсе ярдәмендә тулыланмый. | | Сәһү сәҗдәсе ярдәмендә тулылана | Тулылануда хаҗәте юк |

## ИХТЫЯРИ НАМАЗ

### Ай һәм кояш тотылган вакытта укыла торган намаз

Кояш тотылган вакытта намаз уку тиешлерәк, чөнки Пәйгамбәребез ﷺ мондый намазны үзе үтәде һәм башкаларга да боерды.

Әлеге намаз Гайшә, Аллаһ аннан риза булсын, хәдисендә тасвирланганча укыла. Әлеге хәдистә Пәйгамбәрнең ﷺ бу намазны ничек укуы хакында хәбәр ителә: ***«Ул кояш тотылган вакытта укылучы намаз вакытында Коръәнне кычкырып укыды һәм ике рәкәгатьтә дүрт рокугъ һәм дүрт сәҗдә кылды».*** Килешенгән хәдис.

**Тасвирламасы:** Гайшә, Аллаһ аннан риза булсын, сүзләреннән китерелә: ***«Пәйгамбәр исән вакытта кояш тотылу булганда, ул мәчеткә китте, ә калган кешеләр аның артыннан тезелде. Ул тәкъбир әйтте һәм Коръән укуны озынайтты, шуннан соң тәкъбир әйтте һәм озак итеп рокугъта торды; шуннан соң ул башын күтәрде һәм: «Сәмига Аллаһу лимән хәмидәһ!»,— диде. Шуннан соң ул турайды һәм сәҗдәгә китмичә тагын Коръәннән озаклап укыды, тик бу юлы беренчесенә караганда кыскарак иде. Ул янәдән тәкъбир әйтте һәм рокугъка китте, ләкин бу юлы рокугъ вакыты буенча беренчесеннән кыскарак иде, шуннан соң ул әйтте: «Сәмига Аллаһу лимән хәмидәһ! Раббәнә уә ләк әлхәмд». Шуннан соң ул сәҗдә кылды һәм икенче рәкәгатьтә дә шуларны ук эшләде. Шул рәвешле ул дүрт рокугъ һәм дүрт сәҗдәне төгәлләде. Ай тотылу аның намазына караганда иртәрәк бетте». Бохари.***

Намаздан соң имамга кешеләргә вәгазь белән мөрәҗәгать итәргә һәм аларны, Пәйгамбәребез ﷺ эшләгәнчә, Аллаһка дога белән ешрак ялварырга, ешрак истигъфар кылырга һәм сәдакалар бирергә чакырырга кирәк.

## [Витр намазы]

Витр намазы катгый рәвештә үтәлергә тиешле намаз булып тора. Әлеге намазны Пәйгамбәребез ﷺ сәфәрдә дә, өйдә дә һәрчак кыла иде, башкаларны да шуңа өнди иде.

| **1.Иң аз рәкәгать** | **2.Иң күп рәкәгать** | **3.Вакыты** | **4.Хәерлерәк** |
|---|---|---|---|
| 1 рәкәгать | 11 рәкәгать | Төнге намаздан соң таң атканчыга кадәр | Аны төннең соңгы намазы итү |

Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: **«*...витр намазы төнлә укылган ахыргы намаз булсын*».** Килешенгән хәдис.

Ул әйтте: ***«Кем дә кем төннең соңгы өлешендә йоклап калудан курыкса, витр намазын төннең башында укысын. Ә кем төннең соңгы өлешендә йокыдан торуында ышанса, витр намазын төннең ахырында укысын. Чынлыкта, төннең ахырында укылган намазга фәрештәләр шаһит була, һәм әлеге вакыт та иң хәерле вакыт». Мөслим.***

## [Яңгыр сорау намазы]

Су җитмәгәнлектән кешеләр кытлык кичерә башлагач, яңгыр сорау намазы уку сөннәт булып тора. Бу намаз бәйрәм намазы кебек укыла, ачык кырда кылына, әлеге намазга басынкы, түбәнчелекле һәм буйсынучан рәвештә барырга кирәк.

| 1.Ике рәкәгатьле | 2.Шуннан соң вәгазь укыла: | | |
|---|---|---|---|
| | А. Истигъфарларны еш әйтә-әйтә бу гыйбадәтне кылырга боеручы аятьләр укыла. | Б. ныклык белән дога кылына. | В. Якын киләчәктә җавап булачагына өмет белән. |

Намазга барганчы начарлыктан котылырга һәм Аллаһның рәхмәте килүгә ярдәм итүче ошбу шартларны үтәү тиеш:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1.Истигъфар | 2.Тәүбә | 3.Гаделсезлекне туктату | 4.Кешеләргә яхшылык кылу | 5.Аллаһның рәхмәтен тартып торучы һәм явызлыкка киртә куючы башка шартларны үтәү. Аллаһ бу хакта яхшырак белә. |

**[Намаз укырга тыелган вакытлар]**

Ирекле гади намазларны үтәү өчен тыелган вакыт аралыклары:

| | | |
|---|---|---|
| 1.Кояш чыкканнан алып сөңге буекүтәрелгәнчегә кадәр | 2.Икенде намазыннан соң кояш баеганчыга кадәр | 3.Кояш күкнең уртасына җитеп зәвәл вакытына кадәр. Аллаһ бу хакта яхшырак белә. |

**Әлеге тыелган вакыт аралыкларында рөхсәт ителә:**

| | |
|---|---|
| 1.Укылмый калган фарыз намазын уку | 2.Төрле сәбәпләре булган намазларны уку: тәһарәт, мәчет намазлары, ике рәкәгать тәваф намазы, кояш тотылган вакыттагы намаз, истихара намазы. |

**Фарыз һәм ирекле намазлар арасындагы аерма:**

| № | Фарыз | Ирекле |
|---|---|---|
| 1 | Мигъраҗ кичендә боерыла | Шәригатьнең башка күрсәтмәләре кебек |
| 2 | Фарыз намазыннан нигезле сәбәпләр булмаганда чыгарга ярамый | Ирекле намаздан нигезле сәбәпләр булмаганда чыгарга тыелмаган |
| 3 | Аны калдырган кеше гөнаһлы була. | Аны калдырган кеше гөнаһлы булмый |
| 4 | Сан ягыннан чикле | Кайбер искәрмәләрдән тыш, өйдә укылса яхшырак |

| | | |
|---|---|---|
| 5-6 | Мәҗбүри рәвештә җәмәгать белән һәм мәчеттә укыла | Кайбер искәрмәләрдән тыш, өйдә укылса яхшырак |
| 7 | Хайван өстенә атланган килеш (автомобильдә утырган килеш) укырга рөхсәт ителми, бары тик зарурият булганда гына. | Хайван өстенә атланган килеш (автомобильдә утырган килеш) укырга рөхсәт. |
| 8 | Нинди генә очрак булмасын, йөз белән кыйблага юнәлү шарт булып тора. | Сәфәр вакытында йөз белән кыйблага юнәлү шарт түгел. |
| 9 | Һәр намазның үз вакыты бар | Кайберләре билгеле бер вакытта укыла, кайберләренең билгеле бер вакыты юк. |
| 10 | Фарыз намазыннан соң ирекле намазга күчү рөхсәт ителә, ләкин киресенчә булырга тиеш түгел. | |
| 11 | Игътибарсызлык нәтиҗәсендә фарыз намазын калдырган кеше, галимнәрнең дөрес фикере буенча,имансызга әйләнә. | Галимнәрнең уртак фикере буенча, ирекле намазны калдырган кеше имансызга әйләнми. |
| 12 | Ирекле намазлар фарыз намазларны тулыландыра, әмма киресенчә булган караш дөрес түгел. | |
| 13 -14 | Басып тору намазның бер әркәне булып тора, һәм бер тәслим генә җитми. | Басып тору намазның әркәне түгел, һәм бер тәслим дә җитә. |
| 15 | Качып киткән колдан кабул ителә | Качып киткән колдан кабул ителми |
| 16 | Фарыз намазга кадәр азан һәм камәт әйтелә | Намазга кадәр азан һәм камәт әйтелми |
| 17 | Сәфәрдә кыскартыла | Сәфәрдә кыскартылмый |
| 18 | Аны үтәү бурычы һичнинди шартларда да өстән төшерелми, һәм аны үтәгән өчен тулаем савабы үз көчендә булганда гадәттә үтәп барган, әмма хәзер булдыра алмаган кешегә языла. | Аны уку мөмкинлеге булмаган вакытта уку тиешлеге бетерелә һәм аны үтәгән өчен савабы үз көчендә булганда гадәттә үтәп барган, әмма хәзер булдыра алмаган кешегә языла. |

| | | |
|---|---|---|
| 19 | Барлык фарыз намазларыннан соң зикерләр укылырга тиеш | Кайбер ирекле намазлардан соң гына зикер әйтү канунлаштырылган |
| 20 | Кәгъбә эчендә уку рөхсәт ителми, дип санала, ләкин дөресрәк фикер — моның рөхсәт ителүе. | Кәгъбә эчендә уку рөхсәт ителгән |
| 21 | Ике намазны берләштерү рөхсәт ителгән | Берләштерү рөхсәт ителми |
| 22 | Савабы күбрәк | Савабы азрак |
| 23 | Намаз укыганда су эчү катгый тыела. | Укыганда аз күләмдә су эчү рөхсәт ителгән |
| 24 | Фарыз намазлары арасында бер рәкәгатьле намазлар юк. | Ирекле намазлар арасында бер рәкәгатьле намаз бар. |
| 25 | Аллаһның рәхмәте һәм җәзасы турындагы аятьләрне укып, Аллаһтан дога кылып сорарга һәм Аллаһның яклавына сыенырга рөхсәт ителгән (ләкин һәрвакыт үтәргә дип канунлаштырылмаган). | Аллаһның рәхмәте һәм җәзасы турындагы аятьләрне укып, Аллаһтан дога кылып сорарга һәм Аллаһның яклавына сыенырга рөхсәт ителгән. |
| 26 | Бәлагатькә ирешкән кешегә кечкенә малай намазда имам була алмый, әмма дөресрәк фикер — моның рөхсәт ителгәнлеге. | Бәлагатькә ирешкән кешегә кечкенә малай намазда имам була ала |
| 27 | Ирекле намазны башкаручы кешегә фарыз намазын укучы кеше өчен имам булып басарга рөхсәт ителә. | Ирекле намазны башкаручы кешегә фарыз намазын укучы кеше өчен имам булып басарга рөхсәт ителә. Ләкин кайбер намазларны каза кылырга кирәк. |
| 28 | Бөтен укылмыйча калган фарыз намазларны санынча каза кылырга кирәк. Җомга намазын каза кылу өчен өйлә намазы укыла. | Кайбер ирекле намазларны санынча каза кылырга кирәк, кайберләре исә санынча каза кылынмый, мәсәлән, витр намазы. |
| 29 | Төнге фарыз намазлар кычкырып укыла. | Төнге ирекле намазлар укучы кешенең теләге белән кычкырып та, эчтән дә укыла. |

| | | |
|---|---|---|
| 30 | Ике фикернең берсе буенча мәҗбүри рәвештә җилкәләрне капларга кирәк. | Җилкәләрне каплау мәҗбүри түгел |
| 31 | Нинди шартлар булуына да карамастан, бер намаз да төшеп калырга тиеш түгел. | Кайбер намазлар сәфәр вакытында төшеп кала. |

## ҖӘМӘГАТЬ НАМАЗЫ ҺӘМ АНЫ ҮТӘҮ

Биш вакыт фарыз намазына кагылышлы җәмәгать намазы, өйдә булганда да, сәфәрдә булганда да, ир-атларның шәхси бурычы булып тора. Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Мин җәмәгать намазын укырга, намаз белән җитәкчелек итү өчен бер кешене билгеләп куярга, ә соңыннан бер төркем кешеләрне чыбык-чабык белән намазга килмәгәннәрнең йортларын яндыру өчен җибәрергә боеруны ниятләгән идем».*** Килешенгән хәдис.

Катнашучыларның иң аз саны: имам һәм 1 мәъмум. Җәмәгать намазында катнашучылар саны күбрәк булган саен, Аллаһка да ул күбрәк ошый.

Аллаһның илчесе әйтте: «***Ялгыз укылган намазның савабына караганда җәмәгать белән укылган намазның савабы 27 тапкыр күбрәк***». Килешенгән хәдис.

Ул шулай ук әйтте: ***«Әгәр сез намазны өйдә укысагыз, шуннан соң мәчеткә килеп имамның әле намаз укымаганлыгын күрсәгез, намазны тагын имам белән бергә дә укыгыз, әлеге намаз сезгә өстәмә намаз булып торыр».*** Хәдисне «Сунан» китабының бөтен авторлары да китерә.

Әбу Хурайрадан Пәйгамбәргә кадәр барып тоташучы бер хәдистә болай дип хәбәр ителә: ***«Имам башкаларга үрнәк булсын өчен куела. Шуңа күрә...»***

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1. ***Әгәр ул Аллаһны зурласа, сез дә Аллаһны зурлагыз, һәм бу гамәлне аннан алданрак эшләмәгез.*** | 2. ***Ул рокугъка киткәч, сез дә рокугъка китегез, һәм бу гамәлне аннан алда эшләмәгез.*** | ***3. Ул: «Аллаһ Үзен мактаучыларны ишетә!» — дисә, сез: «Йә Аллаһ, Раббыбыз безнең! Сиңа барча мактау!» — диегез.*** | 4. ***Ул сәҗдәгә киткәч, сез дә сәҗдәгә китегез, һәм бу гамәлне аннан алда башкармагыз.*** | 5. ***Әгәр ул намазын утырып укыса, сез дә аның белән бергә утырырга тиеш».*** Хәдисне Әбу Давыд китерде һәм аның нигезе «Сәхихайн» да китерелә. |

**Шушыларны эшләргә кирәк:**

| | | |
|---|---|---|
| 1.Имам алгарак чыгарга тиеш | 2.Мәъмумнәр рәт-рәт тезелергә тиеш | 3. Башта алгы рәтләрне тулыландырырга кирәк |
| 4.Хатын-кызлар ир-атлардан соң рәт булып басалар. | | |

Бер сәбәпсезгә, намаз укучылар тезелгән рәтләрнең артына басып ялгызы гына намаз укыган кеше, әлеге намазын каза кылырга тиеш.

Ибн Габбас әйтте: ***«Бервакыт төнлә мин Аллаһның илчесе белән бергә намаз укырга карар кылдым һәм аның сул ягына бастым. Ул мине, баш артымнан тотып, үзенең уң ягына бастырып куйды».*** Килешенгән хәдис.

Аллаһның илчесе ﷺ әйтте: ***«Әгәр сез камәт ишетсәгез, намазга тыныч һәм абруйлы рәвештә барыгыз. Ашыкмагыз һәм имам белән намазның өлгергән өлешен укыгыз, ә калган өлешен каза кылыгыз!».*** Килешенгән хәдис. Тирмизи риваятендә исә болай диелә: ***«Әгәр сез җәмәгать намазына барсагыз, имам белән намазның өлгергән өлешен укыгыз».***

## НИГЕЗЛЕ СӘБӘПЛӘРЕ БУЛГАННАРНЫҢ НАМАЗЛАРЫ

### [Авыру кешенең намазы]

Авыру кешенең җәмәгать намазларына бармавы кичерелә.

Әгәр басып торганда авыруның сәламәтлеге начарланса, аңарга утырып укырга рөхсәт ителә, әгәр дә авыруның утырып укырга да мөмкинлеге булмаса, ул намазын кырын ятып укый ала. Пәйгамбәребез ﷺ Гыймран ибн Хусанга болай диде: ***«Намазны басып укы, әгәр булдыра алмасаң, утырып укы, әгәр утырып та укый алмасаң, намазыңны кырын яткан килеш укы». Хәдисне Бохари китерә.***

Әгәр авыру кешегә барлык намазларны да үз вакытында укып бару читен булса, ул аларны берләштерә ала: өйләне икенде белән, ахшамны ястү белән. Намазлар бу очракта икесенең берсенең вакытында укыла.

### [Мосафирның намазы]

Шулай ук мосафир кеше дә намазларны берләштерә ала: [өйләне икенде белән, ахшамны ястү белән. Намазлар бу очракта икесенең берсенең вакытында алдан яки бераз кичектереп укыла].

Шулай ук мосафирга дүрт рәкәгатьле намазларны ике рәкәгатьлеккә кадәр кыскарту тиешле.

Һәм ул Рамазан аендагы уразасын да тотмаска мөмкин, [ләкин аны Рамазан аеннан соң башка вакытта каза кылырга кирәк].

### [Курку намазы]

Курку намазын Пәйгамбәребез башкарган рәвешләрдә укырга кирәк.

Мәсәлән, Салих ибн Хаввват хәдисендә **«Зат әр-Рикагъ»** сугышында Пәйгамбәр ﷺ белән бергә курку намазын укыган кешедән хәбәр ителә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «***Ул кичә пәйгамбәр белән бергә намаз укырга дип тезелеп баскан төркем белән бер рәкәгать укыды, ә икенче төркем дошман каршында басып калды.*** | ***Ул үзе белән булган төркем белән бер рәкәгать укыды,*** | ***шуннан соң басып калды, ә калганнар намазларын үзләре төгәлләде,*** | ***шуннан соң кителәр һәм дошман каршысына тезелеп бастылар.*** | ***Шуннан соң башка төркем килде, һәм ул алар белән бергә калган рәкәгатьне укыды,*** | ***шуннан соң утырган рәвештә калды, калганнар намазларын укып бетерде,*** | ***шуннан соң аның белән бергә сәлам бирделәр***». Килешенгән хәдис. |

«***Әгәр куркуыгыз көчле булса, ул вакытта намазыгызны аякта килеш булса да, хайваннарга атланган килеш тә, кыйблага юнәлгән халәттә дә, юнәлмичә дә, рокугъ һәм сәҗдә ишарәләре ясап укыгыз***».

Шул рәвешле үзе өчен курыккан һәркем, нинди шартларда булуына карап, намаз укый ала. Бу очракта ул үзенә кирәкле төрле хәрәкәтләр эшләргә мөмкин, әйтик: йөгерергә һәм башкалар.

Аллаһның илчесе ﷺ әйтте: «***Әгәр мин сезгә ни булса да боерсам, аны үзегезнең мөмкинлегегездән чыгып үтәгез***». Килешенгән хәдис.

# ҖОМГА НАМАЗЫ

Җәмәгать намазына бару йөкләтелгән һәркем, әгәр туган җирендә, үз йортында яшәсә, җомга намазына да барырга тиеш.

**Җомга намазының шартларына түбәндәгеләр керә:**

| | | |
|---|---|---|
| 1.Үз вакытында үтәү | 2.Ниндидер бер җирлектә үтәлергә тиеш | 3.Ике хөтбәдән соң башкарыла |

**Җәбир сүзләреннән хәбәр ителә, Пәйгамбәр ﷺ хөтбә укыган вакытта:**

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1.***Аның күзләре кызара, тавышы көчәя һәм ул, башкаларны «Дошман иртән киләчәк!» яки «Дошман кичтән киләчәк!» — дигән сүзләр белән кисәткән кебек нәфрәтләнә иде.*** | 2.***Һәм ул әйтә иде: «Шуннан соң, хакыйкатьтә, иң күркәм сүзләр Аллаһның китабында, иң яхшы кулланма ул — Мөхәммәд ﷺ кулланмасы, иң начар эш — бидгать, ә һәрбер бидгать адашудыр!»*** Хәдисне Мөслим китерде. | 3.Әлеге хәдиснең башка риваятендә болай хәбәр дип бирелә: ***«Җомга көнне Аллаһ илчесе үзенең хөтбәсендә Аллаһны мактый һәм хәмед-сәнәләр әйтә иде, шуннан соң көчле тавыш белән сөйли башлый иде».*** | 4. Башка риваятьтә исә болай китерелә: ***«Кемне Аллаһ туры юлга күндерә, аны беркем дә адаштыра алмас, ә кемне адаштырса, беркем дә аны туры юлга кертә алмас».*** | 5.Ул әйтте: ***«Чынлыкта, намазны озынайтып хөтбәне кыскарту динне тирәнтен аңлауның бер билгесе булып тора».*** Хәдисне Мөслим китерде. |

Хөтбәне минбәрдә басып торып укырга тиешле. Аңарга күтәрелгәндә кешеләргә борылырга һәм аларны иң күркәм сәлам белән сәламләргә кирәк.

Шуннан соң имам утыра, ә мәзин азан әйтә, шуннан соң имам тора һәм хөтбә укый, шуннан соң кыска вакытка гына утыра, шуннан соң икенче хөтбәне укый.

Шуннан соң җомга намазы башкарыла. Имам башкалар белән бергә, кычкырып, ике рәкәгать намаз укый. Беренче рәкәгатьтә «Әл-фатиха»дан соң «Әл-Агълә» сүрәсен, ә икенче рәкәгатьтә — «Әл-Гашийә» яки «Әл-Җомга» һәм «Әл-Мунафикин» сүрәләрен уку хәерлерәк.

**Җомга намазына килүче кешегә ошбу гамәлләрне үтәү тиешле:**

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1.Госел коенырга. | 2.Ислемайлар сөртергә. | 3.Иң яхшы киемне кияргә. | 4.Мәчеткә иртәрәк барырга. |
| 5.Пәйгамбәребезгә ﷺ күп итеп салаватлар әйтергә. | | 6.Бу көндә «Әл-Кахф» сүрәсен укырга. | |
| 7.Барлык догалар да кабул була торган сәгатьне туры китерергә һәм шул вакытта Аллаһтан күбрәк сорарга. | | | |

«Сахихайн»да мондый хәдис китерелә: ***«Әгәр җомга көнне имам хөтбә укыганда янәшәдә утыручы кешегә: «Дәшмә!» — дисәң, син үзең буш сүз сөйләүче хөкемендә булырсың».***

Бервакыт бер кеше мәчеткә керде, бу вакытта Пәйгамбәр ﷺ инде хөтбә укый башлаган иде. Пәйгамбәр ﷺ аннан сорады: ***«Син намаз укыдыңмы?»*** Ул: «Юк!» — дип җавап бирде. Шунда Пәйгамбәр ﷺ әйтте: ***«Бас һәм ике рәкәгать намаз укы».*** Килешенгән хәдис.

**Җомга хөтбәсе укылган вакытта намаз укучыга түбәндәгеләр тыела:**

| | |
|---|---|
| 1.Имамга мөрәҗәгать итүдән тыш сөйләшергә. | 2.Утырган кешеләрнең җилкәләре аша атлап үтәргә. |

## БӘЙРӘМ НАМАЗЫ

***Пәйгамбәр ﷺ бәйрәм намазын үтәү, изге эшләрдә һәм мөселманнарның Аллаһка дога кылып мөрәҗәгать итүләрендә катнашсыннар өчен хәтта колларга һәм хәез вакыты булган хатын-кызларга да чыгарга боерды. Әмма хәез вакыты булган хатын-кызларга намаз укыла торган урыннан ераграк булырга кирәк.*** Килешенгән хәдис.

Бәйрәм намазының үтәлү вакыты:
Кояш чыгып сөңге буе күтәрелгәннән алып зәвәл вакытына кадәр.

**Әлеге гамәлләрне үтәү тиешле:**

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.Намазны ачык җирдә уку. | 2.Корбан гаете көнендә бәйрәм намазын иртәрәк уку. | 3.Ураза гаетендә бәйрәм намазын озаккарак сузу. | 4.Бигрәк тә Ураза гаете көнне намазга кадәр өч хөрмә җимеше (финик) белән генә булса да авыз ачу. | 5.Исле-майлар сөртелгән чиста кием кию. | 6.Иң яхшы киемнәрне кию. | 7.Намазга барганда бер юлдан, кайтканда икенче юлдан кайту. |

Бәйрәм намазы ике рәкәгать итеп азан һәм камәтсез укыла. Беренче рәкәгатьтә 7 тәкъбир әйтергә, ә икенче рәкәгатьтә, икенче рәкәгатьне үтәү өчен әйтелгән тәкъбирне санамыйча, 5 тәкъбир әйтергә кирәк. Һәрбер тәкъбирне әйткәндә кулларны күтәрергә һәм һәр ике тәкъбир саен Аллаһны мактарга һәм Пәйгамбәребезгә ﷺ салаватлар әйтү тиешле. Шуннан соң кычкырып «әл-фатиха» һәм башка бер сүрәне укырга кирәк.

Намаздан соң җомга хөтбәсенә охшашлы ике хөтбә укырга тиешле, әмма әлеге хөтбәләрдә шушы вакытка тәңгәл килерлек күрсәтмәләр бирергә кирәк.

**Тәкъбирне әйтү тиешле:**

| | |
|---|---|
| **1.Гадәти:** бәйрәмгә каршы төндә һәм Зөл-хиҗҗә аеның һәр 10 көнендә. | **2.Билгеле бер:** Гарәфә көненең таңы атканнан алып соңгы тәшрик көненең икенде намазына кадәр һәр фарыз намазыннан соң. |
| **Тәкъбирнең формасы:** Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр. Лә иләһә иллә Ллаһ уә-Ллаһу әкбәр, уә ли-Лләһи әл-хәмд. | |

## НАМАЗ КИТАБЫ БУЕНЧА СОРАУЛАР

| Сорау | Дөрес | Дөрес түгел |
|---|---|---|
| — Билгеләнгән инанганлык шуның киресендә инану белән генә бетерелә ала.<br>— Шәхси бурыч (фард ’айн) җәмәгать бурычына (фард кифая) караганда яхшырак.<br>— Берничә төрле үтәү варианты булган гыйбадәтне кеше шушы барлык вариантларга да муафыйк рәвештә үтәргә тиеш.<br>— Теләсә-кайсы намазны кергән вакытында ук уку тиешле, шуңа күрә азан белән камәт арасында зур өзеклек булмаска тиеш.<br>— Азан — ул шәхси бурыч.<br>— Мосафирга камәт әйтү шәригатьтә канунлаштырылмаган.<br>— Азан Мәдинәдә һиҗрәттән соң беренче елда боерылды.<br>— Мәзин артыннан камәтне кабатлап бару тиешле.<br>— Икенде намазын уку өчен вакыт өйлә намазыныкыннан күбрәк.<br>— Тышкы яктан имансызларга охшау эчке яктан да аларга охшауга китерә.<br>— Кешенең эчендә калучы нәҗеснең зыяны юк.<br>— Җәмәгать белән бергә кылынган үтәргә тиешле намазлар башка намазларга караганда катгыйрак.<br>— Матур тавышлы имам эзләү нияте белән мәчетне алыштырырга ярый.<br>— Имам белән элемтәгә керергә мөмкинлек була торып, ул соңга калганда намаз укырга ярый.<br>— Пычракны чистартырга оныткан кешенең намазы дөрес түгел. | | |

— Намаз укыган вакытта сүзләрнең мәгънәләрен үзгәртүче хаталар җибәргән имам артыннан укылган намаз дөрес түгел.

— Мосафирның да, өйдә булган кешенең дә намазда имам булып басарга бердәй хокукы бар.

— Намазда балаларга өлкәннәр артыннан басарга кирәк.

— Намазы дөрес булган һәркем, әгәр каршылыклар булмаса, намазда имам булып баса ала.

— Төрле шартларга бәйле рәвештә хөтбәне озынайту имамның фикхны аңламаганлыгын белдерә.

— Хайваннарга охшашлык шелтәләү формасында гына килә.

— Ибнуль Кайим әйтте: ***«Мәчетләргә минбәр куелганнан соң Пәйгамбәр башка нәрсәгә сөялмәде, таянмады».***

— Ураза гаетендә намазны тизләтеп, Корбан гаетендә, соңрак укырга кирәк.

— Беренче рәкәгатьтә, кереш тәкъбирне дә кертеп, 6 тәкъбир, икенче рәкәгатьтә, сәҗдәдән торганда әйтелә торган тәкъбирне дә кертеп, 5 тәкъбир әйтелә.

— Кояш тотылу вакытындагы намазның асыл мәгънәсе Аллаһның Үзенең колларын куркытуында.

— Кояш тотылган вакытта укылучы намазның бер шарты булып җәмәгать белән уку тора.

— Теге яки бу сәбәп белән бәйле гыйбадәтләр, сәбәпләре үтү белән, кылынмыйлар.

— Кояш тотылган вакытта укый торган намазны намаз уку өчен тыелган вакытларда кылырга ярамый.

— Яңгыр сорау намазының бер шарты булып аның җәмәгать белән укылуы тора.

— Кешегә беренче яңгыр яуганда яңгыр астында тору һәм үзенең атланып йөри торган хайванын алып чыгу тиешле.

— Бер рәкәгатьтә бер сүрәдән артык уку рөхсәт ителә.

— Өйлә намазының вакытыдәвам итә:

Предметларның шәүләләре үзләренең озынлыгы кебек булганчы ___,

Предметларның шәүләләре үз озынлыкларыннан ике тапкыр артык булганчы ___,

Зәвәлгә кадәр___.

— Икенде намазын вакыты кергәч тә уку:

тиеш___, хәерле түгел___, мәҗбүри___.

— Намазның шартлары үтәлә:

Намазга кадәр___, намаздан соң___, укыган вакытта___.

— Тыелган нәрсәләр рөхсәт ителә: кискен ихтыяҗ булганда___, гадәти ихтыяҗ булганда___.

— Имам белән бергә җомга намазының бер рәкәгатен үтәргә өлгергән кеше, аны тәмамларга тиеш: җомга намазы кебек___, өйлә намазы кебек___. Ә имам белән аннан да азрак өлешен укыргаөлгерсә, аны тәмамларга тиеш: җомга намазы кебек___, өйлә намазы кебек___, өйлә намазы укырга дип ниятләсә, өйлә намазы кебек ___.

— Җомга намазында хөтбә укучы имам ничә тапкыр утырырга тиеш: 1 тапкыр___, 2 тапкыр___.

— Имам җомга намазын берничә тапкыр укырга рөхсәт бирсен өчен шарт китерелә: дин тарафыннан___, дәүләт строе тарафыннан___, икесе белән дә___.

— Бәйрәм намазлары шундый гыйбадәтләргә керәләр ки, аларның: вакыты___, сәбәбе___, төре___ бар.

— Ислам динендә бәйрәмнәрнең саны: өч__, ике__, күп__.

— Җиңгәч яки җиңелгәч бәйрәм үткәрүләрнең хөкеме: рөхсәт ителгән_____, тыелган_____.

— Бәйрәм намазлары: җәмәгатьнең бурычы___, шәхси бурыч___, сөннәт___.

— Сәбәбе булган һәр намаз да, сәбәбе үтүгә: кире кайтарылып укылмый___, укыла___.

— Ураза гаетендә сөннәт булып тора: бер финик ашау___, өч һәм аннан да күбрәк финик ашау___;

Моны: бәйрәм намазына кадәр___, бәйрәм намазыннан соң___ эшләргә кирәк;

Моның асыл мәгънәсе: сөннәткә иярүдә____, мәҗбүрине ирекледән аерып күрсәтүдә ___, икесендә дә___чагыла.

— Бәйрәм намазларында бу сүрәләрне уку тиеш: «Әл-Ә'лә» һәм «Әл-Гашийә»_____, «Каф» һәм «Әл-Камәр»_____, яки әлеге сүрәләрнең берсен_____.

— Бәйрәм намазына кадәр яки аннан соң, шул ук урында калып, ирекле намазлар уку: сөннәт____, рөхсәт ителгән____, үтәлмәсә яхшырак___;

Әмма бәйрәм намазы укылачак урында мәчет намазыуку: фарыз___, сөннәт___, бөтенләй укылмый____.

— Кояш тотылу турында кешеләргә хәбәр итү___, хәбәр итмәү___ хәерлерәк.

— Кояш тотылу намазы шундый гыйбадәткә керә ки, аның: вакыты____, сәбәбе_____, төре____ бар.

— Әгәр астрологлар кояш тотылуы турында алдан хәбәр бирсәләр, без аны үз күзләребез белән күрмичә торып намаз укымыйбыз ___, күрмәсәк тә намаз укыйбыз___.

— Кояш тотылу намазы хөкеме: шәхси бурыч___, җәмәгать бурычы___, сөннәт___.

— Кояш тотылган вакытта хөтбә: шәригатьтә юк___, сөннәт__, фарыз___.

— Әгәр кояш тотылу хакында кояш тотылу үткәч кенә билгеле булса: намаз каза кылына___, каза кылынмый____.

— Әгәр кояш тотылу намазын кылган вакытта фарыз намазы вакыты җитсә: кеше кояш тотылу намазын өзәргә тиеш___, тиз генә тәмамларга тиеш___, фарыз намазы вакыты чыгып китмәгәнлеккә инанып, намаз укуын дәвам итәргә тиеш ___.

— Әгәр кояш кояш тотылу халәтендә баеса: шәригатьтә канунлаштырылган___ канунлаштырылмаган___.

— Беренче рокугътан соң булган гамәл: әркән була___, сөннәт була___.

| | | |
|---|---|---|
| — Яңгыр сорау намазы шундый гыйбадәткә керә ки, аның: вакыты____, сәбәбе_____, төре____ бар.<br>— Яңгыр сорау намазының хөкеме: шәхси бурыч___, җәмәгать бурычы___, сөннәт____.<br>— Яңгыр намазын үтәүгә чакыру: сөннәт___, бидгать___.<br>— Азанның хөкеме: сөннәт___, җәмәгатьбурычы___, шәхси бурыч___.<br>— Намазның әркәннәре һәм фарыз гамәлләре бер нәрсәдә тәңгәл килә: белмәүдә____, онытылуда___, аңлы рәвештә булуда___.<br>— Намаз укырга тыелган вакытларда ирекле намазлар рөхсәт ителә: барысы да___, кайберләре генә___.<br>— Намазда кулларны күтәрергә кирәк: 4 урында_, 3 урында___.<br>— Намаз вакыты кергәннән алып чыкканчыга кадәр кеше аңсыз халәттә булса: намазын кайтарырга тиеш___, кайтарырга тиеш түгел___.<br>— Намаз вакытында күзләрне йому хөкеме: рөхсәт ителгән___, рөхсәт ителмәгән___. | | |

# ЖЕНАЗА КИТАБЫ

## [ҖЕНАЗА КИТАБЫ]

| Мөселман кешесе вафат булганнан соң шәригать хөкемнәре: | | |
|---|---|---|
| **1.Үлем алдыннан** Кайбер гамәлләр боерылды: авыру кеше янына бару, тәүбә турында һәм васыять язуы хакында, чистарыну ысуллары һәм намазны ничек укырга кирәклеген исенә төшерү, авыруны, бигрәк тә моны ул үзе теләсә, Коръән укып дәвалау һәм «Аллаһтан башка табынырга лаеклы зат юк»,— дигән сүзләрне исенә төшерү. | **2.Үлем вакытында** Кайбер гамәлләр боерылды: күзен йомдыру һәм сакалын бәйләү. | **3.Үлемнән соң** Ошбу гамәлләр боерылды: мәрхүмне юу, кәфенгә төрү, җеназа намазы башкару, аны җирләү, мирас малын бүлү, хатынына матәм тоту тиешле, туганнарының кайгыларын уртаклашу һәм каберен зиярат кылу. |

Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Үлем түшәгендә ятучы кардәшләрегезгә үлем алдыннан: «Аллаһтан башка табынырга лаеклы зат юк»,***— дигән сүзләрне әйтү кирәклеге хакында үгет-нәсихәт бирү [Бу сүзләрне өч тапкыр әйтергә кирәк]. Мөслим.

Ул шулай ук әйтте: ***«Вафат булган кардәшләрегезгә «Ясин» сүрәсен укыгыз»***. Нәсаи һәм Әбу Давыд.

**Искәрмә:** Күпчелек галимнәрнең фикеренчә, «Ясин» сүрәсен уку турындагы хәдис көчсез һәм аргумент буларак китерелә алмый. Вафат булган кешегә бу сүрәне уку Шәригатьтә канунлаштырылмаган дигән фикер дөресрәк.

**Мәетне әзерләүгә түбәндәгеләр кирә:**

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1.Аны юу | 2.Кәфенлеккә төрү | 3.Җеназа намазы уку | 4.Зиратка илтеп җиткерү | 5.Җирләү |

**Җәмәгать бурычы булып тора.**

Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Мәетне тизрәк алып барыгыз, чөнки әгәр ул иманлы булган булса, сез аны аның нигъмәтенә илтәсез, әгәр дә ул иманлы булмаса, сез тизрәк үз җилкәгездән явызлыкны алып ата алырсыз».*** [ Хәдисне «Сунан»ның кайбер авторлары китерде.]

Ул шулай ук әйтте: ***«Иманлы бәндәнең җаны аның әҗәте белән бәйле булыр, шул әҗәт түләнгәнчегә кадәр».*** Әхмәд һәм Тирмизи.

Мәетне кәфенлеккә төргәндә ир-атларның башыннан башка калган җирен, хатын-кызларның йөзләреннән башка бар җирләрен капларга кирәк.

**Җеназа намазы тасвирламасы:**

<table>
<tr><td colspan="2">1.Басарга, тәкъбир әйтергә һәм «әл-фатиха» сүрәсен укырга.</td><td colspan="2">2.Шуннан соң тагын бер тәкъбир әйтергә һәм Пәйгамбәргә ﷺ салаватлар әйтергә.</td></tr>
<tr><td colspan="3">3.Шуннан соң тәкъбир әйтергә һәм вафат булган кеше өчен ошбу доганы кылырга кирәк:</td><td rowspan="2">4.тәкъбир һәм тәслим әйтергә [1 яки 2 тәслим]</td></tr>
<tr><td>Аллаһуммә-гфир ли-хаййинә вә мәййитинә, вә сагыринә вә кәбири-нә, вә закәри-нә вә унса-нә, вә шәхиди-нә вә гаиби-нә, Аллаһуммә, мән әхйәйта-ху мин-нә фә-ахйи-хи галә-ль-исләм, вә мән тавәффәйта-ху мин-нә фә-тавәффә-ху галә-ль-имән</td><td>Аллааһуммә-гфир ләху вәрхамх, вә гаафихи вәгъфугәнх, вә әкрим нузуләһу вә вәссигъ мудхаләһу, вәгсыльһу биль-мәги вәс-сальджи вәл-бәрад, вә нәккыхи минәл-хатайә кәмә юнәккә ссавбуль-әбъяду минәд-данәс. Аллааһуммә ләә тахримнәәәджраху вә ләәтафтиннә багъдаху вә гфир ләнә вә ләху.</td><td>Әгәр вафат булучы кечкенә бала булса, гомуми догадан соң ошбу сүзләрне өстәргә кирәк:<br><br>Аллаһуммәа дж'әльху фәратан ли-вәлидәйхи, вә зухран вә шәфи'ан муджәбән. Аллаһуммә саккиль би-хи мәвәзинахумәвә агъзым би-хи уджурахумә вә джгәльху фи кафәләти Ибраһим вә кы-хи би-рахмәтикә'азабә әл-джәхим.</td></tr>
</table>

| | | | |
|---|---|---|---|
| *Мәгънәсе: Йә Аллаһ, безнең исән-нәребезне һәм вафат булган-нарны, кече һәм өлкәннәрне, ир һәм хатын-кызларны, бирердә булган-нарны һәм булма-ганнарны гафу әйлә. Йә Аллаһ, Син исән калдырган-бәндәләреңә ислам динендә яшәргә ярдәм ит, вафат иткәннәребезне иманлы итеп вафат кыл.* | *Мәгънәсе: Йә Аллаһ, гафу әйлә аны, рәхмә-теңнән ташлама һәм якла. Аңа карата юмарт бул. Аның кабе-рен киң кыл. Аны су, кар һәм боз белән юын-дыр. Ак киемне пычрактан чистарткан кебек аны гөнаһларыннан чистарт. Йә Аллаһ, аның өчен булган әҗер-саваптан мәхрүм итмә һәм аннан соң безне кот-кыга салма.* | *Мәгънәсе: Йә Аллаһ, әлеге баланы ата-ана-сына Җәннәттә урын әзерләүче, кыйммәтле хәзинә, яклавына җавап бирелүче яклаучы ит. Аның әти-әнисенең изге эшләре тәлинкәсен авыр ит, әлеге бала өчен әҗер-савапларын арт-тыр. Йә Аллаһ, әлеге баланы Ибраһимның кайгыртуы астына куй һәм Үзеңнең рәхмәтең-белән аны Җәһәннәм газабыннан сакла.* | |

Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әгәр җеназа намазын Аллаһка һичкемне дә тиңдәш кылмаган кырык ир-ат башкарса, Аллаһ аларны мәрхүм өчен яклаучы итәчәк».*** Мөслим.

**Ул шулай ук әйтте:**

| | |
|---|---|
| ***Кем дә кем җеназа намазы укыл-ганчы башкарыла торган мәетне җирләү эшләрендә катнашса, бу кеше әҗергә кират алыр.*** | ***Ә кем мәетне җирләүдә аны җиргә иңдергәнчегә кадәр катнаша, бу кеше әҗергә ике кират алыр.*** |
| Аннан: «Ә нәрсә соң ул ике кират»? — дип сорадылар. Ул: ***«Алар ике зур тауга тиң»,***— дип җавап бирде. Килешенгән хәдис. | |

**Пәйгамбәр ﷺ тыйды:**

| | | |
|---|---|---|
| **1.Каберне гипс белән капларга** | **2.Кабергә утырырга** | **3.Кабер өстендә биналар төзергә.** Мөслим |
| 4.Кабергә язарга. | 5.Каберне яктыртырга | 6.Аның өстендә мәчет салырга |
| 7.Аның өстендә яки аңа таба юнәлеп намаз укырга. | | |

**Искәрмә:** Нигездә зират, ширек кылу куркынычы булмасын өчен, биналардан читтә урнашырга тиеш, һәм каберләр дә Сөннәткә муафыйк рәвештә тигезләнергә тиеш, ягъни бер карыш биеклегеннән дә калкурак булырга тиеш түгелләр, һәм алар алдына зур булмаган гына таш куелырга тиеш (бер яки ике).

Мәрхүмне җирләгәннән соң Пәйгамбәр ﷺ кабер өстенә баса һәм әйтә иде: ***«Кардәшегез өчен истигъфар сорагыз, Аллаһтан аның ныклыгын сорап дога кылыгыз, чөнки аннан хәзер сорау алалар».*** Хәдисне Әбу Давыд китерде, ә Хәким аны дөрес дип атады.

Бер тапкыр барып [ә бер җирдә җыелышып һәм табын артында түгел], мәрхүмнең туганнарының кайгыларын уртаклашырга тиешле.

Пәйгамбәр ﷺ үзенең мәрхүмнәре өчен елады һәм болай дип әйтә иде: ***«Бу — нигъмәт»,*** әмма үксеп елаучыларны һәм аларны тыңлаучыларны каргады.

Ул әйтте: ***«Каберләрне зыярат итегез, чөнки алар безгә кабер тормышы турында искә төшерә».*** Мөслим.

Каберләрне зыярат итүчегә ошбу сүзләрне әйтергә кирәк:

**Әс-саләму ‘аләйкум әхлә дари каумин муъминин, вә иннә ин шә’а-Ллаху би-кум ләхыкун, вә ярхаму- Ллаху-ль-мустакдиминә мин-нә вә-ль-мустаъхиринә. Нәс'әлү Ллаһа ләнаә уә ләкум әл-’афия. Аллаһуммә лә тахримнә әдҗрахум уә лә тафтиннә бә’дахум вә гфир ләнә уә ләхум. Нәс'әлү Ллаһа ләнә уә ләкум әл-’афия.**

*Мәгънәсе: Аллаһның сәламе булсын сезгә, иманлы бәндәләр. Без дә Аллаһ теләсә, сезгә кушылырбыз, Аллаһ сезне, иртәрәк киткәннәрне дә, безне, соңга калганнарны да кичерсен. Аллаһтан безнең өчен дә, сезнең өчен дә иминлек сорыйбыз. Йә Аллаһ, безне алар өчен булган әҗер-саваптан мәхрүм итмә һәм алардан соң безне коткыга салма, һәм аларның да, безнең гөнаһларыбызны ярлыка. Аллаһтан үзебез өчен дә, сезнең өчен дә иминлек сорыйбыз.*

Әгәр каберлекләрне зыярәт иткән кеше Аллаһка якынайтучы гамәлләр кылса һәм әлеге гамәле өчен әҗерне исән яки вафат мөселманга бирсә, бу аларның икенчесенә файда китерәчәк, Аллаһ бу хакта яхшырак белә.

| **Каберлекләрне зыярат кылу төрләре:** | | |
|---|---|---|
| 1.Шәригатьтә канунлаштырылган<br><br>— сәфәргә чыгып китмичә үлемне искә алу нияте белән һәм Сөннәткә муафыйк рәвештә мәрхүм булганнар өчен дога кылу нияте булса һәм Шәригатькә каршы килә торган артык бер нәрсә дә кылынмаса. | 2.Бидгать<br><br>— каберләр янында Аллаһка дога белән мөрәҗәгать итү. | 3.Ширек<br><br>— каберлекләрне зыярат кылганда мәрхүмгә дога һәм үтенеч белән мөрәҗәгать итү. |

**Искәрмә:**

— Җеназа намазы укыганда имам вафат булган ир-атның башы белән бер тигезлектә, ә хатын-кызның гәүдәсенең уртасы тигезлегендә басу хәерлерәк.

— Хатын-кызларга каберлекләргә бару тыела, чөнки Аллаһның илчесе: ***«каберлекләрне зыярәт итүче хатын-кызларны каргады»,*** чөнки аларның каберлекләргә килүләре коткыга бирелү һәм сабырсызлык белән куркыныч.

— Шулай ук хатын-кызларга мәетне зиратка кадәр озатырга тыела, чөнки Аллаһның илчесе ﷺ аларга моны тыйды.

— Җеназа намазын мәчеттә яки өйдә укуга килгәндә, бу мәсьәлә ир-атлар өчен дә, хатын-кызлар өчен дә Шәригатьтә канунлаштырылган.

— Аллаһның илчесе ﷺ үлем теләүне тыйды, ул әйтте: ***«Беркем дә ниндидер бәла-казага юлыгу аркасында үзенә-үзе үлем теләмәсен. Әмма әгәр бу хәлдән башка чыгу юлын күрмәсә, Аллаһтан ошбу сүзләрне әйтеп, дога белән сорасын: «Йә Аллаһ, минем өчен нигъмәт булган вакытта миңа гомер бир, әгәр дә минем өчен [бу очракта] хәерле булса, миңа үлем бир».*** Килешенгән хәдис.

— Кеше үлемгә әзерләнү һәм мәңгелек тормыш өчен гамәлләр кылу өчен үлем турында искә алырга. Бу аңа күңел төшенкелеге өстәмәячәк, ләкин уңыш бирәчәк. Аллаһның илчесе ﷺ әйтте: ***«Ләззәтләрне җимерүче үлемне еш искә алыгыз»***. Хәдисне «Сунан» китапларының кайбер авторлары китерде.

## ҖЕНАЗА КИТАБЫ БУЕНЧА СОРАУЛАР

| Сорау | Дөрес | Дөрес түгел |
|---|---|---|
| — Авыру кешедән аның тәһарәт алуы һәм намаз укуы ни рәвешле булуын сорау, кеше эшенә тыкшыну була.<br>— Авыруның хәлен белгәндә, бу авыруның якын туганмы яки ерак туганмы булуында аерма юк.<br>— Сәфәрдәге туганын көтеп җиткерү өчен мәрхүмне җирләргә әзерләүне кичектереп торырга рөхсәт ителә.<br>— Мәрхүмнән соң җитәкчелек итәргә тиешле варис билгеле булмаса, дәүләт җитәкчесен җирләүне кичектерергә рөхсәт ителә.<br>— Үз-үзенә кул салучы кешегә имам җеназа намазын укырга тиеш түгел.<br>— Җеназа намазын, мәчеттә, әгәр ул пычранмаса, укырга ярый.<br>— Мәрхүм өчен елау рөхсәт ителгән.<br>— Мәрхүм, ләхеткә куйганда, йөзе белән кыйблага каратылып куелырга тиеш.<br>— Әгәр кеше Аллаһка якынайтучы гамәлләр кылса һәм әлеге гамәле өчен әҗерне исән яки вафат мөселманга бирсә, бу аңа файда китерәчәк.<br>— Хәлен белергә килергә тиешле авыру: барлык авырулар да___, авыру сәбәпле урамга чыга алмаган авырулар___.<br>— Мәрхүмнең әҗәтләрен түләү: мәҗбүри___, тиешле___, рөхсәт ителгән___.<br>— Үлем түшәгендә ятучыга тәүхид сүзләрен искә төшерү: мәҗбүри___, тиешле____, тыелган___.<br>— Үлем түшәгендә ятучыга тәүхид сүзләрен йошак кына искә төшерү: мәҗбүри___, тиешле___, рөхсәт ителгән___, тиешле, ләкин 3 тапкырдан да артыграк түгел____. | | |

| | | |
|---|---|---|
| — Үлем түшәгендә ятучы кешегә тәүхид сүзләрен искә төшерергә кирәк: һәрдаим____, 3 тапкыр ___, беренче тапкыр искә төшергәннән соң телгә килсә___. — Үлем түшәгендә ятучы кешегә тәүхид сүзләрен искә төшерү ул: «Аллаһтан башка табынырга лаеклы зат юк» дип әйтү___, «әйт» сүзеннән башка аның янында шәхәдәт әйтү ____, «әйт» сүзеннән башка шәхәдәт турында исенә төшерү ___. — Мәрхүмне җирләү: бурыч___, сөннәт___, җәмәгать бурычы___. — 4 айдан соң бала төшү хөкеме: юарга кирәк түгел һәм җеназа намазы укылмый____, юарга кирәкми, әмма җеназа намазы укыла___, юарга да, җеназа намазы укырга да кирәк___. — Мәрхүмне юарга ярдәм итмәүчеләрнең шунда булуы: тыелган___, рөхсәт ителгән___, тиеш түгел___. | | |

# ЗӘКӘТ КИТАБЫ

## ЗӘКӘТ КИТАБЫ

<table>
<tr><td colspan="6">Зәкәт ике төрле була:</td></tr>
<tr><td colspan="5">Мәҗбүри, ул үзе ике төргә бүленә:</td><td rowspan="3">Ирекле<br>Гыйбадәт кылу максаты белән генә түләнгән зәкәт.</td></tr>
<tr><td colspan="4">1.Мал-мөлкәттән зәкәт,<br>Аның күләме Шәригать тарафыннан билгеләнгән: Шәригать тарафыннан каралган билгеле бер категория кешеләр яки конкрет юнәлеш файдасына мәҗбүри өлеш түләү юлы белән Аллаһ Тәгаләгә гыйбадәт кылу. Бу исламның 3нче әркәне һәм аның 4 төре бар:</td><td rowspan="2">2. Фитр сәдакасы,<br>ул Ураза гаете көнне бирелә.<br>Һәр мөселман өчен, олы кеше өчен дә, балалар өчен дә, ир-атлар яки хатын-кызлар өчен дә, мөселманның кол яки ирекле булуына карамастан, мәҗбүри</td></tr>
<tr><td>А.Алтын һәм көмештән һәм аларны алыштырып килгән нәрсәләрдән, мәсәлән, акча һәм башкалар. Алтынның нисабы — 1 мискал (85 гр.), ә көмешнеке — 200 дирхәм (595 гр.)</td><td>Б.Елның күп айларын яки ел әйләнәсе рөхсәт ителгән территорияләрдә утлап йөргән хайваннардан, Болар: дөя, сыер һәм сарыклар.</td><td>В.Җирдә үсә торган азык-төлектән: бөртекле культуралар һәм җиләк-җимеш.</td><td>Г.Сәүдә товарларыннан: сату-алу өчен яраклы булган бөтен нәрсәдән.</td></tr>
</table>

**Кайбер затлар һәм бөтен җәмгыять өчен зәкәтнең файдасы, шулай ук аның хикмәте түбәндәгедән гыйбарәт:**

1.Аллаһның колының буйсынуының тулылыгы һәм камиллеге.

2.Зәкәт бирүченең ихлас иманын дәлилли.

3.Зәкәт бирүченең әхлагы чистара.

4.Мал-мөлкәте чистара.

5.Калебе ачыла.

6.Кешене камил иманлы итә

7.Җәннәткә керергә бер сәбәп була.

8.Гөнаһларны бетерә.

9.Мөселман җәмгыятен, бер гаилә кебек, берләштерә.

10.Ярлыларны юашландыра.

11.Финанс җинаятьләрне кисәтә.

12.Кубарылу көнендәге челлә эсседән коткара.

13.Начар үлемнән саклый.

14.Кешене Аллаһ һәм аның боерыклары чикләрен аңлауга китерә.

15.Нигъмәтләр килүенә сәбәп була.

16.Раббыбызның ачуыннан саклый.

17.Күктән төшүче бәлалар белән көрәшә һәм аларның җиргә төшүенә киртә була.

# МАЛ-МӨЛКӘТТӘН ЗӘКӘТ

Түбәндә саналган һәр кешегә мәҗбүри[шул исәптән кечкенә балага һәм юләр кешегә дә]:

| | | |
|---|---|---|
| 1.Мөселманга | 2.Ирекле | 3. «Нисаб»ка тулган мал-мөлкәте булган кешегә |

Мал-мөлкәттән зәкәт бер тулы ел [ай календаре буенча] үтмичә бирелми, шушылардан тыш:

| | |
|---|---|
| 1.Җирдә үсә торган азык-төлек | 2. Нигез салынганнан соң, мәсәлән, нисабтан соң алынган мөлкәт, сәүдәдән алынган табыш, чөнки бу очракларда нигез салынган ел башка табышлар елы кебек исәпләнә. |

Мәҗбүри рәвештә бары тик 4 нәрсәдән генә зәкәт бирелә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1.Көтүлектә утлап йөргән мал-лардан | 2.Җирдә үскән азык-төлектән | 3.Кыйммәтле металлардан | 4.Сәүдә товарла-рыннан |

**<u>Көтүлектә утлап йөргән малларга</u> килсәк,** әлеге мәсьәләдә нигез итеп Әнәс хәдисе алына, ул Әбу Бәкрнең аңарга хат язуы хакында хәбәр итә: ***«Аллаһ кушуы буенча Аллаһның илчесе мөселманнарга бурыч итеп йөкләгән зәкәт мәсьәләсенә кагылышлы боерык.***

***— Баш саны 25тән ким булган дөя көтүе өчен зәкәт сарыклар белән түләнә — һәр 5 дөя өчен бер сарык.***

***— Әгәр көтүлектә 25тән алып 35кә кадәр дөя булса, алар өчен зәкәт итеп бер яшьлек ана дөя бирелә, әгәр ул булмаса, ике яшьлек дөя бирелә.***

***— Әгәр дөяләрнең баш саны 36 алып 45кә кадәр булса, алар өчен ике яшьлек бер ана дөя бирергә кирәк.***

***— Әгәр аларның саны 46дан 60ка кадәр булса, алар өчен өч яшьлек бер ана дөя бирергә кирәк.***

***— Әгәр аларның саны 61дән алып 75кә кадәр булса, алар өчен дүрт яшьлек бер ана дөя бирелә.***

***— Әгәр аларның баш саны 76дан 90га кадәр булса, алар өчен зәкәт ике яшьлек ике ана дөя белән түләнә.***

***— Әгәр аларның саны 91дән алып 120 кадәр булса, алар өчен өч яшьлек ике ана дөя бирергә кирәк.***

***— Әгәр аларның саны 120дән артса, бу очракта һәр 40 дөя өчен ике яшьлек бер ана дөя, ә һәр 50 дөя өчен өч яшьлек бер ана дөя бирелә.***

***— Әгәр кешенең 4 кенә дөясе булса, ул, әгәр үзе теләмәсә, алардан зәкәт түләргә бурычлы түгел.***

Көтүлектә утлап йөри торган сарыклардан зәкәт (сарык яки кәҗә):

***— Әгәр көтүлектә утлап йөргән көтүдә 40тан алып 120гә кадәр сарык булса, алардан бер сарык зәкәт итеп түләнә.***

***— Әгәр алар 120дән алып 200 башка кадәр булса, алар өчен ике сарык түләнә.***

***— Әгәр алар 201дән алып 300гә кадәр булса, алар өчен өч сарык бирелергә тиеш.***

***— Әгәр сарыкларның баш саны 300дән артык булса, зәкәт итеп һәр 100дән бер сарык бирелергә тиеш.***

***— Әгәр көтүлектә йөрүче сарыклары кырыктан бергә генә ким булса да, әгәр хуҗа кеше үзе теләмәсә, аларның зәкәтен түләү мәҗбүри түгел.***

Кешеләр көтүлекләрен бергә кушарга тиеш түгелләр, ә, киресенчә, зәкәтен чыгарганда баш саннарын белү өчен аерырга тиешләр. Әгәр ике кешенең көтүе бергә кушылган булса, зәкәтне аның берсе генә түли, икенчесе исә гаделлек белән үз өлешен түли.

Һәм зәкәт сыйфатында (тешләре коелган) карт хайваннарны да, нинди дә булса җитешсезлекләре булган һәм авырту хайваннарны да алырга ярамый.

**Көмешкә кагылышлы мәсьәләдә,**

***— аннан аның бәясенең уннан бер өлешенең чиреге зәкәт итеп түләнә. Көмеш 190 дирхәмнән күбрәк булмаса, әгәр хуҗасы теләмәсә, аннан зәкәт түләү мәҗбүри түгел.***

***Дөяләрнең яше төрле булганлыктан, әгәр кеше зәкәт сыйфатында дүрт яшьлек дөя бирергә тиеш булып, аның өч яшьлек дөясе генә булса, аннан әлеге дөяне кабул итеп алырга кирәк, аңа өстәп бу кеше, әгәр булса, ике сарык, булмаса, 20 дирхәм өстәп бирергә тиеш.***

***Әгәр кеше зәкәт сыйфатында өч яшьлек дөя бирергә тиеш булып, аның дүрт яшьлек дөясе генә булса, аннан бу дүрт яшьлек дөяне кабул итеп алырга кирәк, әмма аңа кире ике сарык яки 20 дирхәм түләргә кирәк».*** Хәдисне имам Бохари китерә.

Мугаз хәдисендә болай дип китерелә: Пәйгамбәр ﷺ ***һәр утыз сыердан бер яшьлек бер үгез бозау яки тана бозау, ә һәр кырык сыердан ике яшьлек бер сыер түләргә боерды.*** Хәдисне «Сунан» китабы авторлары китерә.

**Кыйммәтле металлардан зәкәт түләү мәсьәләсенә килгәндә исә**, югарыда зәкәт бары тик көмешнең саны 200 дирхәм булса гына түләнә диелде, һәм бу очракта уннан бер өлешнең чиреге бирелә.

**Җирдә үскән азык-төлектән зәкәт түләүгә килгәндә,** ул бөртекле культуралардан һәм җиләк-җимешләрдән түләнә, әмма алар запаска калган азык-төлек булырга тиеш. Пәйгамбәр ﷺ әйтте: ***«Хөрмәләрдән (финиклар), әгәр алар биш васктан кимрәк булса, зәкәт түләнми».*** Килешенгән хәдис.

1 васк — ул 60 сагъ, ә бөртеклеләрнең һәм җиләк-җимешләрнең нисабы 300 сагъка тигез (Пәйгамбәр ﷺ заманында кулланылган сагъ).

Пәйгамбәр ﷺ әйтте: ***«Яңгырлар явып һәм пальмалардан коелган су белән, тамырлары белән казылган чокырлардан яңгыр суын алып үскән уңышның уннан бер өлешеннән, ә су сибеп үстергән уңышның егермедән бер өлешеннән зәкәт түләнә».*** Бохари.

Сәхлә ибн Әбу Хасмә сүзләреннән хәбәр ителә, ул әйтте: ***«Уңышны җыеп алып бәяләгәннән соң гына зәкәтен алыгыз, хуҗасына уңышның өчтән бер өлешен калдырыгыз. Әгәр сез өчтән бер өлешне калдырырга теләмәсәгез, дүрттән бер өлешне калдырыгыз».*** Хәдисне «Сунан» китабы авторлары китерде.

**<u>Сәүдә товарларына</u> килгәндә**, аларга табыш алу нияте белән сәүдә өчен әзерләнгән барлык товарлар керә. Товарны тулы бер ел үткәннән соң бәяләргә кирәк, һәм аннан зәкәт, фәкыйрьләрнең ихтыяҗларын исәпкә алып, алтын яки көмеш белән кырыктан бер өлеш күләмендә бирелә.

Әҗәткә акча алган яки милеге булып та аннан куллана алмаган кеше, әйтик, кемгәдер әҗәткә акча биреп, теге кеше ул әҗәтне кайтаруны сузса яки фәкыйрь булып бөтенләй кайтара алмаса, мондый милектән зәкәт түләнми, [ләкин әлеге акчаларны кире кайтарган очракта, хуҗа кеше аннан зәкәтне кайтарылган елны гына бер тапкыр түләргә тиеш]. Әҗәткә бирелгән акчалар вакытында кайтарылса, алардан зәкәт алына.

Зәкәт уртача азык продуктларыннан да түләнә. Хуҗаның кол өчен түләнгән зәкәте саналмый, һәм милегеңнән иң яхшысын бирү мәҗбүри түгел, хуҗа кеше үзе моны теләсә генә.

Әбу Хурайрадан килгән Пәйгамбәребезгә ﷺ барып тоташучы хәдистә хәбәр ителә: ***«Табылган хәзинәдән биштән бер өлеш күләмендә зәкәт түләнелә».*** Килешенгән хәдис.

| **Табылган хәзинәләр** | |
|---|---|
| **1.Җәһилият вакытында** (исламга кадәр) — бу зәкәт түләнелә торган хәзинә һәм аның зәкәт итеп биштән бер өлеше түләнә. | **2.Мөселманнар вакытында** (ислам дине килгәч) — әлеге мәсьәлә табылдыклар хакындагы темада аңлатылыр. |

## ФИТР СӘДАКАСЫ (УРАЗА ГАЕТЕ ЗӘКӘТЕ)

Ибн Гомәрнең болай дип әйткәнлеге хәбәр ителә: «***Аллаһның илчесе Ураза гаете көнне фитр сәдакасын өләшергә боерды:***

| | | |
|---|---|---|
| 1.***Бер сагъ финик яки арпа,*** | 2.***мөселман булган ирләргә һәм хатын-кызларга, кечесенә һәм олысына, ирекле кешегә һәм колга,*** | 3. ***һәм ул моны кешеләр бәйрәм намазына чыкканчы эшләргә боерды»***. Килешенгән хәдис |

**Фитыр сәдакасы фарыз:**

| | | |
|---|---|---|
| 1.Үзе өчен һәм тәрбия кылучы гаилә әгъзалары өчен | 2.Бәйрәм төнендә һәм көнендә тукланганнан соң калган артык ризыктан. | 3.Бер сагъ: финик, арпа, эремчек, йөзем яки бодай. |

Файдалырак азык-төлек бирү хәерлерәк.

Фитыр сәдәкасын бирүне бәйрәм көннән соңга калдыру рөхсәт ителми.

Аллаһның илчесе ﷺ ошбу сүзләре белән бу зәкәтне бурыч итеп йөкләде: ***«Зәкәт-әл-фитр ураза вакытында кирәкмәгән буш сүзләрдән арыну һәм ярлыларга ризык бирү өчен:***

| | |
|---|---|
| 1.***Әгәр кеше бу зәкәтне бәйрәм намазына кадәр бирсә, ул кабул ителә.*** | 2.***Әгәр ул бәйрәм намазыннан соң бирелсә, ул гадәти сәдакадан китә».*** Әбу Давыд һәм Ибн Мәджә. |

| Пәйгамбәр ﷺ әйтте: ***«Аллаһ Аның күләгәсеннән гайре башка күләгәләр булмаган Көндә Үзенең күләгәсендә җиде кешене каплар*** | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 1.***Гадел хакимне.*** | 2.***Аллаһка гыйбадәттә үскән яшь егетне***<br>3.***Йөрәге мәчетләр белән бәйле булган кешене.*** | 4.***Аллаһ ризалыгы өчен бер-берләрен сөйгән һәм күрешкәндә дә, аерылышканда да Аның ризалыгы өчен күрешкән һәм аерылышкан ике кешене*** | 5.***Бай һәм чибәр хатын-кыз үзе янына дәшкәндә дә «Мин Аллаһтан куркам!» дип җавап биргән ир-атны*** | 6.***Ирекле сәдака биреп, шуны уң кулы биргәнне сул кулу күрмәслек итеп яшергән кешене*** | 7.***Һәм үзе генә калып Аллаһны зикер иткән вакытта күзләре яшьләр белән тулган кешене».*** Килешенгән хәдис |

## ЗӘКӘТ ТИЕШЛЕ БУЛГАН КЕШЕЛӘРНЕҢ КАТЕГОРИЯЛӘРЕ

Зәкәт бары тик сигез категория кеше файдасына гына бирелә, әлеге категорияләрне Аллаһ Тәгалә Үзенең бер аятендә искә алды: **«Сәдака (ягъни мәҗбүри зәкәт) ярлыларга, фәкыйрьләргә, зәкәтне җыю һәм тарату эше белән шөгыльләнүче кешеләргә, ислам диненә кертергә теләп калебен яулап алырга теләгән кешеләргә, колларны сатып алырга, әҗәтләрен түли алмаган кешеләргә, Аллаһ юлына һәм мосафирларга. Аллаһ тарафыннан шулай боерылды, Аллаһ — Белүче, Хикмәт иясе!»**

Пәйгамбәребезнең ﷺ Мугазга әйткән сүзләренә таянып, бер категория белән дә чикләнеп була: ***«Әгәр алар бу мәсьәләдә сиңа буйсынсалар, аларга Аллаһ мәҗбүри зәкәт турында боерды, дип хәбәр бир, зәкәт бай кешеләрдән алынып шунда яшәүче фәкыйрь-ярлыларга һәм мескеннәргә бирелә».*** Килешенгән хәдис.

Зәкәтне бирергә ярамый:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1.Бай кешегә | 2.Акча эшләү мөмкинчелеге булган сәламәт кешегә. | 3.Мөхәммәд ﷺ гаиләсенә, ягъни Бану Хашим кавеменә һәм аның токымына. | 4. Зәкәт бирелгән вакытта зәкәт җыючы кешенең тәрбиясендә булганнар файдасына. | 5.Имансыз кешегә. |

Ирекле зәкәтне исәәле генә санап үтелгән категория кешеләренә дә башкаларга бирергә мөмкин.

Әмма зәкәт бирелгән кешегә күпме күбрәк файда китерсә (бу файда гомуми һәм өлешчә булса да), шулкадәр яхшырак һәм камилрәк була.

Пәйгамбәр ﷺ әйтте: ***«Үзенең малын арттыру өчен дип башкаларның малын сораган кеше үзе өчен Җәһәннәм утын сорый. Шуңа күрә теләсә, аз сорасын, теләсә, күп сорасын».*** Мөслим.

Ул Гомәргә, Аллаһ аннан риза булсын, әйтте: ***«Ал моны. Әгәр сиңа шушы милектән син омтылмаган һәм сорап алмаган нәрсә булса да эләксә, аны ал. Шуннан башкага калебеңне буйсындырма».*** Мөслим.

<table>
<tr><th colspan="6">Зәкәт Аллаһ «Тәүбә» сүрәсендә телгә алган сигез категория кешеләргә тиеш:</th></tr>
<tr><td>1.Ярлылар. Болар бер нәрсәләре дә булмаган яки кирәкле нәрсәләрнең берникадәр өлеше генә булган мохтаҗлык кичерүче кешеләр.</td><td colspan="3">2.Фәкыйрьләр. Болар кирәк-яракның күп өлеше яки яртысы үзләрендә булган кешеләр. Әгәр кешегә ел әйләнәсе 12.000 кирәк дип исәпләсәк, ярлы кеше ул — 6.000нән азрак акчасы булган, ә фәкыйрь — 6.000 яки күбрәк, тик 12.000нән азрак акчасы булган кеше. Бу категория кешеләренә зәкәтне ел әйләнәсенә җитәрлек итеп бирергә кирәк, чөнки зәкәт бер елга түләнә.</td><td colspan="2">3.Зәкәт белән бәйле кешеләр. Бу зәкәтне җыючы һәм саклаучы кешеләр, аларга зәкәтне бүлү эше йөкләтелгән һәм алар хаким күзәтчелеге астында. Әлеге кешеләргә ярлы яки фәкыйрь кеше булу мәҗбүри түгел. Бай булган очракта да аларга зәкәт түләнелә.</td></tr>
<tr><td rowspan="3">4.Калебләрен яулап алырга теләүчеләргә. Әлеге кешеләргә зәкәт ислам динен кабул итмәсме дигән өмет белән яки аларның явызлыгын тотып тору яки иманын ныгыту нияте белән бирелә.</td><td colspan="3">5.Колларны сатып алып азат итү өчен</td><td colspan="2">6.Әҗәтлеләр</td></tr>
<tr><td>Мукатаб — үзенең хуҗасыннан үзен сатып алган колга.</td><td>Мөселман колны азат итү.</td><td>Әсир мөселман</td><td>Ике кешене дуслаштыру өчен әҗәткә акча алып торган кешегә.</td><td>Үзенең ихтыяҗлары өчен әҗәткә акча алып торган кеше.</td></tr>
<tr><td colspan="3">Бу категориягә хуҗалары тарафыннан инде азат ителгән коллар керми. Мондый колларга зәкәт тиеш түгел.</td><td colspan="2">Ярлы кешенең әҗәтен, бу минем тарафтан зәкәт булыр, дигән ният белән гафу итәргә ярамый.</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| 7.**Аллаһ юлына тотар өчен.** Монда сугышчылар, шулай ук аларга кирәкле кораллар һәм башкалар керә. | 8. **Үз милекләреннән еракта булган һәм акчалары беткән мосафирлар.** Мондый кешеләргә зәкәт аларга туган җирләренә кайту өчен җитәрлек күләмдә түләнә. |

| **Чәчүлекләрне сугару төрләре һәм алардан зәкәт күләме:** | |
|---|---|
| 1.Ясалма рәвештә сугарылган чәчүлекләрдән — унынчы өлешнең яртысы (5%). | 2.Табигый ысул белән сугарылган чәчүлекләрдән — унынчы өлеш (10%). |
| 3.Ясалма ысул белән дә, табигый ысул белән дә бертигез сугарылган чәчүлекләрдән — унбиштән бер өлеш (7,5%). | 4.Ясалма ысул белән дә, табигый ысул белән дә, әмма бертиге зсугарылмаган чәчүлекләрдән — кайсы ысул белән күбрәк. |
| 5.Ясалма ысул белән дә, табигый ысул белән дә, әмма бертигез сугарылмаган чәчүлекләрдән, кайсы ысул белән күбрәк сугарылуын белмәгән очракта — унынчы өлеш (10%). | |

| Кайбер терминнарның мөһим билгеләмәләре: | | |
|---|---|---|
| **Дөяләр** | Бинт әл-мәхад | Бер яшьлек ана дөя. Әлеге исем аңа әнисе карында инде икенче яралгыны йөрткәнлектән бирелгән. |
| | Бинт әл-ләбун | Ике яшьлек ана дөя. Әлеге исем аңа әнисе инде яңа дөя баласын имезгәнлектән бирелгән. |
| | Әл-хикка | Өч яшьлек ана дөя. Әлеге исем аңа каплатыла башлаганлыктан бирелгән. |
| | Әл-джәзагат | Дүрт яшьлек ана дөя . Әлеге исем аңа бу вакытта кискеч тешләре төшкәнлектән бирелгән. |
| **Сыерлар** | Әт-Табигъ | Бер яшьлек тана бозау |
| | Әл-Мусиннә | Ике яшьлек тана |

# КЫСКАЧА

| Зәкәтнең күләме | | | |
|---|---|---|---|
| ***Мал-мөлкәт*** | ***1 ел*** | ***Нисаб*** | ***Зәкәтнең күләме*** |
| Мал-туар | Шарт | Алга таба тәфсилләбрәк аңлатыла | Алга таба тәфсилләбрәк аңлатыла |
| Жирдән алынган уңыш | Шарт түгел | 300 сагъ | ***Унынчы өлеш*** — әгәр чәчүлекләр яңгыр белән яки чишмә суы белән сугарылса. ***Унынчы өлешнең яртысы*** — әгәр чәчүлекләр су сибеп сугарылса. ***Унбиштән бер өлеш*** — әгәр ике ысул белән дә сугарылса. |
| Кыйммәтле әйберләр | Шарт | 85 г. алтын яки 595 г. көмеш | Кырыктан бер өлеш |
| Сәүдә товарлары | Шарт | Алтын яки көмеш, мохтаҗларның ихтыяҗларын истә тотып | Кырыктан бер өлеш |

<table>
<tr><td colspan="9">Ирекле рәвештә көтүлекләрдә утлап йөрүче мал-туарның нисабы һәм зәкәт күләме</td></tr>
<tr><td colspan="3">Мөгезле вак терлек:</td><td colspan="3">Дөяләр: бер өркәчле яки ике өркәчле</td><td colspan="3">Сыерлар һәм буйволлар</td></tr>
<tr><td colspan="2">Саны</td><td rowspan="2">Зәкәт</td><td colspan="2">Саны</td><td rowspan="2">Зәкәт</td><td colspan="2">Саны</td><td rowspan="2">Зәкәт</td></tr>
<tr><td>башлап</td><td>кадәр</td><td>башлап</td><td>кадәр</td><td>башлап</td><td>кадәр</td></tr>
<tr><td>40</td><td>120</td><td>1 сарык</td><td>5</td><td>9</td><td>1 сарык</td><td>30</td><td>39</td><td>1 бер яшьлек бозау (тана яки үгез)</td></tr>
<tr><td>121</td><td>200</td><td>2 сарык</td><td>9</td><td>14</td><td>2 сарык</td><td>40</td><td>59</td><td>1 ике яшьлек тана</td></tr>
<tr><td>201</td><td>300</td><td>3 сарык</td><td>10</td><td>19</td><td>3 сарык</td><td>60</td><td>69</td><td>2 бер яшьлек бозау</td></tr>
<tr><td colspan="3" rowspan="6">Шуннан соң һәрбер 100 башка — 1 әр сарык<br><br>Кәҗә тәкәсе, карт, авыру яки булган малдан иң начар хайван зәкәт сыйфатында бирелми.</td><td>20</td><td>24</td><td>4 сарык</td><td colspan="3" rowspan="6">Шуннан соң һәр 30 баштан — 1әр бер яшьлек бозау, ә һәр 40 баштан — 1әр ике яшьлек бозау.</td></tr>
<tr><td>25</td><td>35</td><td>1 бер яшьлек ана дөя</td></tr>
<tr><td>36</td><td>45</td><td>1 ике яшьлек ана дөя</td></tr>
<tr><td>40</td><td>60</td><td>1 өч яшьлек ана дөя</td></tr>
<tr><td>61</td><td>75</td><td>1 дүрт яшьлек ана дөя</td></tr>
<tr><td>76</td><td>90</td><td>2 ике яшьлек ана дөя</td></tr>
</table>

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Хәлсезләнгән, буаз, ашамсак яки булган малдан иң яхшы хайван зәкәт сыйфатында алынмый. | 91 | 120 | 2 өч яшьлек ана дөя | |
| | 121 | 129 | 3 ике яшьлек ана дөя | |

| **Ураза зәкәтенең хөкеме:** | | |
|---|---|---|
| **Мәҗбүри:** | | **Тиешле:** |
| Рамазан аеның соңгы көнендә, мөселман булып, кояш баешын күргән барлык кешеләр: олылар һәм балалар, ир-атлар һәм хатын-кызлар, ирекле кешеләр һәм коллар өчен. | Бәйрәм көннәрендә һәм төнгә үзең һәм гаиләң өчен булган ризыкның һәм башка төп ихтыяҗлардан артык калган өлешеннән 1 сагъ күләмендә | Әни карынындагы баладан |

| **Ураза зәкәте боерылуның хикмәте** | |
|---|---|
| Ураза тотучыны буш сүзләрдән һәм гайбәттән чистарта | Бәйрәм көнендә ярлыларны һәм фәкыйрьләрне сәдака сораудан арындыра. |

| **Ураза зәкәтен түләү вакыты** | | |
|---|---|---|
| Рөхсәт ителгән вакыт: бәйрәмгә кадәр бер яки ике көн кала | Хәерле вакыт: таң атканнан соң бәйрәм намазын укыганчыга кадәр | Тыелган вакыты: бәйрәм намазыннан соң |

| **Ураза зәкәтен нәрсә белән түләргә кирәк:** | |
|---|---|
| Кешеләр тукланучы азык-төлектән 1 сагъ ризык. 1 сагъ яхшы бодай2 кг 40 г га тигез<br>Башка азык-төлек тә шул рәвешле санала. | Акча белән саналмый. |

| **Киң кулланылган азык-төлекләрнең авырлыгы буенча ураза зәкәте күләме:** | | |
|---|---|---|
| Он — 1400 г. | Ак он — 2000 г. | Дөге — 2300 г. |
| Бодай — 2040 г. | Ясмык — 2100 г. | Борчак — 2000 г. |
| Фасоль — 2060 г. | Хөрмә (Финик) — 1800 г. | Йөзем — 1640 г. |

| **Алучыны һәм күләмен исәпкә алып зәкәт төрләре:** | | |
|---|---|---|
| 1.Бирелергә тиешле продукт билгеле, әмма бирүче һәм алучы кешеләре күрсәтелмәгән зәкәт. Мәсәлән: ураза зәкәте. | 2.Алучысы да, бирелүче продукт та билгеле булган зәкәт, мәсәлән, китерелгән зыян өчен компенсация, йолым: ***«һәрберсенә бер сагъның яртысын биреп, 6 ярлыны ашату».*** | 3.Алучысы билгеле булып, бирелергә тиешле продукты билгеле булмаган зәкәт. Мәсәлән, антны бозган өчен йолым. |

## ЗӘКӘТ КИТАБЫ БУЕНЧА СОРАУЛАР

| Сорау | Дөрес | Дөрес түгел |
|---|---|---|
| — Әгәр кеше зәкәтен түләмәгән хәлдә вафат булса, зәкәт варислар хокукына күчкәнче аның милкеннән алына.<br>— Мөгезле вак терлекнең нисабы — 120 баш.<br>— 76 дөядән 1 ике яшьлек ана дөя алына.<br>— Куллану өчен билгеләнгән бизәктән зәкәт түләнми.<br>— Сәүдә товарлары 1 ел үткәч, ярлыларның ихтыяҗларын истә тотып, алтын яки акча белән бәяләнә.<br>— «Мал-туар»га дөяләр, сыерлар, буйволлар һәм сарыклар керә.<br>— Җиләк-җимешләрдән зәкәт алынмый.<br>— Фәкыйрьләр дә, ярлылар да зәкәт мәсьәләсендә бер хөкемдә.<br>— «Калебләрен яулап алырга теләүчеләр» — бу төшенчә имансызларга да, аларның ислам динен кабул итүендә өмет булмаса да, кагыла.<br>— Әгәр хуҗа үзенең колын иреккә җибәрсә, колга зәкәт бирелә.<br>— Бай кеше ярлы кешедән билгеле бер суммада акча таләп итә, әмма шуннан соң, зәкәт сыйфатында санау нияте белән, ул сумманың бер өлешен гафу итә. Болай эшләү дөрес.<br>— «Аллаһ юлында» — үз эченә хәйрия эшен ала, мәсәлән, мәчетләр төзү.<br>— Кыйммәтле металлардан зәкәт 40 ка бүлү юлы белән исәпләнә.<br>— Бары тик ирекле көтүлекләрдә утлап йөргән мал-туардан гына зәкәт алына, эш эшли торган һәм махсус ашата торган малдан зәкәт алынмый.<br>— Бөртеклеләр һәм җиләк-җимешләрдән алар нисабка җиткәч һәм өлгергәч зәкәт алына. | | |

| | | |
|---|---|---|
| — Бөртеклеләрдән һәм җиләк-җимештән, әгәр алар кеше хезмәте ярдәмендә сугарылган булсалар, зәкәт буларак унынчы өлешнең яртысы алына. | | |
| — Алтынның нисабы 20 мискальгә җитсә, аннан зәкәт түләнә. | | |
| — Әт-табигъ — ул ике яшьлек бозау. | | |
| — Яшәү өчен төзелгән йортлардан зәкәт түләнә. | | |
| — Юлда булучы һәр мосафирга да зәкәт бирелә, чөнки ул сәфәрдә. | | |
| — Зәкәтне түләүче кеше зәкәтне мөстәкыйль рәвештә бирсә яхшырак. | | |

— Кеше бер ел үткәнче үзенең милкеннән зәкәт түләмәс өчен котылса:
Ул үзе курыккан гамәл белән җәзалана һәм аннан зәкәт алына ___, болай эшләү рөхсәт ителә___.

— Кеше сәүдә товарын көтүлектә утлап йөргән малга алыштырып алды, әмма бер елны санаганда исәпкә алмады: дөрес эшләде___, дөрес эшләмәде___.

— Кеше алга таба сәүдә белән шөгыльләнү нияте белән нидер сатып алды, ди: сатып алынган мөлкәттән зәкәт алына___, алынмый___.

— Хатын-кыз үзенә алтын караватсатып алды: зәкәт алына___, зәкәт алынмый___.

— Кешенең 100 саудия риалы бар: зәкәт алына___, зәкәт алынмый___.

— Кеше элек мөселманнарныкы булганлыгын дәлилләүче билгеләре булган хәзинә тапты: зәкәт алына___, зәкәт алынмый___.

— Мал-мөлкәттән зәкәт бер ел үткәч кенә алына: ай календаре буенча___, кояш календаре буенча___, аерма юк___.

— 1 ел үтү шарт булып тормый: хәзинә өчен___, уңыш өчен___, икесе өчен дә___.

— Алтынның нисабы: 85 г.___, 595 г.___, 95 г.___.

— Көмешнең нисабы: 200 дирхәм.___, 595 г.___, икесе дә___.

— Көтүдә утлаучы мал-туар ул: бәясе буенча кыйммәт___, ел әйләнәсе яки елның күбрәк өлешен иркен рәвештә көтүлекләрдә утлап йөргән мал-туар___.

— Рөхсәт ителгән урында көтүләнә, ягъни: чиста ризык белән туклана___, хуҗасы юк___.

| **Әлеге мөлкәтнең һәр төреннән зәкәт күләмен һәм түләнәчәк мал-туарның санын языгыз:** | | |
|---|---|---|
| Мөлкәт | Зәкәт күләме | Саны |
| 100 дирхәм | | |
| 300 динар | | |
| 400 дирхәм | | |
| 80 г. алтын | | |
| 500 г. көмеш | | |
| 30 сарык | | |
| 60 сарык | | |
| 565 сарык | | |
| 4 дөя | | |
| 17 дөя | | |
| 449 дөя | | |
| 30 сыер | | |
| 49 сыер | | |
| 77 сыер | | |
| 99 сыер | | |
| 20 млн. риал | | |
| 45,679 риал | | |
| 255 сагъ бодай | | |

# УРАЗА КИТАБЫ

## УРАЗА КИТАБЫ

| |
|---|
| Ураза — ул таң атканнан алып кояш баегынчыга кадәр ризык, су һәм уразаны бозучы башка гамәлләрдән тыелып тору аркылы Аллаһка гыйбадәт кылу. |
| Әлеге гыйбадәтнең нигезендә Аллаһ Тәгаләнең сүзләре ята: **«Әй сез, иман китергән бәндәләр! Сезгә кадәр килгән кавемнәргә боерылган кебек сезгә дә ураза тоту боерылды».** |

Рамазан аенда ураза тоту һәркемгә фарыз:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1. Мөселманга | 2. Бәлагатькә ирешкән кешегә | 3. Гакыл иясенә | 4. ураза тота алучыга | 5. Яңа ай күргән яки шәгъбән аеның 30нчы көненә ирешкән кешегә |

| |
|---|
| Аллаһның илчесе ﷺ әйтте: ***«Яңа ай күргәч, уразага керегез. Әгәр болыт сәбәпле айны күрә алмасагыз, шәгъбән ае үтүгә ураза тота башлагыз».*** Килешенгән хәдис.<br><br>Башка хәдистә болай диелә: ***«шәгъбән аеның 30 көне үткәннән соң».*** Бохари.<br>1 иманлы кеше яңа айны күрүгә ураза тота башларга кирәк. Башка айларның башланганын билгеләү өчен ике иманлы кеше кирәк.<br><br>Фарыз уразасы өчен төнлә үк ният кылына, ә ирекле уразада исә ураза тоткан көндә ниятләү дә җитә. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Ураза тотканда хәле начарланган авыру кеше һәм мосафир уразаларын тота яки төшереп калдыра ала. | Хәйд яки нифас халәтендәге хатын-кызга ураза тоту тыела, әмма бу калган көннәрен ул каза кылырга тиеш. | Әгәр авырлы яки бала имезүче хатын-кыз үзенең баласы өчен курыкса, ул ураза тотмаска мөмкин, әмма аны соңрак каза кылырга яки калдырылган уразаның 1 көне өчен 1 ярлыны ашатырга тиеш. | Сәламәтләнүгә өметләре булмаган өлкән яшьтәге яки авыру кешеләр уразаның төшеп калган 1 көне өчен 1 ярлыны ашатырга тиешләр. |

Уразасын ашау, эчү, беләә торып косу, кан чыгару, хатын-кызга кагылу сәбәпле мәни чыгу нәтиҗәсендә бозган кеше аны каза кылырга тиеш. Әгәр ураза якынлык кылу нәтиҗәсендә бозылган булса, түбәндәге гамәлләрне кылырга кирәк:

| | | |
|---|---|---|
| 1.Каза кылырга һәм бер колны азат итәргә | 2.Колы булмаса, 2 ай рәттән ураза тотарга тиеш. | 3.Әгәр бу мөмкин булмаса, 60 ярлыны ашатырга тиеш. |

Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: «***Әгәр кем дә булса ураза вакытында онытылып китеп ашаса яки эчсә, ураза тотуын дәвам итсен, чөнки, чынлыкта, Аллаһ аны ашатты һәм эчертте».*** Килешенгән хәдис.

«***Кешеләр тиз арада авыз ачудан туктаганчыга кадәр нигъмәттән мәхрүм булмаслар».*** Килешенгән хәдис.

***«Таң алдыннан ашагыз, чөнки сәхәрдә бәрәкәт».*** Килешенгән хәдис.

***«Сезнең берәрегез авыз ачкан вакытта финик ашасын, чөнки анда бәрәкәт. Әгәр финик булмаса, су белән авыз ачсын, чөнки су чистартучылардан»***. Хәдисне 5 шәех китерде.

***«Әгәр кеше алдалаудан туктамаса, Аллаһка аның ашамыйча һәм эчмичә торуы кирәк түгел».*** Бохари.

«***Рамазан аенда ураза тотарга тиеш булган мәрхүм урынына аның якын кешеләреннән берсе ураза тотсын***». Килешенгән хәдис. [*Әлеге хәдистә сүз тотылмый калган уразасын каза кылырга мөмкинлеге булып, моны эшләмичә вафат булган кеше турында бара. Бу очракта якын туганына аның өчен ураза тоту тиеш була. Якын туганы — ягъни варисы*].

Аллаһның илчесеннән ﷺ Гарәфә көнендә ураза тоту турында сорадылар, ул болай дип җаваплады: «***Үткән һәм бу елгы гөнаһларны юа***». Аннан Гашура көнендәге ураза турында сорадылар, ул җавап бирде: «***Үткән елның гөнаһларын юа***». Аннан дүшәмбе уразасы турында сорадылар, һәм ул җавап бирде: «***Бу көндә мин тудым һәм миңа Аллаһның илчесе булу йөкләтелде***» яки «***Ул көннемиңа вәхий иңде***». Мөслим.

«***Әгәр Рамазан буе ураза тоткан мөселман аннан соң килгән шәвәл аенда да алты көнле ураза тотса, ул ел буе ураза тоткан кебек булачак***». Мөслим.

Әбу Зарр әйтте: «*Аллаһның илчесе ﷺ безгә һәр айда өчәр көн ураза тотарга боерды: 13, 14, 15нче көннәрдә*». Нәсаи һәм Тирмизи.

«***Пәйгамбәр ﷺ ошбу ике көндә ураза тотудан тыйды: Ураза һәм Корбан гаетләре бәйрәмнәрендә***». Килешенгән хәдис.

Ул әйтә иде: «***Тәшрикъ көннәре — ул ашау, эчү һәм Аллаһны зикер итү көннәре***». Мөслим.

«***Сезнең берегез дә җомга көнендә ураза тотмасын, әгәр җомгага кадәр бер көн тоткан булмаса һәм икенче көнне ураза тотмаса***». Килешенгән хәдис.

«***Кем әҗер-савап буласына инану һәм өмет белән Рамазан аенда ураза тотса, аңарга элек кылган гөнаһлары кичерелер, Кадер кичендә намаз укыган кешенең элек кылган барлык гөнаһлары да кичерелер***». Килешенгән хәдис.

«***Аллаһның илчесе ﷺ Аллаһ аны вафат иткәнчегә кадәр һәр Рамазан аенда 10 көн и'тикаф кыла иде. Аның вафатыннан соң аның хатыннары и'тикаф кыла иделәр.***». Килешенгән хәдис.

«***Ошбу өч мәчеттән кала башка җирләргә сәфәр чыкмагыз — әл-Харам мәчете, минем мәчетем һәм әл-Акса мәчете***». Килешенгән хәдис.

## [КЫСКАЧА]

<table>
<tr><th colspan="2">Ураза ике төрле була:</th></tr>
<tr><td>Фарыз: Рамазан аенда, гөнаһларны йолу һәм нәзер уразалары</td><td>Үтәлергә тиешле: башка уразалар</td></tr>
</table>

<table>
<tr><th colspan="3">Уразаның 2 әркәне бар:</th></tr>
<tr><td colspan="2">1.Ният</td><td rowspan="2">2.Уразаны бозучы бар нәрсәдән тыелып тору.</td></tr>
<tr><td>Фарыз уразасын үтәү нияте, әлеге ният төннән үк ниятләнә, ягъни таң атканчыга кадәр. Рамазан ае башлануга ай буе ураза тотарга ниятләп кую җитә. Ниятнең урыны — калеб, ә аны тел белән әйтү — бидгать.</td><td>Үтәргә тиешле уразаны тотарга ният. Әгәр кеше таң атканнан бирле ашамаса, тәүлекнең теләсә кайсы вакытында ниятләргә мөмкин, тик бу очракта әҗер-савабы аңа ниятләгән вакытыннан гына языла.</td></tr>
</table>

<table>
<tr><th colspan="3">Ураза фарыз булсын өчен шартлар алтау:</th></tr>
<tr><td>1.Ислам</td><td>2.Гакыл</td><td>3.Бәләгатькә ирешү. Бәлигъ булмаган балаларны ураза тотарга рухландырырга кирәк, ә аларны тәрбиягә алучылар аларга ураза тотарга боерырга да мөмкиннәр.</td></tr>
<tr><td>4.Туган якта булу. Мосафирга ураза тоту мәҗбүри түгел, әмма аңарга ураза тоту, әгәр авыр булмаса, яхшырак, чөнки Пәйгамбәр ﷺ шулай эшли иде. Бу намусны тизрәк чистарта, мөкәлләф өчен җиңел һәм шул рәвешле ул Рамазан аендагы уразаның фазыйләтләрен алачак.</td><td>5.Сәламәтлек</td><td>6.Хәез һәм нифас халәтендә булмау.</td></tr>
</table>

| Ураза вакытындагы чирләрнең төрләре: | |
|---|---|
| 1.Сәламәтләнергә өмет булмаган чирләр. Бу төргә ураза тота алмый торган өлкән яшьтәге кешеләр дә керә. Мондый кешеләргә ураза тоту мәҗбүри түгел, әмма алар һәр төшеп калган ураза өчен 1 ярлыны ашатырга тиешләр: төшеп калган уразалар санынча ярлыларны бергә җыеп һәм аларны төшке яки кичке аш белән сыйларга яки шул сандагы ярлыларның һәрберсенә дә пәйгамбәребез ﷺ билгеләгән сагъның чиреге (ягъни 0,51 кг) күләмендә яхшы бодай өләшергә кирәк. Һәм аның белән бергә ит яки май өләшү яхшырак булыр. | 2.Сәламәтләнергә өмет булган һәм авыру кешегә ураза тотарга комачау итә торган чирләр. Бу төргә хәез һәм нифас вакыты булган хатын-кызлар да, балаларына күкрәк сөте ашатучы әниләр һәм мосафирлар да керә. Сәламәтләнгәч, аларга төшеп калган уразаларны шул санынча каза кылырга кирәк. Әмма әгәр аларның берсе иртәрәк вафат булса, алар өчен әлеге көннәрне каза кылырга кирәкми |

| Рамазан ае башлану ничек билгеләнә? | |
|---|---|
| Яңа айны күрү белән | Шәгъбан аеның 30 көне тәгәлләнү белән |

| Уразаны бозучы гамәлләр | | |
|---|---|---|
| 1.Аңлы рәвештә ризык яки эчемлек кабул итү. Әгәр онытылып эшләнсә, бу очракта ураза дөрес була. | 2.Якынлык кылу: әгәр ул ураза тоту фарыз булган вакытта көндез булган булса, әлеге гөнаһны йолу өчен катгый рәвештә ошбу гамәлләрне эшләргә кирәк: бер колны азат итәргә, әгәр ул булмаса, 2 ай рәттән ураза тотарга, әгәр болай эшләү мөмкин булмаса, 60 ярлыны ашатырга кирәк. | 3.Хатын-кызга кагылу, аны кочаклау, үбү һәм башкалар аркасында мәни бүленеп чыгу. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4.Ризык һәм әчемлекләрне алыштырып килүче нәрсәләр: тукландыргыч уколлар (глюкоза) һәм башкалар. Әгәр укол тукландыргыч булмаса, ул уразаны бозмый. | 5.Кан алыну. Аз күләмдәге кан, әйтик, анализга бирелгән кан һәм башкалар уразаны бозмый. | 6.Белә торып косу | 7.Хәез яки нифас халәте. |

| **Ураза тотучыга рөхсәт ителгән гамәлләр:** | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Селәгәйне йоту | Кирәк вакытта ризыкны тәмләп карау | Коену | Сивак куллану | Ислемайлар сөртү | Авызны чайкау |

| **Ураза вакытында үтәлергә тиешле гамәлләр:** | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 1.Сәхәр ашау | 2.Сәхәрне соңгарак калдыру | 3. Авыз ачарга ашыгу | 4.Берничә сусыл хөрмә белән, әгәр алар булмаса, саны так булган коры финик белән, әгәр алар да булмаса, берничә йотым су белән авыз ачу; әгәр боларның берсе дә булмаса, калебең белән уразаны тәмамлау турында ниятләргә кирәк. | | |
| 5.Ураза тотканда да, ифтар вакытында да дога кылу | | 6.Күп итеп сәдака бирү | 7. Төнге намазларны тырышып үтәү | 8. Коръән уку | 9. Сине ачуланган кешегә «Мин уразада» дип әйтү. |
| 10.Гомрә кылу | | 11. Соңгы 10 төнендә иъгтикаф кылу | | 12.Кадер кичен көтү. | |

| Ураза вакытында эшләү тиеш булмаган гамәлләр: | |
|---|---|
| 1.Авыз һәм борын куышлыгын яхшы итеп юу | 2.Кирәк булмаган вакытта ризыкны тәмләп карау |

| Ураза тотучыга тыелган гамәлләр: | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1. Какырыкны йоту: ләкин болай эшләү уразаны бозмый | 2.Уразаның бозылуына китерергә мөмкин булса, үбү | 3. Гайбәт: барлык тыелган сүзләрне сөйләү | 4.Наданлык: дорфалык һәм тупаслык | 5. Авыз ачмыйча ике уразаны кушу |

| Каза кылу кагыйдәләре: | | | |
|---|---|---|---|
| Уразаны рәттән каза кылу хәерлерәк | Бәйрәм көненнән соң каза кылуны ашыктырырга кирәк | Икенче Рамазан башланганчы сузарга рөхсәт ителми | Әгәр уразаны каза кылуны калдыруга нигезле сәбәпләре булмаса, уразалар саны артмаса да, гөнаһ булып языла. |

| Үтәргә тиешле, хәерле булган уразалар: | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1.Бөтен Рамазан буе ураза тоткан кешеләргә шәвәл аеның алты көн уразасы; һәм аны икенче көннән алып үти башлау хәерлерәк | | 2. Хаҗда булмаучылар өчен Гарәфә көне уразасы | 3. Гашура көне уразасы (мөхәррәм аең 10сы) 9-11 көннәрдә. | 3. Гашура көне уразасы (мөхәррәм аең 10сы) 9-11 көннәрдә. |
| 5.Һәр айда 3әр көн, һәм бу «ак көннәр» булса, яхшырак (13, 14, 15 көннәрдә) | 6.Көн аралаш ураза тоту | 7.Аллаһның ае Мөхәррәм анда ураза тоту | 8.Зөл-хиҗҗә аенда 9 көн ураза тоту | 9. Шәгъбән аенда ураза тоту, ләкин тулаем түгел. |

| Хәерле булмаган уразалар: | |
|---|---|
| Аерым-аерым җомга, шимбә, якшәмбе көннәрендә ураза тоту | Әгәр бу көннәргә сәбәп белән тотыла торган уразалар туры килсә, мәсәлән, Гарәфә көне уразасы, бу очракта рөхсәт ителә. |

| Тыелган уразалар: | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1. Аерым Рәҗәп ае буе ураза тоту | 2. Бәйрәм көннәрендә ураза тоту | 3. Шикле көндә ураза тоту, әгәр ул ураза тоту гореф-гадәте белән туры килмәсә генә | 4.Тәшрикъ көннәрендә, корбан чалу өчен малы булмаган кешедән кала, ураза тоту. | 5. Һәрчак ураза тоту |

## УРАЗА КИТАБЫ БУЕНЧА СОРАУЛАР

| Сораулар | Дөрес | Дөрес түгел |
|---|---|---|
| — Әгәр без теге яки бу гамәл уразаны боза, дип шикләнсәк, нигездә, ул уразаны бозмый | | |
| — Кем сәхәр ашады, шул Сөннәтне тормышка ашырды, хәтта сәхәрне төн уртасында ашаса да. | | |
| — Гарәфә көнендә ураза тоту теләсә-кайсы очракта да үтәргә тиешле булып тора. | | |
| — Ирекле ураза тотучы кеше үзенең уразасын ахырына кадәр үтәп бетерергә тиеш. | | |
| — Теләсә-кайсы чир ураза тотарга киртә булып тора. | | |

— Уразаның әркәннәрен санагыз: 1___,2___, 3___, 4___.

— Кем өчен ураза фарыз була?

1.______________________________

2.______________________________

3.______________________________

4.______________________________

— «Сәхәр» вакытын атагыз.

— Сәхәр вакытында нәрсә ашарга кирәк?

— Ураза тотучы кеше нәрсә белән авыз ачарга тиеш? ________________, әгәр ул булмаса,______________, әгәр ул да булмаса,_____________, әгәр ул да булмаса, ______________.

| Ураза тотучының гамәлләренә карата хөкемнәрне атагыз: | | | |
|---|---|---|---|
| **Гамәл** | **Хөкем** | **Гамәл** | **Хөкем** |
| Нифас халәтендәге хатын-кызның уразасы | | Авызны җентекләп чистарту | |
| Өлкән яшьтәге кешенең уразасы | | Үбешү | |
| Ураза вакытында ризык кабул итү | | Бер өзлексез ике уразаны кушу | |
| Ураза тоту хакында таң аткач ниятләү | | Тотылмыйча калган уразаларны икенче Рамазан аена кадәр калдыру | |
| Күзгә сала торган тамчылар | | Гарәфә көнендәге ураза | |
| Тынычландыра торган укол | | Шикле көндәге ураза | |
| Кан чыгару | | Бәйрәм көннәрендәге ураза | |
| Косу | | Тәшрикъ көннәрендәге ураза | |
| Селәгәй йоту | | Мөхәррәм аендагы ураза | |
| Ризыкны тәмләп карау | | Рәҗәб аендагы ураза | |
| Йокы | | Ел әйләнәсе ураза тоту | |
| Коену | | Җомга көнендә ураза | |
| Мосафир уразасы | | Шәвәл аеның 6 көнендә ураза тоту | |
| Сивак | | Ураза тотучыга тукландыргыч укол ясау | |
| Ислемайлар | | Ният булмаган ураза | |
| Таравих намазлары | | Кечкенә балаларның уразасы | |
| Рамазан аенда гомрә | | | |

# ХАЖ
# КИТАБЫ

## ХАЖ КИТАБЫ

**Хаж** — ул Аллаһның илчесе ﷺ сөннәтенә муафыйк рәвештә билгеле бер йолаларны үтәү аша Аллаһка гыйбадәт кылу.

**Гомрә** — ул Кәгъбә тирәли тәваф кылу, Сафа һәм Мәрва тауларында йөрү, чәчләрне кыру яки кисү гамәлләрен башкару аша Аллаһка гыйбадәт кылу.

Әлеге йолаларның нигезендә корбан чалу ята. Хаж һәм Гомрә йола дип аталганнар, чөнки аларны үтәгән вакытта корбан чалына һәм сәдакалар бирелә.

## ПӘЙГАМБӘРНЕҢ ХАҖЫ ТАСВИРЛАНГАН ҖӘБИР ХӘДИСЕ

Нигезендә Аллаһ Тәгаләнең сүзләре ята: **«Кешеләр Аллаһ каршында Кәгъбәтуллага хаж кылырга тиеш, әгәр аларның бу юлны үтәргә мөмкинлекләре булса».**

**Хаж фарыз булсын өчен алты шарт үтәлү мөһим:**

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 1.Ислам | 2.Гакыл | 3.Балигъ-лыкка ирешү | 4.Ирекле булу | 5.Мөмкинлекләр булу | 6.Әгәр хаж гамәлен үтәү өчен сәфәргә чыгарга туры килсә, хатын-кызны мәхрәм озатып йөрергә тиеш. |

| **Мөмкинлек булу —** иң мөһим шарт һәм ул менә нәрсәләрне аңлата | |
|---|---|
| Кешегә барлык кирәк әйберләрдән [*алардан башка кеше яши алмый*] һәм аның төп ихтыяҗларыннан тыш [*алардан тыш кеше яши ала, әмма авырлык белән*], ризыгы һәм транспорты булу. | Әгәр хаҗ гамәлен үтәү өчен сәфәргә чыгарга туры килсә, хатын-кызны мәхрәм озатып йөрергә тиеш. [Мәхрәм өчен шартлар: ислам, тәклиф, ир затыннан булу]. |

Пәйгамбәрнең ﷺ хаҗы тасвирланган Җәбир хәдисендә хаҗга кагылышлы иң мөһим боерыклар урын алган.

Җәбир ибн Габдуллаһ сүзләреннән, Аллаһ аларның икесеннән дә риза булсын, Мөслим ошбу хәдисне китерде: ***Пәйгамбәр ﷺ Мәдинәдә яшәгән тугыз ел дәвамында бер дә хаҗ кылмады. Унынчы елда Аллаһ илчесенең ﷺ хаҗ кылу турындагы нияте барлыгы хәбәр ителде, һәм Мәдинәгә бик күп кеше килде. Аларның барысы да Аллаһның илчесен ﷺ озатып барырга һәм ул үтәгән йолаларны кабатлап үтәргә телиләр иде.[Мөкәлләфкә хаҗ шунда ук фарыз була].***

***— Без юлга чыктык һәм Зүль-Хуләйфәгә җиттек. Бу вакытта Әсма бинт Гөмәйс Мөхәммәд ибн Әбү Бәкрне тудырды. Ул Аллаһның илчесе ﷺ янына үзенә нишләргә кирәклекне белү өчен бер кешене җибәрде. Ул әйтте: «Коен, шуннан соң озын һәм киң чүпрәк материя ярдәмендә кан аккан урынны бәйлә. Шуннан соң син ихрамга керә алырсың».*** [Гайшә, Аллаһ аннан риза булсын, хәдисендә болай дип хәбәр бирелә: аның хәйд халәте башлангач, Пәйгамбәр ﷺ аңа: ***«Кәгъбә тирәли тәваф кылудан тыш, хаҗ кылучылар кылырга тиешле гамәлләрнең барысын да кыл. Ә Кәгъбә тирәли әйләнү йоласын чистарынгач үти аласың»,— дигән]. Аллаһның илчесе ﷺ мәчеттә ике рәкәгать намаз укыды, шуннан соң ул әл-Касвәгә утырды. Аның дөясе Әл-Байдка җиткәч, ул, кычкырып, шәһәдәт сүзләрен әйтте: «Менә мин Синең каршыңда, Йә Аллаһ! Менә мин Синең каршыңда! Менә мин Синең каршыңда, һәм Синнән башка табынырга лаеклы зат юк! Менә мин Синең каршыңда! Чынлыкта, Сиңа барча мактау, һәм барча рәхмәт һәм хакимлек Синеке! Һәм Сиңа тиң юк».***

***— Барлык кешеләр дә аның артыннан шушы сүзләрне кабатладылар, һәм Аллаһның илчесе ﷺ аларга каршы сүз әйтмәде.***

***— Киресенчә, ул һаман саен тәлбия сүзләрен кабатлады.***

***— Ә безгә килгәндә, безнең һәрберебез дә хаҗ кылырга дип ниятләде, чөнки без Гомрә хаҗын ничек үтәргә кирәклеген белми идек.***

***— Аллаһның илчесе ﷺ белән бергә Кәгъбәтуллага килеп җиткәч,ул аның почмагына кагылды,***

***— Шуннан соңаның тирәли өч тапкыр тиз итеп, ә дүртенчесен салмак адымнар белән әйләнде.***

***— Шуннан соң ул Ибраһим, Аллаһның сәламе булсын, урынына килеп җитте һәм ошбу сүзләрне укыды: «Ибраһимның урынын намаз уку урыны итегез».***

***— Ул Ибраһим урыны үзе белән Кәгъбә арасында булырлык итеп басты,***— икенче хәдистә килгәнчә: ***«әл-Ихлас» һәм «Әл-Кәфирун» сүрәләрен укып, ике рәкәгать намаз үтәде.***

***— Шуннан соң ул Кәгъбәнең почмагына килеп, янәдән аңа кагылды.***

***— Шуннан соң ул капкалар аша чыгып, Сафа тавына китте. Аңа якынайганда ул: «Хакыйкатьтә, Сафа һәм Мәрва — Аллаһның йола билгеседер»,— дип укыды. Ул сафадан башлады һәм тауга менде, аннан Кәгъбә күренә иде. Шуннан соң ул аңа йөз белән борылып басты,***

***— Шәһәдәт сүзләрен әйтте, Аллаһны мактады һәм әйтте: «Аллаһтан башка табынырга лаеклы зат юк, Аның тиңе юк! Аңарда барча хакимият һәм барча мактаулар, һәм Ул барча нәрсәгә кодрәтле! Бер Аллаһтан башка табынырга лаеклы илаһ юк! Ул үзенең сүзен үтәде, Үзенең колына ярдәм итте һәм Берүзе берләшкән дошманны җиңде». Бу сүзләрне ул өч тапкыр әйтте, ә әйтүләр арасында Аллаһка дога белән мөрәҗәгать итте.***

***— Шуннан соң ул таудан Мәрва юнәлешенә таба төшә башлады. Үзәнлеккә төшкәннән соң, ул йөгерә башлады, ә калкулыкка җиткәндә, атлауга күчте. Мәрвага менгәннән соң, ул бар нәрсәне дә Сафадагы кебек эшләде.***

***— Мәрвада соңгы йөгерүне тәмамлаганнан соң, ул әйтте: «Әгәр мин хәзер белгән нәрсәләремне иртәрәк белгән булсам, корбанга дигән куаламас идем һәм Гомрә хаҗын үтәр идем».***

— Шулвакыт Сурака ибн Мәлик ибн Джугъшум торып басты һәм сорады: *«Йә Аллаһның илчесе, бу безгә быел гына кылырга боерылдымы, әллә бөтенләйгәме?»* ***Аллаһның илчесе ﷺ, кул бармакларын кушырып, әйтте: «Гомрә хаҗга керә. Гомрә хаҗга керә, һәм ул сезгә бөтенләйгә боерылды».***

***— Бу вакытта Пәйгамбәребез өчен корбанга чалынырга тиешле маллар белән Йәмәннән Гали килде һәм ихрамнан чыккан Фатыйманы күрде. Ул буялган тукымадан тегелгән кием кигән иде, үзе дә сөрмә тарткан иде. Гали аны моның өчен шелтәләде, ә Фатыйма болай диде: «Минем әтием миңа шулай эшләргә боерды». Гали Гыйракта булган вакыттаул Аллаһның илчесе ﷺ янына барганлыгы хакында сөйләде, аның нияте Фатыйманың бу гамәле турында сораштырып, ул сөйләгән нәрсәләр хакында Пәйгамбәрнең фикерен белү булды. Фатыйманы шелтәләве турында сөйләгәч, Пәйгамбәр ﷺ әйтте: «Ул дөресен әйткән! Ул дөресен әйткән! Хаҗ кыла башлаганда син нәрсә әйткән идең? Гали җавап бирде: «Йә Аллаһ! Мин Синең Пәйгамбәрең эшләгәннәрне үтәргә ниятлим!» Шуннан соң Пәйгамбәр ﷺ әйтте: “Минем белән корбан маллары, шуңа күрә ихрамнан чыкма».***

***— Гали Йәмәннән үзе белән һәм Пәйгамбәребез, аңа Аллаһның сәламе һәм рәхмәте булсын, алып килгән корбан маллары барысы бергә йөз баш булдылар.***

***— Кешеләр ихрамнан чыктылар һәм чәчләрен кистеләр. Бу гамәлне бары тик Пәйгамбәр ﷺ һәм корбан маллары булган кешеләр генә үтәмәде.***

***— Ә әт-тарвийә көне килеп җиткәч (зөл-хиҗҗә аеның 8нче көне), алар, хаҗ башлануын хәбәр биреп, Мина үзәненә юл тоттылар.***

***— Аллаһның илчесе ﷺ дөя өстендә барды. Шунда ул өйлә, икенде, ахшам, ястү һәм иртәнге намазларны үтәде*** [ике рәкәгатьлеләрне кыскартып]**.**

*— Анда кояш чыкканын көтеп,*

*— ул Намира тавында йон шатер куярга боерды.*

*Аллаһның илчесе ﷺ юлга кузгалгач, корәешләр аның Мөздәлифә үзәнендә туктаячагына шикләнмиләр иде, җаһилият вакытында да корәешләр шулай эшли иде. Әмма Аллаһның илчесе ﷺ Гарәфәт тавына җиткәнче юлын дәвам итте. Аның өчен Намира тавында шатер инде куелган иде, һәм ул шунда тукталды.*

*— Өйлә вакытыннан соң ул янына әл-Касвәне китерүләрен боерды.*

*— һәм аның өстендә Гарәфәт үзәнлегенә төште, анда ул кешеләргә вәгазь белән мөрәҗәгать итте, ул вәгазендә Пәйгамбәр болай диде: «Хакыйкатьтә, бу көн, бу ай, һәм бу җир изге булган кебек сезнең каннарыгыз һәм милекләрегез кагылгысыз һәм изге. Җаһилият вакытында кылынган барлык гамәлләр дә бүгеннән тыела! Җаһилият вакытында коелган кан тыела, һәм иң беренче мин сезне безнең туганыбыз Рабиг ибн әл-Харисның улының каны өчен үч алудан тыям. Аны бану сагъд кавеменнән булган имезүче хатынга бирделәр, һәм хузейл кавеме аны үтерде. Җаһилият заманнарында киң таралган ришвәтчелек тыела, һәм иң беренче мин сезгә Габбас ибн Гәбд әл-Мутталиб нәселе тарафыннан алынучы ришвәтне тыям. Бүгеннән ришвәтчелек гомумән тыела! Хатын-кызларыгыз белән мөгамәлә кылганда Аллаһтан куркыгыз, чөнки сез аларны хатынлыкка Аллаһ сезгә ышануы аркасында алдыгыз һәм сез алар белән Аллаһ Сүзе буенча яшисез. Алар сезнең ятагыгызда сез сөймәгән кешене утыртмаска тиешләр, әгәр алар сезнең сүздән чыкса, аларны, күрсәтмичә генә кыйнагыз. Ә сез аларны акылга муафыйк рәвештә ашатырга һәм киендерергә тиешсез! Чынлыкта, әгәр сез мин сезгә калдырган нәрсәгә ныклап ябышсагыз, беркайчан да адашуда булмаячаксыз. Бу — Аллаһның китабы. Сездән минем хакта сорасалар, сез нәрсә дип җавап бирерсез?» Кешеләр җавап бирделәр: «Син үзеңә йөкләтелгән вазифаңны үтәдең һәм безгә дөрес үгет-нәсихәт бирдең, дип шаһәдәт бирәбез». Аллаһның илчесе ﷺ күрсәтү бармагын күккә таба күтәрде, шуннан соң аның белән кешеләргә күрсәтте һәм өч тапкыр әйтте: «Йә Аллаһ, шаһит бул! Йә Аллаһ, шаһит бул! Йә Аллаһ, шаһит бул!»*

***— Шуннан соң Биләл азан әйтте һәм намаз башлануын хәбәр итте.***

***Шуннан соң тагын бер мәртәбә азан әйтеп намаз башлануын белдерделәр, һәм ул икенде намазын укыды*** [2әр рәкәгать].

***— Әлеге ике намаз арасында ул өстәмә намазлар башкармады.***

***— Шуннан соң ул үзенең дөясенә утырды һәм Гарәфәт тавына басып тору урынына юнәлде.***

***— Ул хаҗ кылучы җәяүлеләр бара торган сукмакта шул рәвешле туктады ки, аның дөясенең корсагы кыялар биеклегендә иде. Ул йөзе белән кыйблага таба юнәлде.***

***— һәм кояш баерга якынлашканчыга кадәр шунда булды. Тиздән кояшның яктысы бетте, ул күздән югалды.***

***— Усама ибн Зәйд дөягә атланды һәм Аллаһ илчесенең ﷺ, аны саклау нияте белән, артына басты. Аллаһның илчесе ﷺ әл-Касвәнең йөгәнен каты итеп тотты ки, аның башы өзәңгеләргә терәлде.***

***— Үзенең уң кулын алга сузып, ул болай диде: «Әй кешеләр, тынычлыкны саклагыз! Тынычлыкны саклагыз!» Ком өемнәренә җитәрәк, ул, дөягә аларны кичәргә җиңелрәк булсын өчен, йөгәнне йомшарта иде.***

***— Мөздәлифәгә барып җиткәннән соң, ул анда ахшам һәм ястү намазын укыды*** [2 рәкәгать], ***намазга чакыру бер тапкыр гына әйтелде, ә һәр намазның башлануы хәбәр ителде. Ике намаз арасында ул Аллаһны зикер итмәде.***

***— Шуннан соң ул таң атканчыга кадәр ял итәргә дип ятты. Иртәнге шәфәкъ күренүгә, намазга чакырып азан әйтелде һәм намаз башлануы турында хәбәр ителде, шуннан соң ул иртәнге намазны башкарды.***

***— Шуннан соң ул әл-Касвәгә утырда да әл-машгар әл-харам урынына килеп җитте.***

***— Шуннан соң ул әл-Касвәгә утырда да әл-машгар әл-харам урынына килеп җитте.***

***— Анда ул йөзе белән кыйблага юнәлде, Аллаһка дога белән мөрәҗәгать итте, Аны мактады, шәһәдәт сүзләрен әйтте һәм таң атканчы шунда басып тора бирде.***

***— Кояш чыгар алдыннан ул үзенең юлын дәвам итте, ә аның артына әл-Фадль ибн Габбас утырды... Шул рәвешле алар Мухассир үзәненә барып җиттеләр, һәм ул кызуланыбрак китте. Зур баганага илтүче үзәк юлдан барып,***

***— алар янында агач үсеп утыручы багана янына килеп җиттеләр. Алар аңа Аллаһны мактап, һәр атуда җидешәр кечкенә таш аттылар. Аллаһның илчесе ﷺ ташларны түбән җирдән алып атты.***

***— Шуннан соң ул корбан чалу урынына юнәлде һәм үз куллары белән алтмыш өч дөяне чалды.***

***— Калган дөяләрне Гали чалды, ә Аллаһның илчесе ﷺ аңа булышты.***

***— Шуннан соң ул һәр түшкәдән берәр кисәк ит алырга һәм казанга салып пешерергә боерды. Ризык әзер булгач, алар иттән һәм шулпадан авыз иттеләр. Шуннан соң Аллаһның илчесе ﷺ үзенең дөясенә утырып Кәгъбә янына китте***

***— һәм өйлә намазын Мәккәдә укыды.***

***— Шуннан соң ул Зәмзәм чишмәсеннән суны бүлүче Гәбд әл-Мотталиб нәселе кешеләре янына килде һәм әйтте: «Әй Гәбд әл-Мотталиб нәселе дәвамчылары, миңа су алып бирегез. Әгәр мин сезне кешеләр моннан кысрыклап чыгаруларыннан курыкмасам, суны сезнең белән бергә үзем алган булыр идем». Алар аңа чишмәдән чиләк белән су алып бирделәр, һәм ул аннан туйганчы су эчте».*** Мөслим.

Хаҗның йолаларын үтәгәндә ул кешеләргә әйтә иде: ***«Хаҗның йолаларын миннән алыгыз».*** Иң камил хаҗ — Пәйгамбәребез ﷺ һәм аның сәхәбәләре, Аллаһ аларның барысыннан да риза булсын, үрнәгендә үтәлгән хаҗ ул.

<table>
<tr><th colspan="3">Хаҗның әркәннәре һәм фарыз гамәлләре</th></tr>
<tr><td colspan="3">Әгәр хаҗны үтәүче кеше ошбу гамәлләрне үтәү белән генә чикләнсә:</td></tr>
<tr><td rowspan="2">4 әркән</td><td>1.Ихрам.</td><td>2.Гарәфәдә тору.</td></tr>
<tr><td>3.Кәгъбә тирәли әйләнү.</td><td>4.Бару.</td></tr>
<tr><td rowspan="3">Һәм фарыз гамәлләр</td><td>1.Микатта ихрам.</td><td>2.Кояш баеганчы Гарәфәдә басып тору.</td></tr>
<tr><td>3.Корбан бәйрәменә каршы төнне Мөздәлифәдә үткәрү.</td><td>4.Тәшрикъ көннәренең төннәрен Минада үткәрү.</td></tr>
<tr><td>5.Таш ату.</td><td>6.Чәчләрне кыру яки кисү.</td></tr>
<tr><td colspan="3">хаҗның үтәлүе өчен шул җитә.<br><br>Хаҗда әркәнне калдыру белән фарыз гамәлне калдыру арасындагы аерма шуннан гыйбарәт:</td></tr>
<tr><td>Әгәр хаҗның әркәне төшеп калса: Шәригать кушканча үтәлгәнчегә кадәр хаҗ дөрес түгел.</td><td colspan="2">Әгәр фарыз гамәл төшеп калса: хаҗ дөрес була, әмма аны төшереп калдырган кеше гөнаһлы була һәм корбан чалырга тиеш.</td></tr>
</table>

<table>
<tr><th colspan="4">Хаҗның 4 әркәненә аңлатма:</th></tr>
<tr>
<td>1.Ихрам — бу хаҗ кылу гамәленә керешү өчен ният, ә тәлбия әйтү яки ихрам кию түгел.</td>
<td>2. Гарәфәдә басып тору — Зөл-Хиҗҗә аеның тугызынчы көнендә кояш зәвалдән авыша башлаган мизгелдән алып бәйрәм көненең таңы атканчыга кадәр. Пәйгамбәр ﷺ әйтте: «Хаҗның мәгънәсе — Гарәфәдә тору». Хәдисне «Сунан китабының» кайбер авторлары китерде.</td>
<td>3. Кәгъбә тирәли соңгы тәваф. Бу Кәгъбә тирәли әйләнү, ул Гарәфә тавында торганнан соң кылына.</td>
<td>4.Йөру — Сафә һәм Мәрва таулары арасында йөру һәм йөгеру. Аллаһ Тәгалә әйтте: «Сафа һәм Мәрвә таулары, әлбәттә, Аллаһка гыйбадәт кыла торган урыннарның билгеләредер».</td>
</tr>
</table>

| Хаҗның фарыз һәм сөннәт гамәлләре | | | |
|---|---|---|---|
| 1.Микатта ихрам. | 2.Кояш баеганчыга кадәр Гарәфәдә тору. | 3.Мөздәлифәдә төн уздыру. | 4.«Тәшрикъ көннәре» төннәрен Минада үткәрү. |
| 5.Ташлар ату. | 6.Чәчләрне кыру яки кисү. | 7.Мәккәдән китәргә җыенган (хәтта әле берничә айдан соң гына китәм, дип ниятләсә дә) һәркем өчен Кәгъбә тирәли саубуллашу тәвафын кылу. Бу гамәлне хәез һәм нифас халәтендәге хатын-кызлар кылмый(автор бу пунктны телгә алмады). | |

| Олы хаҗ һәм гомрәнең микатлары | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1.Вакыты | | 2.Урыны (Олы хаҗ өчен дә, гомрә өчен дә) | | |
| *Олы хаҗның*: айлары: шәвәл, зөл-кагъдә, зөл-хиҗҗә | *Гомрә:* билгеле бер вакыты юк | А. Мәдинә һәм аның аша үткәннәр өче Әл-Хуләйфа. | Б. Шам, Мисыр һәм Мәгърib өчен Әл-Джухфә | В. Нәжд өчен Карн әл-Мәнәзиль |
| | | | | Г. Йәмән өчен Яләмләм |
| | | | | Д. Гыйрак өчен Зату Гирк |

| Хаҗның үтәлергә тиешле гамәлләре | | |
|---|---|---|
| 1.Ихрам алдыннан госел коену һәм исле-майлар сөртү | 2.Ир-атларга ак төстәге ике тукымага төренү тиешле | 3.Ихрамга кадәр тырнак кисү һәм кырылырга тиешле чәчләрне кыру. |
| 4.Ихрамнан соң һәм гакабәгә таш атканга кадәр тәлбия уку | 5. «Ифрад» һәм «кыйран» ысулы белән хаҗ кылучыларга сәламләү тәвафы кылу. | 6. «Тәмәттугъ» ысулы белән хаҗ кылганда сәламләү тәвафының беренче өч әйләнешендә һәм гомрә хаҗында тәваф әйләнгәндә тиз-тиз атлау. |

| | | |
|---|---|---|
| 7. «Тәмәттугъ» ысулы белән хаҗ кылучыларга сәламләү тәвафында яки гомрә вакытындагы тәвафта уң як җилкәне ачу. | 8. Мөздәлифәгә килгәч, төнге намазны кичке намаз вакытында уку. | 9.Минада Гарәфә кичен уздыру. |
| 10.Кара ташны үбү. | 11.Мөздәлифә үзәнлегендә таң атканнан алып кояш чыкканчыга кадәр булу. | |

## ХАЖ ЙОЛАЛАРЫ

<table>
<tr><td colspan="4">Ихрамга керергә теләүчеләр хаж кылу ысулларын үзләре сайлый: тәмәттугъ — иң яхшы ысул, кыйран яки ифрад.</td></tr>
<tr><td rowspan="2">1.Тәмәттугъ — бу вакытта кеше Хаж аенда Гомрә үтәү өчен ихрамга керә, аны үтәгәч ихрамнан чыга, һәм шул ук елны Олы Хаҗны үти. Моннан тыш ул, әгәр Әл-харам мәчетендә булмаса, корбан да чалырга тиеш.</td><td rowspan="2">2.Ифрад — бу кешенең бары тик Олы Хаҗны үтәргә генә (кече хаж — Гомрә хаҗын үтәмичә генә) ният кылуы.</td><td colspan="2">3.Кыйран</td></tr>
<tr><td>Бу кешенең олы хаж белән гомрәне бергә үтәве.</td><td>Кеше гомрәне үтәргә керешеп, шуннан соң тәваф кылганчы (гомрә вакытында) олы хаҗны үтәве.</td></tr>
<tr><td colspan="4">Тәмәттугъны үтәүче шушы ысулны сайларга мәҗбүр:</td></tr>
<tr><td colspan="2">1.Әгәр гомрә хаҗын кылу сәбәпле Гарәфә тавында торуга өлгермәүдән курыкса</td><td colspan="2">2.Әгәр хатын-кызның хәез яки нифас вакыты башланса, һәм ул Гарәфә тавында торганчы чистарынып бетмәячәген белсә.</td></tr>
<tr><td colspan="4">Ифрад һәм кыйран ысуллары бер төрле үк кылына, әмма кыйран ысулы белән хаҗны үтәүче кеше корбан да чалырга тиеш.</td></tr>
</table>

## ИХРАМ ВАКЫТЫНДА ТЫЕЛГАН ГАМӘЛЛӘР

<table>
<tr><th colspan="3">Ихрам вакытында хаҗ кылучы кеше ошбу гамәлләрне кылудан саклanырга тиеш:</th></tr>
<tr><td>1.Чәчләрне кыру</td><td>2.Тырнакларны кисү</td><td>3.Әгәр ир-ат булса, тегелгән кием кию</td></tr>
<tr><td colspan="2">4.Ир-ат булса, башка кию</td><td>5.Ислемай сөртү (ир-атларга да, хатын-кызларга да)</td></tr>
<tr><td colspan="2">6.Шулай ук аңа тыелган: киек ауларга, аулаучы кешегә аны күрсәтергә һәм ауларга ярдәм итәргә.</td><td>7.Ихрамдагы иң төп тыю: женси якынлык. Әлеге гамәл катгый рәвештә тыела, ул йоланы боза һәм аның өчен штраф — корбан чалу каралган.</td></tr>
</table>

<table>
<tr><th colspan="3">Ихрамда булганда тыелган гамәлләр 9:</th></tr>
<tr><td colspan="3">— Әгәр болар арасыннан берәрсе онытылып, белмичә яки мәҗбүр ителеп кылынса, монда гөнаһ юк.<br><br>— Әмма әгәр дә хаҗ кылучы кеше киекне үтерсә, нинди генә очрак булса да, ул барыбер штраф түләргә тиеш.</td></tr>
<tr><td rowspan="2">1. Штраф салынмый</td><td colspan="1">1) Никах укыту: үзеңнеке яки кешенеке</td><td rowspan="2">Бу очракта хаҗ кылучы штраф түләми, әмма ул тәүбә итәргә тиеш.</td></tr>
<tr><td>2) Женси якынлык кылмыйча һәм мәни чыкмыйча якынлык</td></tr>
<tr><td rowspan="2">3. Катгый штраф</td><td rowspan="2">4) Женси якынлык</td><td>А.Беренче тәхәллүлгә кадәр 4 нәтиҗәгә китерә:1.хаҗны боза, 2.хаҗны үтәгән елны хаҗ бозык килеш кала, 3.каза кылырга тиеш, 4.корбан чалырга тиеш.</td></tr>
<tr><td>Б.Беренче тәхәллүлән соң фарыз тәвафка кадәр шулай ук 4 нәтиҗәгә китерә: 1.гөнаһ язылa, 2.ихрамны боза, 3.Харам мәчете тышына чыгып, янәдән ихрамга керергә кирәк, 4.Корбан чалырга кирәк</td></tr>
</table>

| | | |
|---|---|---|
| 4. Җиңелчә штраф | 5.Баштагы яки тәндәге чәчләрне кыру | Бу очракларда штраф сайлап түләнә: яки өч ураза, яки, һәрберсенә дә ярты сагъ ризык бүлеп биреп, 6 ярлыны ашату, яки сарык чалып, итен Харамдагы мохтаҗларга бүлеп бирү. |
| | 6.Тырнакларны кисү | |
| | 7.Ир-атларга башны каплау | |
| | 8.Ир-атларга тегелгән кием кию. | |
| | 9.Хатын-кызларга никаб яки перчаткалар кию | |

<table>
<tr><th colspan="6">Салынган зыян өчен штраф түләү хөкемнәре:</th></tr>
<tr><td colspan="3">1.Әгәр хаҗ кылучы ир-ат башын капласа һәм тегелгән киемнәр кисә, ә хаҗ кылучы хатын-кыз йөзен капласа һәм перчаткалар кисә яки алар исле-майлар сөртсә, аларга сайлау мөмкинлеге бирелә:</td><td colspan="3">2.Әгәр хаҗ кылучы кеше киекне үтерсә, аңа да сайлау мөмкинлеге бирелә:</td></tr>
<tr><td>А. Өч ураза.</td><td>Б. 6 ярлыны ашату.</td><td>В. Сарык чалу.</td><td>А.Әгәр мал-туары булса, шундый ук мал чалу.</td><td>Б. Үтерелгән киекнең бу җирлектәге бәясен исәпләп чыгарырга, шул бәягә ризыклар сатып-алып һәр ярлыга 1 мудда бодай яки башка азык-төлектән яртышар сагъ бүлеп бирү.</td><td>В. Һәр ярлы өчен берәр ураза тоту.</td></tr>
</table>

<table>
<tr><td colspan="2">Тәмәттугъ яки кыйран хаҗында корбан чалу мәсьәләләренә килгәндә, корбанга чалынасы мал Корбан бәйрәмендә чалынырга яраклы мал кебек булырга тиеш. Әгәр андый мал булмаса, бу вакытта 10 көн ураза тотарга тиешле:<br><br>— хаҗда 3 көн [уразаны хаҗ яки гомрә өчен ихрамга кергән вакыттан алып тота башларга мөмкин һәм аның вакыты соңгы тәшрикъ көнендә тәмамлана]. Шулай ук тәшрикъ көннәрендә дә ураза тотарга мөмкин.<br><br>— һәм өйгә кайткач 7 көн ураза. [Әгәр бөтен уразаларны шул урында хаҗ тәмам булгач үтәсәң, гөнаһ юк].<br><br>Ошбу гамәлләрне кылган кешеләр дә шундый ук хөкемдә:</td></tr>
<tr><td>1.Хаҗның фарыз гамәлен төшереп калдырган кеше</td><td>2.Якынлык кылу сәбәпле штраф түләргә тиешле кешеләр.</td></tr>
</table>

Ихрам яки Харам мәчете белән бәйле булган ризыкны яки корбан итен Харамдагы (Мәккәдә яшәүчегә дә һәм килгән кешегә дә) ярлыларга өләшергә кирәк.

Барлык җирләрдә дә ураза тоту рөхсәт ителә.

Тәмәттугъ, кыйран һәм штрафны (хадью) үтәгәндә чалынган корбан итен үзеңә ашарга һәм бүләк һәм сәдака итеп өләшү хәерле.

Ә тыелганны кылган яки фарыз гамәлне калдырган өчен чалынган фарыз корбанының итенең бер өлешен дә үзеңә калдырырга ярамый, ә сәдака сыйфатында таратып бетерергә кирәк.

## [ТӘВАФ ҺӘМ АТЛАП ЙӨРҮ ШАРТЛАРЫ]

| Тәвафның гомуми шартлары: | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.Ният | 2.Таштан башлау | | | 3.Кәгъбә сул якта булырлык итеп басу | 4.Жиде тулы әйләнеш ясау | 5.Пычрак һәм нәҗестән чистарыну. |
| | Анда кагылу һәм үбү тиешле | Әгәр бу мөмкин булмаса, бармак белән күрсәтү | һәм ошбу сүзләрне әйтү: بسم الله ألله أكبر اللّٰهُمَّ إيمانا بك و تصديقا بكتابك و وفاء بعهدك و اتباعا لسنة نبيك محمد *«Аллаһ исеме белән, Аллаһ бөек! Йә Аллаһ, Сиңа инанабыз, Синең Китабының хаклыгын таныйбыз, Сиңа бирелгән антны үтибез һәм Синең Пәйгамбәреңнең Сөннәтенә иярәбез».* | | | |

Хаҗның тәвафтан башка йолаларын башкарганда госел коену фарыз түгел, ә сөннәт.

Хәдистә хәбәр ителә: ***«Кәгъбә тирәли тәваф кылу намазга тиң. Аерма бары шунда: тәваф вакытында Аллаһ сөйләшергә рөхсәт итте».*** Тирмизи.

Ошбу гамәлләрне эшләү тиешле:

| | |
|---|---|
| 1.Сәламләү тәвафын кылганда уң як җилкәне ачу | 2.Һәм беренче 3 әйләнешне әкрен генә йөгерергә, ә калган 4 әйләнешне атлап барырга кирәк. |

Әлеге тәвафтан кала башка тәвафларда җилкәне ачу һәм әкрен йөгерү сөннәт түгел.

Йөрүнең шартлары:

| | | |
|---|---|---|
| 1.Ният | 2.7 тапкыр йөгерү | 3. Сафа тавыннан башлау. |

Хаҗ кылучыга тәваф кылганда, йөргәндә һәм башка хаҗ йолаларын башкарганда күп тапкырлар Аллаһны искә алу һәм Аңа дога белән ялвару тиешле, чөнки Пәйгамбәр ﷺ әйтте: ***«Чынлыкта, Кәгъбә тирәли тәваф кылу, Сафа һәм Мәрва таулары арасында йөгерү һәм җәмәрәтләргә таш ату сезгә Аллаһны зикер итү өчен тиешле кылынды». [Хәдисне «Сунан» китабының кайбер авторлары китерде].***

Әбу Хурайра, Аллаһ аннан риза булсын, сүзләреннән китерелә: «Аллаһ Тәгалә Үзенең Рәсүленә Мәккә шәһәрен яулап алырга рөхсәт биргәч, ул кешеләр каршысына басты, Аллаһны мактады һәм әйтте: ***«Чынлыкта, Аллаһ Тәгалә филне Мәккәгә басып керүдән туктатты, әмма Үзенең Рәсүленә һәм иманлы бәндәләренә бу шәһәрне яулап алырга рөхсәт бирде. Миңа кадәр беркемгә дә Мәккәдә сугышырга рөхсәт ителмәде, һәм миннән соң беркемгә дә рөхсәт ителмәс. Чынлыкта, минем өчен дә бу көн дәвамында бер генә сәгатькә рөхсәт ителде, ә хәзер ул янәдән тыелган территориягә керә, биредә ошбу гамәлләрне эшләү тыела:»***

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1.Чәнечкеләрне кисәргә | 2.Агачларны кисәргә | 3.Монда табылган милекне бары тик табылдык турында әйтер өчен генә алырга ярый. | 4.Әгәр берәр кешене үтерсәләр, аның иң якын туганнары икенең берсен сайлый ала: яки үтерелгән кеше өчен түләү алырга, яки үтерүченең гамәле белән тиң әҗерен бирергә». | 5. Габбас әйтте: *«Йә Аллаһның илчесе, безнең каберләребез һәм өйләребезне төзекләндерү өчен кулланылучы хуш исле камыштан кала!»* — һәм шулчак Пәйгамбәр ﷺ әйтте: ***«Хуш исле камыштан кала».*** Килешенгән хәдис. |

Пәйгамбәр ﷺ әйтте: ***«Мәдинә шәһәре Гаир тавыннан алып шул-шул урынга кадәр тыелган».*** Мөслим.

Ул әйтте: ***«Биш җан иясе зыян сала һәм изге Харам җирендә дә үтерелә:***

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1.***Карга*** | 2.***Тилгән*** | 3.***Чаян*** | 4.***Тычкан*** | 5.***Котырган эт».*** Килешенгән хәдис |

Этләр өч төрле була:

| | | |
|---|---|---|
| 1.Котырган: үтерергә кирәк. | 2. Кара: үтерергә мөмкин. | 3.Башка төрле: әгәр ул зарар китермәсә, үтерү тыелган |

## ШТРАФ СӘБӘПЛЕ, КОРБАН ГАЕТЕНДӘ ҺӘМ БАЛА ТУГАЧ КОРБАН ЧАЛУ

Югарыда штраф сәбәпле корбан чалу фарыз дип, ә башка очракларда сөннәт дип әйтелде. Моңа бәйрәмдә корбан чалу да, бала тугач корбан чалу да керә.

Корбан гаетендә корбан чалу мәсьәләсенә килгәндә, мөмкинчелеге булган мөселманга, чалмыйча калдырырга ярамый, чөнки Аллаһның илчесе ﷺ әйтте: ***«Мөмкинчелеге булып та корбанга мал чалмаган кеше без намаз укый торган урынга якын да килмәсен».*** Ибн Мәджә, Әхмәд.

Ул шулай ук әйтте: ***«Әгәр 10 көнлек башланса һәм сезнең арадан кемдер корбан чалырга ниятләсә, ниятен тормышка ашырганчы үзенең тырнакларын һәм чәчләрен кисмәсен»*** — башка хәдистә: ***«һәм тиресен дә»***.

Корбанга чалу өчен бары тик яше түбәндәгечә булган мөгезле эре яки мөгезле вак терлек кенә ярый:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1.Ярты яшьлек сарык | 2. Пар тояклы хайваннардан: | | |
| | А. Дөя: биш яшьлек | Б. Сыер: ике яшьлек | В. Кәҗә: бер яшьлек |

Сәламәт һәм һәртөрле кимчелекләрсез булуы корбан малының мәҗбүри шарты булып тора. Пәйгамбәр ﷺ әйтте: ***«Корбан итеп ошбу дүрт төр хайванны чалырга ярамый:***

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1.***Кимчелеге күренеп торган бер күзле малны,*** | 2.***Авыру икәнлеге күренеп торган малны,*** | 3.***Аксаклыгы күренеп торган аксак малны,*** | 4.***Һәм хәлсезлеге күренеп торган хәлсез малны».*** Дөрес хәдис, 5 шәех китерә. |

Корбанга чалынасы мал яхшы һәм камил сыйфатлар ия булырга тиеш. Корбанга әзерләнгән мал яхшырак булган саен, Аллаһка ул күбрәк ошаячак, һәм аның хуҗасы да әҗер-савапны күбрәк алачак.

Джәбир әйтте: ***«Худайбиядә без Пәйгамбәр белән җиде кешедән дөя, җиде кешедән сыер чалдык».*** Мөслим.

Бала тугач, әти кешегә [яки тәрбиячесенә] корбан чалу тиешле:

| | |
|---|---|
| 1.Малай өчен: ике сарык | 2.Кыз өчен: бер сарык |

**Бала тугач, корбан чалу ошбу көннәрдә башкарыла:**

<table>
<tr><td colspan="2">1.7нче көнгә. Әгәр бала шимбә көн туган булса, корбан җомга көнне чалына.</td><td>2. Әгәр 7нче көнендә чалынмаса, 14нче көнгә.</td><td>3.Әгәр ул көндә дә чалынмаса, 21нче көндә.</td></tr>
<tr><td colspan="4">Корбан чалу җан өрелгән һәр бала өчен тиеш, хәтта ул үле туса да.</td></tr>
<tr><td colspan="4">7нче көнгә шулай ук ошбу гамәлләрне үтәүтиешле була:</td></tr>
<tr><td>1. Әгәр иртәрәк бирелмәгән булса, балага исем кую.</td><td>2. Малайның чәчләрен кыру</td><td colspan="2">3.Баланың чәче авырлыгында көмеш акча белән сәдака бирү.</td></tr>
</table>

Пәйгамбәр ﷺ әйтте: ***«Һәрбер ир бала үзенең гакыйкасының тоткыны, Корбан ул тугач 7нче көнгә чалына, шул көнне аның чәче алына һәм исем кушыла».*** Дөрес хәдис, 5 шәех китерә.

Югарыда саналган корбаннарның итен үзеңә ашарга да, күчтәнәчкә бирергә дә, сәдака итеп өләшергә дә ярый.

Корбан чалган кешегә бу иттән түләргә ярамый. Ит аңа күчтәнәч яки сәдака итеп бирелә

## [КЫСКАЧА]

| Хаҗ көннәре исемнәре: | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. әт-Таруийа: 8 нче көн; Бу көндә кешеләр Минага су алып килә | 2.Гарәфә көне: яки Гарәфәдә тору көне — 9нчы көн | 3.Бәйрәм көн: корбан чалу көне, 10нчы көн | 4.әл-карр көне: 11нче көн | 5. ән-нәфәр-нең беренче көне: 12нче көн | 6. ән-нәфәр-нең икенче көне: 13нче көн |
| Җыелу төне — бу бәйрәм алды төне, Гарәфә тавында торганнан соң кешеләр-нең җыелып торулары өчен шулай аталган, чөнки Мәккәдә яшәүчеләр җәһи-лият вакытында бу тауга чыкмыйлар иде. | | | | | |
| **Хаҗ вакытында Аллаһтан дога кылып сорау өчен биш урын:** | | | | | |
| 1.Гарәфә тавында 9нчы көннең зәвәленнән соң кояш баеганчы | 2.Мөздә-лифәдә 9нчы көнендә таң атканнан алып сары төс кер-гәнчегә кадәр. | 3.Тәшрикъ көннәрендә «әс-сугра» һәм «әл-вуста» җәмәрәт-ләренә таш атканнан соң | 4.Тәваф вакытында | 5.Сафа һәм Мәрва таулары арасында йөргән вакытта һәм аларда торган чакта. | |

| Шәригатьтә канунлаштырылган пәйгамбәр шәһәрендәге зиятартлар: | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1.Пәйгамбәр мәчетендә намаз уку өчен сәфәргә чыгарга ният кылу, чөнки хәдистә болай диелде: ***«Ошбу өч мәчеткә: әл-Харам, минем мәчетем һәм әл-Аксадан кала башка мәчетләргә сәфәр кылмагыз».*** Килешенгән хәдис. Ә икенче бер хәдистә: ***«Бу мәчеттәге намаз башка мәчетләрдәге мең намазга караганда яхшырак»,*** — диелде. Килешенгән хәдис. | 2. «Куба» мәчетендә намаз уку, чөнки хәдистә әйтелә: ***«Кем дә кем үз өендә госел коенса, ә соңыннан Куба мәчетенә килеп намаз укыса, кече хаҗ кылган кебек савап алыр».*** Ибн Мәджә | 3.Пәйгамбәребезнең һәм аның ике сәхәбәсенең каберләрен зиярат итү, чөнки сәхәбәләр шулай эшли иде. | 4. «Әл-Бакыгъ» зияратына бару, чөнки пәйгамбәребез шулай эшләде. | 5. Өхед сугышында һәлак булган шәһитләрнең каберләрен зиярат кылу, чөнки пәйгамбәребез шулай эшләде. |

## ХАҖ КИТАБЫ БУЕНЧА СОРАУЛАР

| Сораулар: | Дөрес | Дөрес түгел |
|---|---|---|
| — Ихрам — хаҗның бер әркәне, һәм ул микатта ак кием киюне аңлата.<br>— Фарыз тәваф — бу бару тәвафы түгел. Беренче тәваф — ул әркән, ә икенчесе — сөннәт.<br>— Пәйгамбәребез ﷺ өч тапкыр хаҗ кылды.<br>— Хаҗны булдыра алганчы тизрәк үтәргә кирәк.<br>— Мәдинәдә яшәүчеләр ихрамга Яләмләм җирлегендә керәләр.<br>— Кече хаҗны үтәү өчен вакыт микаты — ул Рамазан ае.<br>— Мәккә кешеләре әт-Тангим дигән җирдән хаҗ кыла башлыйлар.<br>— Ихрамга кергән вакытта хатын-кызга ак кием кияргә кирәк.<br>— Хатын-кызга хаҗ вакытында тегелгән кием киеп йөрергә рөхсәт ителми.<br>— Хаҗ кылучыга билбау киеп йөрергә рөхсәт ителми.<br>— Ике тау арасындагы йөгерүне тизрәк башкару хәерлерәк.<br>— Хаҗ кылучылар Гарәфә тавыннан кичке намаздан соң китәләр.<br>— Гарәфәдә тору — хаҗның фарыз гамәлләренең берсе.<br>— Шәригатьтә Гарәфә көнендә тауга менү канунлаштырылмаган.<br>— Корбан чалу тәмәттугъ һәм кыйран ысуллары белән хаҗ кылучыларга фарыз, ә ифрад ысулы белән хаҗ кылучыларга хәерле.<br>— Тальбияне бәйрәм көнендә әл-гакаба җәмәрәтенә таш ату белән төгәлләргә кирәк.<br>— Хаҗ кылучының аткан ташы җәмәраткә тимәсә дә, ату дөрес була. | | |

— Хаҗ кылучы 10нчы көндә өч җәмәраткә дә таш ата.

— Җәмәрәтләргә таш ату тәшрикъ көннәрендә зәвалдән соң башлана.

— Шәригать буенча таш атканнан соң Аллаһка дога кылу тиешле.

— Әгәр кеше гыйбадәтне туктатырга теләсә, хаҗ һәм гомрәдән кала гыйбадәтләр бозыла. Әгәр кеше тыелганны кылырга ниятләсә, аның гыйбадәте бары тик тыелганны кылганнан соң гына бозыла.

— Ифрад һәм кыйран хаҗлары бертөрле үк кылына, аерма бары тик шунда:

ифрад хаҗыннан аермалы буларак кыйран хаҗын үтәгәндә ике йоланы да бергә үтәү өчен корбан чалына.

— Әгәр бер нәрсәдә рөхсәт ителгән һәм тыелган бергә килсә, һәм аларны бер-берсеннән аерып булмаса, бу очракта тыелган ягы өскә чыга.

— Барлык зыян салучы әйберләр дә нигезле була алмый.

— Хатын-кызның ихрамы йөзенә киелә.

— Аллаһ һәм Аның рәсүле ﷺ канунлаштырган нәрсәләр генә фарыз була. Төпле дәлил булмыйча торып кагылгысызлыкка хокукы булганнарның милкенә кагылу тыелган. Әмма бу тәрбияләү һәм туры юлга күндерү сыйфатында, гомуми фәтвәләрдә күпчелек галимнәр тарафыннан кулланылган билгеләнгән чикләрдән узмыйча, рөхсәт ителә. Гыйлем алу мәсьәләсенә килгәндә, мәсәлән, теоретик гыйлемнәр, бу очракта хакыйкатьне ачыкларга кирәк.

— Дәлилләрсез нәрсәне дә булса рөхсәт итү дәлилләрсез тыю белән бер.

— Сөннәт ул Пәйгамбәр ﷺ заманында сәбәбе булган нәрсәләрне һәм ул кылмаган гамәлләрне кире кагу.

— Әгәр фарыз гамәл төшеп калса һәм аны каза кылырга мөмкинчелек булмаса, бу очракта корбан чалырга кирәк, кайбер гыйлемсез кешеләр үзләренең сайлау хокуклары бар, дип уйлыйлар.

— Хаҗның әркәннәрен санагыз: 2___, 3___, 4___.

— Уң як җилкәне ачарга кирәк: кече хаҗ вакытындагы тәвафта_____, сәламләү тәвафында____, зиярат кылу тәвафында_____, беренчесен һәм икенчесен башкарган вакытта гына____, барысында да___.

— Пәйгамбәр ﷺ Гарәфә көнендә кичке һәм төнге намазларны кайда укыган? Гарәфә тавында_____, Минада____, Мөздәлифәдә___, юлда___.

— Хаҗ бурычы йөкләнгән: 9нчы елда_____, 10нчы елда____.

— Ихрамда тыелган гамәлләр: 9____, 5____, 3____.

— Ихрамга керүче кешегә ислемайлар сөртү тиешле _______, әмма ____моны эшләү тиеш түгел.

— Хаҗ кылучы хатын-кыз _____һәм____ кимәскә тиеш.

— Хаҗ һәм гомрә гомергә бер тапкыр______; кем хаҗ кылды, һәм______ һәм______, ул анадан туган көндәге кебек гөнаһлардан чиста булыр.

— Кабул кылынган хаҗның савабы бары тик_______.

— Кем ураза тотарга тиеш?

1.____________________________________ 2. ______________________________________________

3.____________________________________ 4. ______________________________________________

Һәм хатын-кыз өчен өстәмә шарт:

5.____________________________________________________________

— Ике тау арасында йөрүне _______ башларга һәм__________тәмамларга кирәк.

— Хаҗны__________ көнендә кыла башларга һәм _____________көнендә тәмамларга кирәк.

— Әгәр фарыз тәвафны Мәккәдән чыгып киткәнчегә кадәр калдырсаң, саубуллашу тәвафы сыйфатында ул җитә. Фарыз тәвафы кече хаҗ вакытындагы кебек кылына, бары тик аерма шунда гына: ____________________ һәм ________________.

— Кыйран һәм ифрад хаҗларын үтәүче кешеләр ике тау арасын йөрүне_______________тиешләр, әмма тәмәтту’хаҗын үтәүче бу йөрүне ________________үти.

— Хаҗ һәм гомрә кылганда иң мөһим тәүхид билгеләренә ________керә.

— Түбәндә санап үтелгәннәрнең шәригать хөкемнәрен санагыз:

А. Сабый баланың хаҗы.

Б. Мәхрәме булмаган хатын-кызның хаҗы.

В. Өстендә бурычы булган кешенең хаҗы.

**Зөл-хиҗҗә аеның көннәрен түбәндә китерелгән җавапларның дөрес вариантлары белән тоташтыр:**

| 8нче көн | 9нчы көн | 10нчы көн | 11нче көн | 12нче көн | 13нче көн |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| Гарәфә көне | Ән-Нәфәрнең беренче көне | Минага су алып килгән көн | Корбан чалу көне | Ән-Нәфәрнең икенче көне | әл-Карр көне |

# СӘҮДӘ КИТАБЫ

# СӘҮДӘ КИТАБЫ

Сәүдәнең шәригатьтәге мәгънәсе — ул, рибадан тыш, «нәрсәнедер алу» һәм «нәрсәнедер бирү», хәтта әгәр ул бурыч рәвешендә булса да, яки рөхсәт ителгән даими узуфрукт, мәсәлән, өйдән керү-чыгу юлы

## Сәүдәнең эркәннәре һәм шартлары

<table>
<tr><td colspan="3">Сәүдә килешүе төрләре:</td></tr>
<tr><td>1.Алыштыру:<br>Сату-алу, аренда килешүе</td><td>2. Мәгълүматның дөреслеген раслау өчен ышанычлы өченче кешедә теркәү:<br>Залог, гарантия</td><td>2. Мәгълүматның дөреслеген раслау өчен ышанычлы өченче кешедә теркәү:<br>Залог, гарантия</td></tr>
</table>

<table>
<tr><th colspan="4">Сәүдә килешүенең эркәннәре:</th></tr>
<tr><td rowspan="2">1.Килешүче яклар: сатучы һәм сатып алучы</td><td rowspan="2">2.Килешүнең предметы:<br>товар</td><td colspan="2">3.Формулировка</td></tr>
<tr><td>А.Телдән: тәкъдим һәм кабул итү</td><td>Б.Гамәлгә нигезләнгән: алыш-биреш</td></tr>
<tr><td colspan="4">Нигездә сәүдә килешүе рөхсәт ителгән. Аллаһ Тәгалә әйтте: «Аллаһ сәүдәне рөхсәт итте һәм ришвәтчелекне тыйды».<br><br>Теләсә-нинди товар: билгеле бер шартлар үтәлгәндә күчемсез милек, мал-туар, мебель һәм башкаларны сатканда сәүдә килешүе төзү тиешле.</td></tr>
<tr><td colspan="4">Сәүдәнең шартлары өч төрле нәрсәдән килеп чыга: законсызлык, ришвәтчелек һәм мошенниклык.<br><br>Шәхси милек булмаган товарны сату — законсызлык; риба — ул ришвәт, билгеле булмаган әйберне сату — ул мошенниклык.</td></tr>
</table>

## СӘҮДӘ ШАРТЛАРЫ

| Сәүдә шартлары: | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1.Килешүче якларның риза булуы | 2.Сәүдә килешүе предметы турында белү (товар һәм аның бәясе турында) | 3.Сатучы һәм сатып-алучы милеккә ия булырга яки милек белән файдалануга рөхсәте булу. | 4.Рибачылыкның булмавы | 5.Товар яки акча харам, тыелган булырга тиеш түгел |

| Тыелган килешүләрнең кайбер төрләре: | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 1.Җомга намазы фарыз булучылар өчен җомга намазына икенче тапкыр чакырганнан соң сату-алу. | 2. Товарларны Аллаһның әмерләрен бозу һәм Шәригатьтә тыелган максатларда куллану өчен сатып алган кешегә сату. | 3.Мөселман кардәшенең сәүдәсен кулга төшерү. | 4.Рассрочкага товар сату һәм аны акчага азрак бәягә кире сатып алу. | 5.Кешеләргә ия булган товарны өченче кешегә сату. | 6.Куллаңышка яраклымы, юкмы икәнлеге ачыкланганчыга кадәр өлгермәгән җиләк-җимешләрне сату. |

Иң мөһим шартларның кайберләре:

**[Беренче шарт:]**

Ике якның да ризалыгы, чөнки Аллаһ Тәгалә әйтте: **«...әгәр сәүдә ике якның да ризалыгы белән булмаса гына».**

| **[Икенче шарт:]** | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Сәүдә килешүенең предметы турында белү, чөнки Пәйгамбәр ﷺ: ***«...билгеле булмаганны сатудан тыйды».*** Мөслим. Монда шулай ук керә: | | | | |
| 1.Качып киткән колны яки малны сату | 2. Ошбу сүзләр: *«Мин сиңа ике товарның берсен саттым».* | 3.Таш кайда төшсә, шул өлешен сату һәм башкалар. | 4. Кол кулында булган нәрсәләрне яки әле агачында үсеп өлгермәгән җиләк-җимешләрне сату. | 5.Яки малның карынында булган яралгыны сату. |
| Билгесезлек бәясендә дә, товарда да булырга тиеш түгел. | | | | |

**[Өченче шарт:]**

Килешүче яклар милеккә хокуклы яки милектән кулланырга рөхсәте булган һәм бәләгать яшенә ирешкән һәм [гакыллы] булырга тиеш.

**[Дүртенче шарт:]**

Рибачылык булырга тиеш түгел.

| **Рибачылык төрләре** | |
|---|---|
| 1. «Риба әл-фәдл» — аерманы арттыру: бер төрдәге аерым товарлар алмашу вакытында өстәмә акча, бу да рибачылыкка керә. | 2. «Риба ән-нәсиә» — Кичектерелгән түләүне арттыру: товар алуны кичектерү, бу да рибачылык була. |
| Убәдә, Аллаһ аннан риза булсын, сүзләреннән китерелә, Аллаһның илчесе ﷺ әйтте: ***«Алтынны алтынга, көмешне көмешкә, бодайны бодайга, арпаны арпага, тозны тозга бертигез күләмдә һәм кулдан кулга алыштырыгыз. Кем арттырды яки арттыруны таләп итте, ул рибачы булды».*** Мөслим. | |

| Рибачылык әйберләре алтау: | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 1.Алтын | 2.Көмеш | 3.Бодай | 4.Арпа | 5.Финиклар | 6.Тоз |
| 1.Сагъ белән яки үлчәүдә үлчәнә торган бер төрдәге азык-төлекне бу ике шартсыз сатарга ярамый. | | 2.Әгәр сагъ белән яки үлчәүдә үлчәнә торган төрле төрдәге азык-төлек сатылса, килешүне төзүче кешеләр таралышканчы товарны кулдан-кулга бирү шарты белән рөхсәт ителә. | | 3.Әгәр сагъ белән билгеләнә торган азык-төлек үлчәүдә үлчәнә торган азык-төлеккә (яки киресенчә) алыштырылса, бу рөхсәт ителә, хәтта товарны килешү төзүче яклар таралышканнан соң кулдан-кулга бирелсә дә. | |

Охшашлык турында белмәү аермалык турында белү белән тәңгәл [ягъни саннарның тигезлеген белмәү бер товарның икенчесеннән саны белән аерылып торуын белү белән тәңгәл килә]. Пәйгамбәр ﷺ «әл-музабәнә»не: ***«...җыелмаган финикларны корыларына алыштыру»***ны тыйды. Килешенгән хәдис. ***«...Шуннан соң ул мохтаҗларга җыелмаган финикларны коры финиклар бәрабәренә сатарга рөхсәт бирде, ләкин шарты мондый иде: финиклар биш васктан ким булырга һәм уңышны җыйганнан соң алардан күпме кипкән финик чыгасы чамаланырга тиеш».*** Мөслим.

| Җыелмаган финикларны кипкән финикларга алыштырып сату рөхсәт ителсен өчен шартлар: | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1.Сатып алу өчен кипкән финиклардан тыш башка продуктларның булмавы. | 2. 5 васк һәм аннан да кимрәк итеп сатып алу. | 3.Финиклар коры финиклар сатып алынган бәягә сатылырга тиеш. | 4.Сатып алучы кеше ризыкка куллану өчен җыелмаган финикларда мохтаҗлык кичерергә һәм аларның өлгерүен көтеп торырга теләмәскә тиеш. | 5. Финиклар җыелмаган булырга тиеш (агачында калырга тиеш). |

| **[Бишенче шарт:]** Сәүдә килешүе төзегән вакытта товар Шәригать тарафыннан тыелган булырга тиеш түгел: | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. «**Пәйгамбәр** ﷺ **шәраб, *үлгән мал итен, дуңгыз итен һәм потларны сатарга тыйды*»**. Килешенгән хәдис. | 2.Сәүдә килешүенең нәтиҗәсе мөселманнарга зыян салса. Пәйгамбәр ﷺ «... ***мөселман кардәшеңнең сәүдәсен тартып алырга»*** тыйды. Мәсәлән, кардәшеңдә 10 мең торган телефонны арзанракка «сату»: *«Әйдә, кил, мин сиңа 9га бирәм».* ***«яки сатып алганда»,*** күбрәк акча тәкъдим итү: *«Мин моны синнән 10га алам»,* ***«һәм бәяләрне ник күтәрмәгез»***: [ягъни сатып алырга җыенмыйча, товарның бәясен күтәрү һәм шул сәбәпле сатучыга һәм сатып алучыга яки икесенә дә зыян китерергә теләү]. Килешенгән хәдис. | 3.Пәйгамбәребез ﷺ: ***«...бер-бер сенә тугән булган колларны аеру»***ны тыйды. Тирмизи һәм Ибн Мәджә | 4.***«Әгәр сатып алучы кеше сатып алынган товарны Аллаһның сүзеннән чыгу өчен куллануы билгеле булса»*** — мәсәлән, комарлы уен предметлары сатып ала; яки фетнәле заманда һәм юлбасарларга корал сату. | 5.Пәйгамбәр ﷺ тыйды: ***«Кәрваннарны шәһәр читендә каршы алмагыз. Әгәр товар хуҗасын шәһәр читендә каршы алып, ул үз товарының бер өлешен саткан булса, базарга килгәннән соң бу сәүдә килешүен өзәргә аның хокукы бар».*** Мөслим | 6.Ул әйтте: ***«Кем ялганлый, ул бездән түгел».*** Мөслим |

| Ачык рибага мисаллар: | | | |
|---|---|---|---|
| 1.Товар белән хәйлә кору: мәсәлән, нәрсәне дә булса 100 сум әҗәткә сатып, соңыннан бу әйберне арзанракка акчага сатып алу. | 2.Яки әҗәт белән хәйлә кору | 3.Әҗәтне артыгы белән кире кайтару өчен хәйлә кору: әгәр кеше әҗәткә биргәндә алмашка бирәр әйбер яки әйберне кулланып торуны сораса.<br><br>Табыш китерүне күздә тотып әҗәткә бирү риба була. | 4. Башка кыйммәтле металлар катнашкан көмеш бизәнү әйберсен чиста көмешкә сату да шулай ук хәйлә булып тора. |

Пәйгамбәрдән ﷺ коры финикларны яңа гына өлгергән финикларга сату хакында сорадылар, ул әйтте: «Кипкәч, финик күләмен һәм авырлыгын югалтамы?» Аңа: «Әйе»,— диделәр. Һәм шуннан соң ул аны тыйды». Хәдисне 5 шәех китерде. [чөнки яңа өлгергән финиклар коры финикларга караганда авыррак. Искәрмә: югарыда телгә алынган шартларны үтәгәндә генә рөхсәт ителә].

***«Пәйгамбәр ﷺ авырлыгы билгеле булмаган финикларны авырлыгы билгеле булган финикларга алыштырып сатуны тыйды».*** Мөслим.

Бурыч язмазы рәвешендә булган әйберне сатуга килгәндә:

| | |
|---|---|
| 1.Әгәр бу әйбер сатучыныкы булса, аның өчен түләнгән акчаны, килешенгән яклар аерылышып киткәнче, кулга бирү шарты белән рөхсәт ителә, чөнки Пәйгамбәр ﷺ әйтте: ***«Түләү тәмам булганчы бер-берегездән аерылмау шарты үтәлгәндә акчаларны бүгенге курс белән алыштыруда начарлык юк».*** Хәдисне 5 шәех китерде. | 2.Әгәр килешүне товар хуҗасы төземәсә, ул дөрес булмый, чөнки «гарар» (билгеле булмаган) була. |

## ЧЫГАНАКЛАРНЫ ҺӘМ ҖИМЕШЛӘРНЕ САТУ

Биредә, мәсәлән, пальма агачы чыганак, ә финиклар җимеш булып тора.

<table>
<tr><td colspan="2">[Чыганакларны сату]:<br><br>Пәйгамбәр ﷺ әйтте: «Кем тарафыннандыр серкәләнгәннән соң сатып алынга нпальманың финиклары, әгәр сатып алучы тарафыннан [уңышы миңа була дигән] шартлар куелмаган булса, сатучыныкы була». Килешенгән хәдис.</td></tr>
<tr><td colspan="2">Әлеге хәдис җир участогын түгел, ә пальмалар саткан кешегә кагыла.<br><br>Пальмалар серкәләнгәч сатылган очракта:</td></tr>
<tr><td>Финиклары сатучы кешенеке була</td><td>Әгәр сатып алучы уңышы минеке була, дигән шарт куймаса, ә бу шартны куйсаң, яхшырак.</td></tr>
<tr><td colspan="2">Бу җимеш китерә торган башка агачларга да кагыла: алмагач, йөзем һәм башкалар, чөнки алар серкәләнгән пальмалар кебек үк.<br><br>Бу шулай укуңышы елга бер генә җыела торган уҗымнарга да кагыла.<br><br>Әгәр уҗымнардан уңыш күп тапкыр җыеп алынса, чыганаклары сатып алучыныкы була, ә килешү вакытында күренгән уҗымнары сатучыныкы була.</td></tr>
</table>

**[Җимешләрне сату]:**

***«Аллаһның илчесе ﷺ өлгермәгән җиләк-җимешләрне сатудан тыйды».***

*Аннан җиләк-җимешләрнең кайчан өлгергән булуы турында сорадылар, һәм ул әйтте:* ***«Аларга бозылу куркынычы янамаганда».***

Ә икенче хәдистә: ***«Алар кызыл яки сары төскә кергәч»*** (тәме тәмле булгач),— диелә.

Шулай ук ул: ***«...ныгыганчыга кадәр бөртеклеләрне сатудан тыйды»***. «Сунан» авторлары китерде.

Әгәр бөртеклеләр мал-туарга ашату өчен сатылса, аларның ныгуы шарт булып тормый.

Ул әйтте: ***«Әгәр син кардәшеңә җиләк-җимешләр сатсаң, шуннан соң аларны ниндидер бәла-каза юкка чыгарса, синең аннан ни булса да алырга хокукың юк. Ни өчен син кардәшеңнең милкен гаделсезлек белән үзеңнеке итәргә тиеш?»*** Мөслим.

Ягъни сатучы сатып алучыга акчаларын кире кайтара.

Әгәр сатып алучының ваемсызлыгы нәтиҗәсендә җимешләргә зыян килсә, бу очракта сатучы акчаларны үзендә калдыра ала һәм бу гамәлдә гөнаһ булмый.

| **Әгәр ошбу нәрсәләр үскән җир участогы сатылса:** | | |
|---|---|---|
| 1.Агачлар: алар җир участогы белән бергә сатып алучыга күчә. | 2.Әгәр уҗымнардан уңыш күп тапкыр җыеп алынса, чыганаклары сатып алучыныкы була, ә килешү вакытында күренгән уҗымнары сатучыныкы була. Әмма әгәр сатып алучы күренгән уҗымнар минеке була дигән шарт куя икән, бу рөхсәт ителә. | 3.Уңышы елга бер тапкыр гына җыела торган уҗымнар: бодай, арпа һәм башкалар уңышны җыеп алганчы сатучыныкы булалар. |

## СӘҮДӘ КИЛЕШҮЕН ИХТЫЯРИ РӘВЕШТӘ БОЗУ

| |
|---|
| Сатучының да, сатып алучының да килешүне төзергә дә, бозарга да хокуклары бар. |
| Әгәр килешү төзелгән икән, моңа шәригать сәбәпләре комачау итмәсә, аны үтәү мәҗбүри. |

| **Мәҗбүри булган килешү төрләре һәм аларның хөкемнәре:** | | |
|---|---|---|
| 1.Ике якка да рөхсәт ителгән килешү: вәкаләтләрне тапшыру (викалә) | 2.Ике якка да үтәү мәҗбүри булган килешү: сату-алу, аренда. | 3.Бер якка үтәү мәҗбүри, икенче якка үтәү рөхсәт ителгән килешү: залог. |

| **Килешүне өзү хокукының сигез төре:** | | | |
|---|---|---|---|
| 1.Хияр әл-мәдҗлис: килешү төзелгән урында аны өзү хокукы. | 2.Хияр әш-шарт: билгеле бер шартлар булганда килешүне өзү хокукы. | 3.Хияр әл-габан: ялган сәбәпле. | 4.Хияр әт-тадлис: мошенниклык факты ачыкланса. |
| 5.Хияр әл-гайб: товарның кимчелеге булу сәбәпле. | 6.Бәяләрнең төрле булу сәбәпле, әгәр элек килешенгәннән кыйммәт яки арзан булса. | 7.Сатучы һәм сатып алучы арасында килеп чыккан фикер каршылыклары сәбәпле. | 8.Тасвирлама белән товар арасындагы аерма сәбәпле. |

### [Беренче төр:]

Килешү төзелгән урында аны өзү хокукы. Пәйгамбәр ﷺ әйтте: ***«Әгәр ике кеше сәүдә килешүе төзесәләр, аларның икесенең дә, аерылышып киткәнче бергә булган вакытта яки аларның берсе икенчесенә сайлап алу мөмкинлеге биргәндә, бу килешүне өзәргә хокуклары бар. Әгәр аларның берсе икенчесенә шартлар тәкъдим итсә, һәм ул әлеге шартларга риза булса, һәм шуннан соң килешүгә килсәләр, килешү төзелгән, дип санала».*** Килешенгән хәдис.

| Икалә: |
|---|
| Пәйгамбәр ﷺ әйтте: ***«Әгәр кем дә булса мөселманның килешүне өзәргә дигән теләгеп кабул итсә, Аллаһ Кыямәт көнендә аның гөнаһларын ярлыкар».*** Әбу Давыд һәм Ибн Мәджә. |

## АВАНС

| Авансны теләсә-нинди товар өчен түләргә мөмкин, әгәр аны тасвирлап булса: | | |
|---|---|---|
| 1.Сатучы товарның бәясенә бәйле булган барлык сыйфатларын да тасвирлый (размеры, төре, тибыһәм сыйфаты). | 2.Вакытын телгә ала | 3.Һәм сатып алучы товарның бөтен бәясен аерылышканчы түли. |
| Ибн Габбас, Аллаһ аларның икесеннән дә риза булсын, сүзләренннән китерелә: ***«Пәйгамбәр ﷺ Мәдинәгә килгәч, аның халкы җиләк-җимешләр өчен бәяне бер, хәтта ике ел алдан ук та түләп куялар иде. Ул әйтте: «Кем җиләк-җимеш өчен аванс түли икән, ул акчаны билгеле бер үлчәү яки авырлык өчен, билгеләнгән вакытка түләсен».*** Килешенгән хәдис.<br><br>Ул шулай ук әйтте: ***«Әгәр кеше чит кешенең милкен кире кайтарып бирү нияте белән ала икән, Аллаһ аның өчен түләячәк. Әгәр ул чит кешенең милкен аны бетерү нияте белән ала икән, Аллаһ аның үзен һәлак итәр».*** Бохари. | | |
| Авансқа мисал: ашлык үстерүче кеше сәүдәгәр янына килеп, болай ди: *«Миңа 1000 риал акча бир, ә мин сиңа ел ахырында 100 сагъ бодай бирермен».* Шулай итеп ашлык үстерүче кеше акчадан, ә сәүдәгәр бодайдан файда ала. | | |

## [РАСЛАНГАН КИЛЕШҮЛӘР]: ЗАЛОГ, ГАРАНТИЯ, ЫШАНЫЧ ЯЗУЫ

Әлеге документлар законлы хокукларны яклый.

<table>
<tr><td colspan="3">[Залог]<br><br>Бу милекне закладка салу юлы белән бурыч акчасын кайтару, ул әҗәтнең бер өлешен яки тулаемын каплый ала.<br><br>Үзе эченә түбәндәгеләрне ала:</td></tr>
<tr><td>1.Залог бирүчене, ул бурычны кайтару өчен залогны бирә.</td><td>2.Залогны алучы –кредитор.</td><td>3.Бурычны кайтару өчен бирелгән залогның предметы.</td></tr>
<tr><td colspan="3">Сатарга мөмкин булган теләсә-нинди милек залог сыйфатында кулланыла ала. [Сатарга ярамый торган әйберне залог сыйфатында калдырырга ярамый: вакыф[1] милек, эт, яки кеше ия булмаган нәрсәләр]. Залогка салынган милек кредиторда саклана һәм, әгәр ваемсызлык күрсәтмәсә, салынган башка зыян өчен акча түләргә тиеш түгел.</td></tr>
</table>

Әгәр:

<table>
<tr><td rowspan="2">1.Бурыч тулысынча түләнсә, залог кире хуҗасына кайтарыла.</td><td colspan="3">2.Әгәр бурыч түләнмәсә һәм кредитор залогка салынган милекне сатуны таләп итсә:</td></tr>
<tr><td>Аны сату мәҗбүри һәм бурыч шуны саткан акчалардан түләнә.</td><td>Бурычны түләүдән калган акчалар кире залог бирүчегә кайтарыла.</td><td>Әгәр бурычның бер өлеше түләнмичә калса, ул залогсыз да саклана.</td></tr>
</table>

Әгәр ике якның берсе залог предметын бозса, ул аны түләргә һәм залог сыйфатында бирергә тиеш.

1Мәчеткә бирелгән милек

Әгәр залогның предметы сан ягыннан артса, бу артым өлеше дә залог сыйфатында кала.

Залогтагы милекне карап, тәрбияләп тору (әгәр ул тере икән) залог бирүченең өстендә һәм кредиторның, залог бирүченең яки закон чыгаручының рөхсәтеннән башка, аны кулланырга хокукы юк. Пәйгамбәр ﷺ әйтте: «***Әгәр атланып йөри торган мал залогка бирелгән булса, аңа, ул синең карамакта булганда, атланып йөрү рөхсәт ителми, ә сөт бирүче мал залогка бирелсә, ул синең карамагыңда булганда, аның сөтен кулланырга рөхсәт ителә. Кем атланып йөри һәм сөтен эчә, шул әлеге малны карап тору өчен акчасын түли***». Бохари.

Кредиторның, бернинди халәттә дә, залогка салынган мал белән кулланырга хокукы юк, ләкин мал-туар искәрмә булып тора. Аның йортта яшәргә яки машинада йөрергә, әгәр ул аларны арендаламаса, хокукы юк. Мал-туарга килгәндә исә, әгәр аларны кредитор тәрбияләп, карап торса, ул аларны куллана ала, бу хакта алда бирелгән хәдистә әйтелә.

| Залогка мисал: кеше сыерны залогка салды, ә кредитор аны сава. Без кредиторга болай дибез: *«Син аны карап, тәрбияләп торганда гына куллана аласың»:* | | |
|---|---|---|
| 1.Әгәр аның сөтенең бәясе бер атнага 100 сум булса һәм аны карап тору өчен атнасына 100 сум кирәк булса, бу очракта аның сөте кредиторныкы була. | 2.Әгәр сөтнең бәясе атнага 200 сум булып, малны карап тору 100 сумга гына төшсә, калган 100 сум акчаны кредитор залог биреп торучыга кайтарырга тиеш, әмма залог сыйфатында да калдыра ала, чөнки бу акчалар «залог предметының артуы» булып санала. | 3.Киресенчә булганда: карап торырга 200 сум кирәк булып, сөтнең бәясе 100 сум гына булса, бу очракта залог бирүче кредиторга килгән зыянны капларга тиеш. |

**[Ышаныч, гарантия]**

Бу икенче затның хокукларын саклау һәм бурычларның үтәлешен тәэмин итүышанычы, гарантия булып тора.

**[Ышаныч язуы:]**

Кем генә поручитель булып килсә дә, ышаныч язуы дөрес санала, ул үз өстенә кешенең бурычын ала.Пәйгамбәр ﷺ әйтте: ***«Поручитель булган кеше үз өстенә чит кешенең бурычын ала».*** [Тирмизи һәм Ибн Мәджә].

Гарант һәм поручитель булган кеше зыянны компенсацияләргә тиеш, әгәр:

| | | |
|---|---|---|
| 1.Өстенә алынган бурыч үтәлмәсә генә. | 2.Әҗәткә бирүче бурычлыны гафу итмәсә. | 3.Гарантия предметы бозылмаса. Ә Аллаһ бу хакта яхшырак белә. |

## БАНКРОТЛЫК ЯКИ БАШКА СӘБӘПЛӘР АРКАСЫНДА МИЛЕККӘ АРЕСТ САЛУ

| |
|---|
| Арест — кешенең үз милке белән ирекле куллана алу хокукыннан мәхрүм итү. |

| **Арестның 2 төре бар:** | |
|---|---|
| 1.Арест салынган кешенең мәнфәгатендә: кечкенә сабый бала, гакылсыз яки юләрләнгән кеше | 2.Банкротлык турында сүз барганда, өченче затлар мәнфәгатендә. |

Хокуклары булган кешегә бурычлы кешегә бурычын түләүне кичектереп торырга һәм материаль кыенлыклар кичергән кешенең хәлен җиңеләйтергә кирәк.

Бурычлы кешеләр үзләренең бурычларын тулаем түләргә тиешләр.

Пәйгамбәр ﷺ әйтте: «***Бай кеше тарафыннан бурычны түләүне сузу — гаделсезлек! Әгәр сезнең арагыздан кемгә дә булса бурычны баерак кешегә күчерергә тәкъдим ясасалар, ризалык бирсен***». Килешенгән хәдис.

Бу җиңеллек.

Бай кеше — ул бурычны түләргә мөмкинчелеге булган кеше һәм бурычны түләүне сузмыйча гына акчаларны туры судка китерә ала.

Әгәр кешенең бурычлары аның материаль халәтеннән күбрәк икән һәм кредиторлар судьядан аның милкенә арест салуны сорасалар, бу таләп үтәлә, бурычлы кешегә бу милектән нәрсә белән булса да куллану тыела, шуннан соң аның байлыгы бәяләнә һәм бурычларына карап, кредиторлар арасында бүленә.

Кредиторлар арасында өстенлек шушыларга бирелә:

| | |
|---|---|
| 1.Залог алучыга, аңа залог предметы калдырыла | 2.Һәм Пәйгамбәребез ﷺ әйткәнчә: ***«Әгәр кеше үзенең милкен банкротлыкка чыккан бурычлыда тапса, аның бу милеккә башкаларныкына караганда хокуклары күбрәк».*** Килешенгән хәдис. |

Баланы, гакылсызны, акылдан язган кешене тәрбиягә (опекага) алган кеше тиеш:

<table>
<tr><td rowspan="2">1. Әгәр үз милекләре белән иркен файдалану зыян китерсә, моннан тыярга. Аллаһ Тәгалә әйтте: «Аллаһ Тәгалә сезгә яшәү чарасы итеп биргән милкегезне гакылсыз кешеләргә бирмәгез».</td><td colspan="3">2.Аларның милекләренә, яхшы нияттән тыш, якын да килмәскә:</td></tr>
<tr><td>А. Аны саклау өчен.</td><td>Б.Милекне аларның интересларында гына куллану өчен.</td><td>В. Аларның ихтыяҗлары өчен генә тоту өчен.</td></tr>
</table>

Аларның опекуннары булып торалар:

<table>
<tr><td>1.Акыллы ата</td><td>2.Әгәр ул булмаса, судья тарафыннан рәхимлерәк булган, аларны белгән һәм куркынычсызлыкларын тәэмин иткән якын туганнары поручитель итеп билгеләнә</td></tr>
<tr><td colspan="2">Кем бай, ул тыелып торсын,<br>Ә кем фәкыйрь, ул гаделлек белән ризыклансын, ягъни үзенә минималь түләү яки үзенә җитәрлек кенә алсын.</td></tr>
<tr><td colspan="2">Әйтик, кешегә яшәү өчен 1000 риал кирәк, ә аның түләве 500 риал гына: без аңа 500 риал бирәбез, чөнки бу минималь сумма, ә Аллаһ бу хакта яхшырак белә.</td></tr>
</table>

## ЯКЛАРНЫҢ КИЛЕШҮЕ

Якларның килешүе — ул конфликтка кергән якларның килешенүе буенча бу эшне тикшерүне туктату килешүе. Аның төрләре күп һәм бу милек хокуклары белән (һәм аның белән генә түгел) бәйле.

Якларның килешүе тик бер очракта гына — судья конфликтка кергән якларның берсе хак булуын аңлаган очракта тыела.

Пәйгамбәр ﷺ әйтте: ***«Мөселманнар ике якның үзара килешүе нәтиҗәсендә конфликтны хәл итәргә хокуклы, әгәр рөхсәт ителгәнне тыймасалар һәм тыелганны рөхсәт итмәсәләр».*** Хәдисне Әбу Давыд һәм Тирмизи китерә. Тирмизи аны яхшы һәм дөрес хәдис, ә Хәким дөрес хәдис, дип атаган.

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1.Бер әйбер урынына икенчесен бирү яки бурыч урынына нәрсә дә булса бирү юлы белән килешү рөхсәт ителә. | 2.Килешү булган миз-гелдә үк кон-фликтка кер-гән яклар, таралыш-канчы, нинди дә булса милекне яки бурычның үзен бирү юлы белән килешү: рөхсәт ителә. | 3.Кучемсез милекнең узуфруктын (әйбернең бөтенлеген һәм куллану максатын саклап кул-лану) яки башка кон-крет әйберне биреп килешү. | 4.Килешү булган миз-гелдә үк бурычның бер өлешен түләү шарты белән калган өле-шен гафу итү юлы белән килешү. | 5.Бер як та бурычның никадәр булуын бел-мәгән очракта кредиторга нәрсә дә булса бирү аша килешү: дөрес була. |

Пәйгамбәр ﷺ әйтте: ***«Кеше үзенең күршесенә стенага бүрәнә куярга комачау итәргә тиеш түгел».*** Бохари.

## ВӘКАЛӘТЛӘҮ, ПАРТНЕРЛЫК һӘМ ИЗДОЛЬЩИНА

**Вәкаләтләү** — ирекле рәвештә милек белән кулланырга хокукы булган кешенең икенче бер кешегә эш кушуы, әлеге эш өченче зат тарафыннан башкарыла ала.

**Партнерлык** — ике яки аннан да артыграк кешенең хокукларда һәм милек белән эш итүдә берләшүе.

**«Мусака» һәм «Музарага»** (издольщина) — ике кеше арасында уңыштан билгеле бер табыш алу максаты белән төзелә торган килешү, әлеге килешү вакытында ике якның берсе икенчесенә (беренче очракта) карап тору өчен агач һәм ясалма сугару җайланмасы яки (икенче очракта) эшкәртү өчен җир участогы биреп тора.

<table>
<tr><td colspan="3">[Бүлек: вәкаләтләү]<br>Пәйгамбәр ﷺ сәхәбәләренә шәхси хаҗәтләрен дә, барлык мөселманнарның хаҗәтләрен дә үтәүне куша иде. Бу ике як өчен дә рөхсәт ителгән килешү [вәкаләтләрне йөкләүчегә дә, вәкаләтләр йөкләнгән кешегә дә].</td></tr>
<tr><td colspan="2">1.Вәкаләтләүгә кергән һәртөрле гамәлгә дә кагыла:</td><td rowspan="2">2.Кеше шәхсән үзе үтәргә тиеш булган гамәлләрне: намаз, тәһарәт, ант, хатыннар өчен төннәрне бүлү һәм башкаларны вәкаләтләү һич тә ярамый торган эш.</td></tr>
<tr><td>А.Аллаһ хокукларына да: зәкәт тарату, гөнаһлар өчен түләү һәм башкалар.</td><td>Б.Кеше хокукларына да: килешүләрне төзү һәм өзү һәм башкалар</td></tr>
</table>

| |
|---|
| Вәкаләтләр йөкләнгән кеше аңа рөхсәт ителмәгән нәрсәләр белән ирекле файдалана алмый: сүз яки гамәл белән.<br><br>Билгеле бер түләү, бүләкләү хисабына башка кешегә вәкаләтләрне йөкләү рөхсәт ителә.<br><br>Вәкаләтле вәкил булган кеше башка шундый затлар кебек үк, ваемсызлык һәм илтифатсызлык күрсәткән очракларда гына килгән зыянны түли. Аның (ваемсызлыгы юклыгы хакындагы) сүзләре ант иткәннән соң кабул ителә, әгәр хокукларның хуҗасы ышанычлы кешегә дәгъва белдерсә һәм милекне кайтарып бирүен таләп итсә, бу очракта: |

| | |
|---|---|
| 1.Әгәр аның өчен түләү вәгъдә ителгән булса, вәкаләтле вәкилнең сүзләре ачык дәлилләр булганда кабул ителә. | 2.Әгәр ул бушка булса, аның сүзләре анттан соң кабул ителә. |

**[Бүлек: партнерлык]**

Пәйгамбәр ﷺ әйтте: ***«Аллаһ Тәгалә әйтте: «Әгәр ике кеше партнерлар булсалар, аларның берсе икенчесен алдалаганчыга кадәр, Мин — өченчемен. Әгәр аларның икесенең берсе шулай эшләсә, Мин аларны калдырам».*** Әбу Давыд. Партнерлык, үзенең бөтен чагылышларында да, рөхсәт ителгән.

Партнерлык вакытында милек һәм табыш ике якның фактик табыш өлешенә кагылышлы килешүе нигезендә бүленә [табыш тигез итеп икегә бүленә].

Монда керәләр:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1.Өлешкә керү турындагы килешү (әл-гинан): һәр як үзенең өлешен кертә һәм билгеле бер эшне башкара. | 2.Капитал белән ышанычлы идарә итү килешүе (әл-мудараба): берәү акча кертә, икенчесе эшне эшли. | 3.Ышанычка нигезләнгән партнерлык килешүе (әл-вуджух): үзләренең абруйлы булулары нәтиҗәсендә кешеләрдән взнос акчалары алалар. | 4.Коммерцияле эшчәнлек, бу вакытта партнерлар физик эш эшлиләр (әл-абдан): рөхсәт ителгән эшне башкаралар, мәсәлән, печән чабу яки башка үзләре риза булган эш | 5.Бөтен төр мөнәсәбәтләрдә дә яклар тигез булган теләсә-кайсы партнерлык (әл-муфавада): үзенә әле генә санап үтелгән пунктларны үз эченә ала. |

Әле санап үтелгән барлык төр партнерлыклар да рөхсәт ителгән.

Әгәр ике якның берсе золымлык кичерсә яки билгесезлектә (гарар) булса, бу очракта килешү өзелә, әйтик, бер як табышны билгеле бер вакыт аралыгында ала, икенче як исә икенче вакыт аралыгында яисә бер як билгеле бер товардан табыш алса, икенче як икенче бер товардан табыш ала һәм башкалар.

**[Бүлек: издольщина]**

Шул ук нәрсә издольщина килешүен дә боза: өлешнең билгеле булмавы. [Мәсәлән, мондый сүзләр: *«Мин синең бу агачыңны аның җимешләренең бер өлеше яки 100 кг җимеш бәрабәренә карап, тәрбияләп торам».* Мондый килешү дөрес түгел, чөнки билгеле түгел].

Рафигъ ибн Хәдидҗ әйтте: ***«Аллаһның илчесе заманнарында кешеләр җирләрен елгалар, инешләр, каналлар янындагы җирләрнең, ягъни әлеге җирнең билгеле бер өлешендә үскән уңышның үзләрендә калдыру шарты белән кулланышка биреп торалар иде. Һәм уңышның әле бер өлеше уңмый, ә икенче өлеше уңа яки киресенчә, ә аларның башка аренда җирләре юк иде. Шуңа күрә Аллаһның илчесе ﷺ болай эшләүдән кисәтте. Билгеле һәм гарантияләнгән уңышка килгәндә [аренда], монда гөнаһлы бер нәрсә дә юк».*** Мөслим.

***«Пәйгамбәр ﷺ Хәйбәр халкы белән аларның бөртеклеләрнең һәм җиләк-җимешнең яртысы бәрабәренә җирдә эшләү шарты белән килешү төзеде».*** Килешенгән хәдис.

| | |
|---|---|
| 1.«Мусака» — агачтан, ул эшчегә билгеле бер өлеш җиләк-җимеш бәрабәренә агачны карап, тәрбияләп торсын өчен бирелә | 2.«Музарага» — җирдән, ул эшчегә билгеле бер өлеш уңыш бәрабәренә җирне эшкәртсен өчен бирелә. |

Һәр як та гадәт буенча үзенә йөкләнгән эшне башкарырга һәм асылында билгесезлек булмаган шартларны үтәргә тиеш.

Әгәр хуҗа эшчегә атланып йөри торган хайванны шуның белән эшләргә дип бирсә, бу рөхсәт ителә.

## ЭШКӘРТЕЛМӘГӘН ҖИРЛӘРНЕ ҮЗЛӘШТЕРҮ

**Эшкәртелмәгән җир** — һич беркем дә дәгъва белдермәгән территория: яткын җирләр, көтүлекләр; кагылгысыз булмаган (ягъни тыныч халыкка булган, яки килешү төзелгән, яки иминлекләре тәэмин ителгән мөселманнарныкы яки имансызларныкы булмаган) җир участоклары.

Үзләштерү — кешеләр үзләштерү яки терелтү яки киресенчә дип санаган бар нәрсә.

Бу хуҗасы булмаган ташландык җир.

Кем аны диварлар төзеп, кое казып, канализация үткәреп яки ашлык чәчү өчен тагын бер эшкәртергә мөмкинлек бирмәгән башка эшләрне башкарып үзләштерсә, шул кеше әлеге участокның (күренеп торган файдалы казылмалар чыганакларыннан тыш, анда булган бар нәрсәсе белән) хуҗасы була. Ибн Гомәр хәдисендә хәбәр ителә: ***«Эшкәртелмәгән җир хуҗасы — аны үзләштергән кеше».*** Бохари.

Әгәр кеше эшкәртелмәгән җирне койма белән тотып куйса, яки кое казыса, яки ничек булса да аерып, бүлеп куйса, әлеге участок аныкы, [чөнки ул үзләштерүне башлады һәм кемдер тарафыннан туктатылмады]. Кеше җирне әле санап үтелгән ысуллар ярдәмендә үзләштерсә генә, ул аныкы булып санала. [Әгәр кеше үзләштерүне сузса һәм башка кеше аны үзләштерергә теләсә, әлеге кешегә рөхсәт бирелергә тиеш].

## КЕШЕНЕ ЭШКӘ АЛУ ҺӘМ АРЕНДА

| |
|---|
| **Кешене эшкә алу —** ул кешегә билгеле яки билгесез эш өчен билгеле яки билгесез вакытта билгеле түләү кую.<br><br>**Аренда** — билгеле бер хезмәт күрсәтү яки билгеле бер эш эшләү турындагы килешү. |
| Ике очракта да билгеле бер күләмдә түләү куела. |

| **Билгелелек, ачыклык ошбу юллар аша билгеләнә:** | |
|---|---|
| 1.Сан һәм сыйфат ягыннан ачыклык, билгелелек | 2.Өлеш һәм түләүне билгеләү. |
| Әгәр кеше шартны үтәгән икән, ул хезмәт хакына лаек, әгәр аренда вакытындагы эш үтәү өчен авыр булмаса. Шулай булган очракта түләү бүленә. | |

| | | |
|---|---|---|
| Пәйгамбәргә ﷺ барып тоташучы бер хәдистә, Әбу Хурайра сүзләреннән хәбәр ителә: ***«Аллаһ Тәгалә әйтә: «Кыямәт көнендә мин өч кешенең дошманы булырмын: Минем Исемем белән ант итеп һәм вәгъдә биреп соңыннан хыянәт иткән кеше; ирекле кешене коллыкка саткан һәм шул акчаларга ашаган кеше; һәм эшчене яллап, аннан эшне тулаем эшләвен таләп итеп, әмма эшләгән хезмәт хакын түләмәгән кеше».*** Мөслим.<br><br>Кешене эшкә алу арендага караганда киңрәк мәгънәгә ия: | | |
| 1.Чөнки ул Аллаһка якынайта торган гамәлләр кылу өчен яраклы. | 2.Билгеле һәм билгесез булган нәрсәләр булган килешү. | 3.Килешүне үтәү мәҗбүри булган арендадан аермалы буларак теләсә кайсы вакытта өзү мөмкин булган рөхсәт ителгән килешү. |

Кешегә арендага бирелгән әйберне янәдән арендага бирергә рөхсәт ителә, бу очракта икенче арендага алучы беренче арендага алучыны алыштыра һәм арендага бирелгән предметка зуррак зыян салмас, дип күз алдында тотыла.

Арендага алучылар чикне узган [ягъни кылырга тиешле булмаганны кылган] очракта гына яки ваемсызлык очрагында [ягъни үз өсләренә алган бурычны үтәмәгәндә] гына зыянны түләргә тиешләр.

Хәдистә әйтелә: ***«Эшкә яллаган эшчегә хезмәт хакын аның маңгаендагы тире кипкәнче түләгез».*** Ибн Мәджә.

**Әгәр кеше башка кеше өчен килешү төземичә генә нинди дә булса эш эшләсә, аңа бернәрсә дә тиеш түгел, ошбу өч очрак кына искәрмә була:**

| | | |
|---|---|---|
| 1.Кагылгысыз милекне бетүдән саклау. | 2.Үзенең хуҗасыннан качкан колны кире кайтару. | 3.Кеше үзен эшкә әзерләгәндә. |

## ТАБЫЛДЫК һӘМ ТАШЛАНДЫК

| [Бүлек: табылдык] Табылдык — ул хуҗасы югалткан һәм кешеләргә әһәмияте булган милек яки кешенең шәхси милеге. 3 төре бар: | | |
|---|---|---|
| 1.Арзанлы әйбер: чыбыркы, ләвәш һәм башкалар.<br><br>Тапкан кеше, табылдык турында белдерү бирмичә генә, аны үзенеке итә ала [монда кешеләр юлда ташлап калдырырга мөмкин булган әйберләр дә керә: ватылган урындык, кайбер савыт-саба һәм башкалар]. | 2.Нигездә ваграк җәнлекләрдән үзләре дә саклана алган югалган хайваннар: дөя, [зур үгезне, атны — әлеге табылдыкларны үзенеке итү тыела, бары тик тапкан кеше әлеге малларны хуҗасы таба алмаячагына инанса гына] — һәм аларны нинди генә очрак булса да үзеңнеке итү тыела. | 3.Башка табылдыклар: кыйммәтлерәк әйберләрне [акча, җәнлекләрдән саклана алмаган вак хайваннар] — бер ел дәвамында табылдык турында белдерү биреп, үзеңә алырга һәм үзенеке итәргә рөхсәт ителә. [Әгәр югалган малны табучы кеше әлеге малны ел буе карап тору малның үз бәясенә караганда кыйммәтрәк чыгудан курыкса, ул аның сыйфатларын исендә калдырып, сатып җибәрә ала, акчасын исә аның хуҗасы өчен саклап тора]. |

Зәйд ибн Халид әл-Джуханидан хәбәр ителә: ***«Бервакыт бер бәдәви Пәйгамбәр янына килде һәм табылдыкны нәрсә эшләтергә кирәклеге турында сорады, һәм (Аллаһның илчесе ﷺ) әйтте: «Кешеләргә әлеге табылдык турында ел буе хәбәр ит, шуннан соң табылган әйбернең барлык сыйфатларын да исеңдә калдыр. Әгәр берәрсе килсә һәм әлеге табылдыкны дөрес итеп тасвирлап бирсә, аны шул кешегә бир. Әгәр тасвирлап бирә***

***алмаса, аның белән куллана аласың». Ул тагын сорады: «Йә Аллаһның илчесе, ә адашкан сарыклар белән нишләргә соң?» Пәйгамбәр ﷺ җавап бирде: «Яки алар сиңа була, яки синең кардәшеңә, яки бүреләргә була». Әлеге кеше янәдән сорады: «Ә адашкан дөяләр белән нишләргә?» Шулвакыт Пәйгамбәрнең ﷺ йөзе ачудан кызылланды, һәм ул болай дип җавап бирде: «Синең аларда ни эшең бар? Аларның бит тояклары һәм сулары бар. Алар, хуҗалары аларны эзләп тапканчы, су янына килә һәм агачтан өзеп яфраклар ашый».*** Килешенгән хәдис.

**Табылдыкны үзеңә алу яхшырак булырмы?** — Үзеңне гөнаһтан саклап әлеге әйберне үз урынында калдыру хәерлерәк булыр, әгәр тапкан кеше белдерү бирүендә ышанса гына алсын.

**Мәккә территориясендә табылдыкларның хөкеме.** Аллаһның илчесе ﷺ әйтте: ***«Табылдыкны алырга ярамый, бары тик аның хакында кешеләргә белдерү бирер өчен генә алырга мөмкин».*** Килешенгән хәдис. Ягъни табылдык турында ел әйләнәсе хәбәр бирергә кирәк. Әгәр тапкан кеше моны эшли алмаса, ул әйберне хөкемдарга бирә.

**[Бүлек: ташландык]**

Нәселе билгеле булмаган һәм баш тартылган бала, ягъни гаиләсе аны үзендә калдырырга теләмәгән, һәм ул югалмаган да.

Ташландыкны алу һәм аны тәрбияләп үстерү җәмәгать бурычы булып тора. Әгәр казна аны тәэмин итә алмаса, әлеге бала белән аның халәтен белгән кеше шөгыльләнергә тиеш.

# ЯРЫШ

3 төре бар:

<table>
<tr><td>1.Приз өчен ярышның рөхсәт ителгән төре: Ат чабышы, дөя чабышы, җәядән ату.</td><td>2.Призсыз ярышның рөхсәт ителгә төре (приз белән рөхсәт ителми): 1нче пунктта саналган 3 төрдән кала барлык башка ярышлар.</td><td>3.Нард, шахмат һәм башка уеннар – нинди шартларда булуына карамастан, тыелган [чөнки калеб бу уеннарга бәйләнә һәм алар күп вакытны ала].</td></tr>
<tr><td colspan="3">Хәдистә килә: «Бары тик дөя чабышында, ат чабышында һәм җәядән ук ату ярышында гына җиңгән өчен приз билгеләргә мөмкин». Әхмәд һәм тагын 3 шәех.<br><br>Башка төр ярышларга килгәндә, алар комарлы уеннарга керә.</td></tr>
</table>

<table>
<tr><th colspan="2">Шунысын белергә кирәк: нинди дә булса рөхсәт ителгән нәрсә, әгәр зыян салса, тыелганга әверелә:</th></tr>
<tr><td>Әгәр ат чабышлары, дөя чабышы һәм җәядән ату ярышы җәмагать намазы вакытында булсалар, алар тыелган.</td><td>Әгәр ярышлар дошманлашуга, нәфрәткә, бер якка гына ярдәмгә һәм фанатизмга китерсә, алар шулай ук тыела.</td></tr>
</table>

<table>
<tr><th>Хайваннар ярышлары</th></tr>
<tr><td>Мондый ярышларның шартлары шул: алар хайваннарның үзләренә һич-нинди зыян китерергә тиеш түгел, киресенчә булса, алар тыела, мәсәлән, этәч, тәкә, үгез сугышлары.</td></tr>
</table>

<table>
<tr><th colspan="3">Бокс ярышының хөкеме<br>(йодрык сугышы)</th></tr>
<tr><td colspan="2">Рөхсәт ителми</td><td rowspan="2">Әмма әгәр кеше йөзгә сукмыйча күнегүләр генә эшләсә, бу рөхсәт ителә.</td></tr>
<tr><td>Чөнки бокс ярышлары вакытында кешенең йөзенә сугу күздә тотыла, ә бу Шәригать тарафыннан тыелган.</td><td>Чөнки хәтәрлеге бар.</td></tr>
</table>

## КЕШЕ МИЛКЕН ҮЗЛӘШТЕРҮ

Бу бернинди хокукларсыз кеше милкенә кул сузу.

Әлеге гамәл тыелган, чөнки хәдистә әйтелә: «***Әгәр кеше чит кешенең биш карыш җирен көч белән үзләштерсә, Аллаһ Кыямәт көнендә аның муенын җиде җир белән уратып алыр***». Килешенгән хәдис.

Читләрнең милкен үзләштергән кеше ошбу гамәлләрне кылырга тиеш:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1.Аны хуҗасына кайтарып бирергә, хәтта арттырып түлисе булса да. | 2. Килгән зыянны компенсацияләргә. | 3.Милек аны үзләштергән кешедә булган вакыт өчен аренда бәясе түләргә. | 4.Нинди генә халәт булмасын, әгәр милек бозылган икән, зыянны капларга тиеш. |
| Милекнең хуҗасы өчен аны арттырырга.<br><br>Әгәр үзләштерелгән әйбер җир участогы булса һәм анда үзләштергән кеше агачлар утыртып, йорт төзегән булса, участокның хуҗасы боларның барысында җимерергә мөмкин, чөнки хәдистә хәбәр ителә: ***«Гаделсезлек кылган кешенең хезмәтенә бернәрсә дә түләнми».*** Әбу Давыд.<br><br>Әгәр хаксыз үзләштерелгән әйбер аның башка кеше кулына күчсә һәм ул әлеге милекнең кешенеке булуын белсә, ул милекне үзләштергән кешегә тиң. | | | |

## ТҮЛӘҮСЕЗ ФАЙДАЛАНУ ҺӘМ САКЛАРГА ТАПШЫРУ

<table>
<tr><td colspan="3">[Түләүсез файдалану]<br><br>— узуфрукт [рөхсәт ителгән булырга тиеш, мәсәлән, китап биреп тору],— хәерле булып санала, чөнки бу изгелек, Пәйгамбәр ﷺ әйтте: «Һәр изге эш — ул сәдака». [Килешенгән хәдис].</td></tr>
<tr><td colspan="2">1.Һәм әгәр:</td><td rowspan="2">2.Башка очракларда кулланып торучы бернәрсә дә түләргә тиеш түгел.</td></tr>
<tr><td>А.Түләү шарт булып торса, түләнә.</td><td>Б. Кулланып торан кеше чикләрне үтсә һәм ваемсызлык күрсәтсә, шулай ук түләтелә.</td></tr>
</table>

<table>
<tr><td>[Сакларга тапшырылган милек]<br><br>[Милекне хуҗасы өчен саклап торачак кешегә тапшыру].<br><br>Саклаучы үзенә сакларга тапшырылган милекне тиешле урында сакларга тиеш һәм хуҗасының рөхсәте булмаса, ул аннан файдалана, куллана алмый [димәк, банкларда саклаcalled акчалар сакларга тапшырылган милек була алмый, ул займ була].</td></tr>
</table>

<table>
<tr><td colspan="5">Саклаучы кеше үзенә сакларга тапшырылган милекне кайчан кайтарырга тиеш?</td></tr>
<tr><td>1.Саклау вакыты тәмамлангач.</td><td>2.Хуҗасы таләп иткәч.</td><td>3.Әгәр караклардан курыкса.</td><td>4.Әгәр саклаучы кеше сәфәргә чыкса.</td><td>5.Әгәр кулланудан туктаса.</td></tr>
</table>

## МИЛЕКНЕ АЛУГА ӨСТЕНЛЕКЛЕ ХОКУК

Кешенең сату яки башка юл белән партнерының өченче затларга күчкән өлешен тартып алырга хокукы.

Бу һич тә бүлеп булмый торган күчемсез милеккә кагыла, чөнки Джәбир хәдисендә, Аллаһ аннан риза булсын, хәбәр ителә: «***Аллаһның илчесе ﷺ бүленмәгән барлык нәрсәләрне дә алуның өстенлекле хокукларын билгеләп куйды. Әгәр чикләр куелса һәм юллар салынса, бу очракта өстенлекле хокук юк***».

Кешене әлеге хокукыннан мәхрүм итәр өчен төрле хәйләләр кору тыелган, һәм төрле хәйләләр корылса да, әлеге хокук барыбер анык булып тора, чөнки хәдистә әйтелә: «***Чынлыкта, гамәлләр ниятләргә карап билгеләнә***».

Әгәр юл бер генә булса, яки партнеры белән бүлешкән теләсә-нинди әйберне күрше сатып алырга өстенлекле хокукка ия була. Киресенчә булганда өстенлекле хокук сакланмый.

**Сатып алуның өстенлекле хокукына мисал:** Ике кеше җир участогына ия. Аларның берсе үз өлешен өченче бер затка сатарга карар кыла. Бу очракта әлеге җир участогының икенче хуҗасының бу җирне, хәтта көч куллану юлы белән дә, үзенә сатып алырга һәм үз өлешенә кушарга хокукы бар. Шуннан соң җир участогы бөтенләе белән анык була.

## ТАРТЫП АЛЫНА АЛМЫЙ ТОРГАН МИЛЕК (ВАКФ)

Бу милекне ничек бар шул рәвештә саклау һәм аның җимешләрен куллану. Бу Аллаһка якынайта торган иң яхшы һәм әгәр дә ул хәйрия эшләренә юнәлтелсә һәм кемнедер кыерсытуга юнәлдерерлгән булмаса, иң файдалы гамәл. Хәдистә хәбәр ителә: «***Кеше вафат булганнан соң, өч гамәлдән кала аның бөтен гамәлләре дә туктатыла. Болар — кешенең вафатыннан соң да дәвам итә торган сәдака; кешеләргә файда китерүче гыйлем; һәм аның өчен Аллаһтан дога кылып сораучы иманлы бала***». Мөслим.

Гомәрнең сүзләреннән китерелә: «*Хәйбәрне яулап алганнан соң һәм җирләрне бүлгәннән соң, Гомәр Пәйгамбәр янына шул хакта киңәшергә дип килә һәм болай ди: «Әй Аллаһның илчесе, мин Хәйбәрдә җир алдым, минем беркайчан да шушы җирдән дә кыйммәтрәк милкем булганы булмады. Миңа аның белән нишләргә боерырсың?» Аллаһның илчесе ﷺ җавап итеп:* ***«Әгәр теләсәң аның нигезен вакф итеп васыять ит һәм ул сиңа китергән уңыштан сәдака бир***», — *диде. Һәм Гомәр әлеге җирне сатарга да, бүләк итәргә дә, мирас итеп алырга да ярамый дигән шарт белән сәдакага әйләндерде, ә әлеге җир китергән табышны фәкыйрьләргә, туганнарга, якыннарга ярдәм итеп, колларны азат итү өчен, Аллаһ юлында һәм мосафирларга ярдәм өчен, шулай ук кунаклар кабул итү өчен юнәлтелергә мөмкин. Әгәр идарәче кеше әлеге җир китергән уңыштан чикләрдән чыкмыйча һәм үзе өчен ниндидер табыш алмыйча тукланса яки үзенең дустын ашатса, монда һич тә начарлык юк*». Килешенгән хәдис.

Иң яхшы вакф — мөселманнарга иң файдалы булганы.

Ул милекне вакф итү өчен кирәкле булган сүзләр яки гамәлләр кылу аркылы тормышка ашырыла.

Милекне вакфка биргән кешенең Шәригать кануннарына туры килүче шартларын үтәү тиешле.

Вакфка бирелгән милекне, әгәр ул файда бирүдән туктамаса, сату тыела. Әгәр файда китерүдән туктаса, ул сатыла һәм аннан килгән акчага шундый ук милек алып куярга кирәк.

| Вакф төрләре: | |
|---|---|
| 1.**Билгеле бер юнәлештә:** хәйрия максатларында | 2.**Билгеле бер кешеләргә**, әмма шарт белән: монда гөнаһка юл куелырга тиеш түгел |

| Вакф һәм васыятьнамә арасындагы аерма: | |
|---|---|
| Вакф<br>— Килешүләрнең юридик яктан мәҗбүр ителгән тибы.<br>— Бөтен милекне дә вакф итеп тапшырырга мөмкин.<br>— варисларга да, башка чит кешеләргә дә тапшырыла ала. | Васыятьнамә<br>— Кешенең вафат булуы белән бәйле булган килешү.<br>— Милекнең өчтән бер өлешен яки кимрәк өлешен генә тапшырырга мөмкин.<br>— Вариска тапшырылмый. |

## ХӘЙРИЯ КИЛЕШҮЛӘРЕ:
## КҮЧТӘНӘЧ, БҮЛӘК, ВАСЫЯТЬНАМӘ

Бу хәйрия килешүләре:

| | | |
|---|---|---|
| 1.Күчтәнәч — исән вакытта һәм сау-сәламәт булганда икенче берәүгә үз милкеңнән иганә итү, бирү. | 2.Бүләк — үлем авыруы белән авырган һәм аннан сәламәтләнүгә өмет булмаган вакытта үз милкеңнән иганә итү, бирү. | 3.Васыятьнамә — вафат булганнан соң милкеңнән иганә итү, бүлеп бирү. |

<table>
<tr><th colspan="3">Авыру төрләре:</th></tr>
<tr><td colspan="2">1.Кешенең тормышына куркыныч тудыручы: кеше сәламәт булуга караганда күбрәк авыру.</td><td>2.Кешенең тормышына куркыныч тудырмаучы: Авыртканга караганда күбрәк сәламәт.</td></tr>
<tr><td colspan="3">Һәртөрле очракта да изгелек һәм иганә кылырга мөмкин.</td></tr>
<tr><td rowspan="2">1.Күчтәнәч төп капиталдан бүленеп бирелә.</td><td colspan="2">2.Бүләк һәм васыятьнамә</td></tr>
<tr><td>А.Өчтән бер яки кимрәк өлеш, вариска түгел.</td><td>Б.Өчтән бердән артыграк һәм вариска да бүләк итү — башка гакыллы варисларның ризалыгыннан тора.</td></tr>
</table>

<table>
<tr><th colspan="4">Милек белән дүрт кеше идарә итә ала:</th></tr>
<tr><td>1.Вәкаләтле вәкил, аңа хуҗа исән вакытта ук аның милке белән идарә итәргә рөхсәт ителгән.</td><td>2.Васыятьнамәне үтәүче, аңа милекне хуҗасы вафат булгач бүлеп бирү рөхсәт ителгән.</td><td>3.Вакф милке артыннан күзәтчелек итүче, аңа милек белән идарә итәргә рөхсәт ителгән.</td><td>4.Баланы опекага алучы кеше, аңа закон тарафыннан опекага алган балаларның, ятимнәрнең милке белән идарә итәргә рөхсәт ителгән.</td></tr>
</table>

**Васыятьнамә үрнәге:**

Бу ________________________ (васыять итеп калдыручының исеме) васыятьнамәсе. Аллаһтан башка гыйбадәткә лаеклы зат юк, һәм Мөхәммәд — Аның колы һәм илчесе.

Мин балаларыма, гаиләмә һәм барлык туганнарыма Аллаһтан куркырга, Ул кодрәтле һәм Бөек, васыять итәм.

Васыять итәм бурычларымны кайтарып бирергә, ул____________________
________________________________________________________________

Васыять итәм «һәм ул үзеннән соң изгелек калдыра» __________________
________________________________________________________________
(мирасның өчтән икесеннән артмаган өлешен) шуңарга: _______________
________________________________________________________________
(варистан тыш милкен васыять итеп калдыручыларның исемнәре).

Мине юган, җирләгән һәм кайгы уртаклашкан вакытта сөннәткә иярергә васыять итәм.

Имзам_______________ Дата________________

Шаһитлар:

## СӘҮДӘ КИЛЕШҮЛӘРЕ КИТАБЫ БУЕНЧА СОРАУЛАР

| Сорау | Дөрес | Дөрес түгел |
|---|---|---|
| — Сәүдә килешүләре шартлары һәм сәүдә килешүләрен төзегәндәге шартлар арасындагы аерымлыклар башка төр килешүләрдә дә, мәсәлән, никах килешүе, булырга мөмкин. | | |
| — Килешүнең һәртөрле шартлары аны юкка чыгара, чөнки килешүләр төзегән вакытта бернинди дә шартлар булырга тиеш түгел. | | |
| — Үзара мөнәсәбәтләрнең нигезе — ул рөхсәт ителгәнлек, тыелганлык турындагы дәлилләр китерелгәнчегә кадәр. | | |
| — Кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләре темасында Имам Мәлик мәзхәбе — барлык мәзхәбләр арасында сөннәткә якын торучы. | | |
| — Имам Мәликнең кешеләр белән үзара мөнәсәбәт кылу турындагы сүзләрен очратсагыз да, сез ул сүзләрнең имам Әхмәт әйткәннәр белән туры килүен күрерсез. | | |
| — Килешүнең нигезенә каршы килүче һәртөрле шарт дөрес түгел. | | |
| — Һәртөрле килешүләр дә халык тарафыннан гомумкабул ителгән кагыйдәләргә муафыйк рәвештә төзелә. | | |
| — Сатып алучы әгәр ул товар турында белмәсә, килешүне өзә ала. | | |
| — Рибага китерә торган барлык гамәлләр каршында Шәригать бөтен ишекләрне дә яба. | | |
| — Җәзасы буенча имансызлыктан да зуррак гөнаһ юктыр, рибадан кала. | | |
| — Ике як тарафыннан да үтәлеше мәҗбүри булган килешү ошбу шартлардан башка өзелә алмый: ике якның да килешүе нигезендә, яки Шәригать тарафыннан каралган башка сәбәпләр аркасында. | | |

— Килешү төзелү өчен рөхсәт бирүе шарт булмаган кеше өчен ул килешү турында белү дә шарт була алмый.

— Килешүче яклар яки бер як икенче якны килешүне өзү хокукыннан мәхрүм итә алалар.

— Әгәр килешүче якларның берсе килешүнең нинди дә булса шартын ачык рәвештә бозса, Шәригать икенче якны яклаячак.

— Кайвакыт кеше, бу хакта уйламыйча яки игътибарга алмыйча, үзенең милкен, сатарга яки берәр нәрсә сатып алырга мөмкин. Шәригать мондый кешеләрнең хокукларын яклый.

— Мөселман кешесе мәнфәгатьләр туры килмәгән очракларда үзе ышанган кеше белән киңәшләшергә тиеш.

— Имамның рөхсәт бирүе ташландык җирләрне үзләштерүнең бер шарты булып тора.

— Табылдык турында бер ел буе кеше күп җыелган җирдә, мәсәлән, мәчетләрдә хәбәр итеп торырга кирәк.

— Вакф — рөхсәт ителгән килешү, аны өзәргә һәм милекне кире кайтарырга мөмкин.

— Балаларга күчтәнәч биргән вакытта гаделлек сакларга кирәк.

— Бөтен мирасның өчтән ике өлешеннән артып китүче милекне васыять итәргә тыела.

— Васыятьнамәне варисларга калдырырга рөхсәт ителә.

— Васыятьнамәне бурычларны түләп бетергәнче тормышка ашырырга кирәк, чөнки Аллаһ Тәгалә әйтте: **«васыятьнамәдән тотып калганнан соң, яки бурычны түләгәннән соң...»**

— Васыятьнамә буенча алынган нәрсәләр үлгәнче шәхси милек була.

— Әгәр кеше үзеннән соң изгелек калдырса, милек васыятьнамәсе калдыру хәерле.

— Сәүдә килешүе шартлары үз көчендә була: сайлау хокукы вакытында_____, әгәр дә моңа ике як та рөхсәтен бирсә____, әгәр килешү төзелсә_____, бөтен санап үтелгәннәр дә____.

— Әгәр килешүнең шарты аның асылына капма-каршы килсә, ул очракта килешү: дөрес___, дөрес түгел___.

— Риба — ул алмашу: сәүдә килешүе дип атала___, сәүдә килешүе дип аталмый___.

— Кешенең сүзләре һәм гамәлләре: гореф-гадәткә___, Шәригатькә___, телгә___ нигезләнә.

— Үлгән мал итен сатарга: рөхсәт итеклә___, рөхсәт ителми____.

— ана карынында булган яралгыны сатарга: рөхсәт ителә_____, рөхсәт ителми____.

— Кешенең товарын урладылар һәм ул аны тапканчы ук сатты: бу рөхсәт ителә____, рөхсәт ителми____.

— Хәзерге заманда төзелә торган финанс килешүләре: бөтенесе дә дөрес түгел, чөнки Шәригатьтә алар турында бер сүз дә юк___, барысы да дөрес, чөнки Шәригать аларны тыймады______, нигездә дөрес, әгәр аларны боза торган нәрсәләр булмаса_______.

— Зәйд Мөхәммәдкә Касым шәһәренә алып килү шарты белән Мәккәдә машина сатты: рөхсәт ителә______, рөхсәт ителми____.

— Зәйд Мөхәммәдкә кимчелекләре өчен сатучы җавап бирми дигән шарт белән йорт сатты, шуннан соң Мөхәммәд анда кимчелек тапты: аның килешүне өзәргә хокукы бар____, хокукы юк____.

— Килешү төзегән яклар тиеш: дөресен сөйләргә һәм анык итеп аңлашырга____, күренми торган кимчелекләрен яшерергә______.

— Зәйд Халидтан кондиционеры да бар дип уйлап машина сатып алды, әмма машина эчендә кондиционер юк иде. Сәүдә килешүе: дөрес___, дөрес түгел__, әгәр Зәйд килешсә, дөрес___.

— Килешү төзегән яклар тиеш: дөресен сөйләргә һәм анык итеп аңлашырга____, күренми торган кимчелекләрен яшерергә______.

— Зәйд Халидтан кондиционеры да бар дип уйлап машина сатып алды, әмма машина эчендә кондиционер юк иде. Сәүдә килешүе: дөрес___, дөрес түгел__, әгәр Зәйд килешсә, дөрес___.

— Кешеләр үзара килешеп сәүдә килешүе төзегән вакытта Шәригать кануннарына: беренче чиратта әһәмият бирелә_____, беренче чиратта әһәмият бирелми____.

— Гомәр Мөхәммәдкә 10.000 риал тиеш, әмма Гомәр бурычы барлыгын кире кага, һәм Мөхәммәд аңа болай ди: *«Үзеңнең бурычыңны таны һәм мин сиңа аннан 3.000 риал бирәм»,*— һәм шуннан соң Гомәр бурычын таный: болай эшләргә ярый____, ярамый___.

— Мәнфәгатьләр каршылыгы килеп туганда беренче чиратта әһәмияткә ия: гомуми мәнфәгатьләр___, шәхси мәнфәгатьләр___.

— Мөхәммәд Әхмәдкә аның өчен 2 көн ураза тотарга кушты: болай эшләү ярый___, ярамый____.

— Өлешләп катнашу килешүендә (әл-гинан): һәр партнер акча кертә һәм эшне башкара____, берәү акча кертә, ә икенчесе эшли___, икесе дә акча кертә, берәү эшне эшли, икенчесе ярдәм итә_____.

— «Әл-муфавада» килешүендә табыш: милек күләменнән____, партнерларның шартларыннан___, уртача табыштан______тора.

— Мөхәммәд һәм Гали бергәләп, өстәмә табыш Мөхәммәдкә, ә калган табышны тигезләп икегә бүләргә дигән шарт белән, сөт фабрикасында эшлиләр: болай эшләү дөрес____, дөрес түгел____.

— Шәраб ясау белән шөгыльләнүче кешегә виноград сатып җибәрү: ярый____, ярамый_____.

— Билгеле булмаган эш өчен түләп кую: ярый___, ярамый____.

— Төшеп калган 4 долларны үзеңә алырга: тыела___ ярый_____, әгәр алсаң: кешеләргә әйтмичә генә алу кирәк____, 1 ел дәвамында табылдык хакында хәбәр биреп торырга кирәк______.

— Табылган дөяне үзеңә алу: ярый____, ярамый ____.

— Табылган кәҗәне үзеңә алу: ярый____, ярамый_____.

— Ату буенча билгеле бер профессионаллар белән ярышырга: ярый____, ярамый_____.

— Бер төркем яшьләр футбол уйнарга сөйләште, ә җиңелгән команда җиңгән команданы кичке аш белән сыйларга тиеш булды. Болай эшләргә: ярый____, тыелган_____.

— Кеше законсыз рәвештә җир участогын үзенеке итте. Әлеге участокның чын хуҗасына ул участокта төзелгән бөтен корылмаларны да җимерергә кирәк_____, тыела_____ ярый_____.

— Шәригатьтә вакфның хөкеме: хәерле____, рөхсәт ителгән____, мәҗбүри______.

— Әгәр рак белән авыручы ир үзенең хатынына җир участогы бүләк итсә, ул нинди хөкемдә була: кучтәнәч___, васыять_____, бүләк______. Бу бүләкне расларга, кабул итәргә мөмкинме: әйе______, юк____.

— Әти кеше үлем авыруы белән авыручы баласының милкен үзенеке итә. Бу гамәл:дөрес_____, дөрес түгел_____.

# МИРАС КИТАБЫ

# МИРАС КИТАБЫ

**Мирасны кемнәргә тиеш, шулар арасында бүлүне өйрәнүче фән.**

Аның нигезендә ята:

| | | |
|---|---|---|
| 1. Аллаһ Тәгаләнең «Хатыннар» сүрәсендәге сүзләре: **«Аллаһ сезгә балаларыгыз турында боера: ир-атка ике хатын-кызның өлеше кадәр өлеш эләгә ...»** дән алып **«Аллаһның чикләре шул...»** га кадәр. | 2.Аллаһ Тәгаләнең шул ук сүрәнең ахырындагы сүзләре: «**Алар синнән карар чыгаруыңны сорыйлар. Әйт: «Аллаһ үзеннән соң әти-әниләр һәм балалар калдырмаганнарыгыз өчен карар чыгарыр»**. | 3.Һәм Пәйгамбәргә ﷺ барып тоташучы Ибн Габбас хәдисе, Аллаһ аларның икесе белән дә риза булсын: ***«Мирас малының тиешле өлешләрен тиешле кешеләргә бирегез, ә бүлеп бетергәннән соңгы өлеше вафат кешенең иң якын ир туганына бирелергә тиеш».*** Килешенгән хәдис |

Әлеге изге аятьләрдә һәм Ибн Габбас хәдисендә мираска кагылышлы әмерләрнең күбесе, аларның тасвирламасы һәм шартлары урын алган. Аллаһ мирасны кыз һәм ир балалар, оныклар (угыл ягыннан), туганнар һәм үги абый-энеләр арасында бүләргә боерды.

Мирасны бүлеп бетергәннән соң ирләргә ике хатын-кыз өлеше кадәр өлеш бирелә.

Һәм әле генә санап үтелгән ир-атлар бөтен милекне яки бүлгәләгәннән соң калган милекне алалар.

## ӨЛЕШ ТИЕШЛЕ КЕШЕЛӘР

<table>
<tr><th colspan="3">Өлеш тиешле кешеләр</th></tr>
<tr><td>Кыз</td><td>Әгәр 1 генә кыз калган булса, аңа мирасның яртысы тиеш.</td><td>Әгәр алар 2 яисә күбрәк булсалар: бөтен мирасның өчтән ике өлеше тиеш</td></tr>
<tr><td>Кыз онык (угыл ягыннан)</td><td colspan="2">Әгәр вафат кешенең 1 кызы һәм 1 кыз оныгы (улы ягыннан) калса: Кыз мирасның яртысын, ә кыз онык алтыдан бер өлешен ала, бергә кушып караганда бөтен мирасның икедән өч өлешен тәшкил итә.</td></tr>
<tr><td>Апа, сеңел</td><td colspan="2">Әгәр вафат булган кешенең әти-әнисе дә, балалары да булмаса, бертуган сеңел-апалар да, әти ягыннан булган кыз туганнар да шуның кадәр үк ала.</td></tr>
<tr><td colspan="3">Әгәр кызларның өлеше өчтән ике өлеш булса, алардан түбәнрәк торган туганнар (улның кызлары) бернәрсә дә алмый, әгәр ир-ат калган өлешне (тагъсыб) алмаган булса.<br><br>Әгәр вафат булган кешенең бертуган апа-сеңелләре калган булса, әти ягыннан булган апа-сеңелләргә бернәрсә дә тиеш булмый, әгәр аларның абыйлары калган өлешне алмаган булса.</td></tr>
<tr><td>Әни ягыннан абый-энеләр</td><td colspan="2">Әни ягыннан булган абый-эне, апа-сеңелнең һәркайсы алтыдан бер өлешне ала, әгәр алар ике яки аннан да артык булса — өчтән бер өлешне ала, ул өлеш ир-атлар һәм хатын-кызлар арасында тигезләп бүленә.<br><br>Әгәр вафат булган кешенең оныклары (кыз оныклары) яки уллары калган булса,</td></tr>
<tr><td>Ир</td><td>Мирасның яртысын ала, әгәр хатынның уллары калмаган булса.</td><td>һәм дүрттән бер өлешне, әгәр калган булса.</td></tr>
<tr><td>Хатын (хатыннар)</td><td>Әгәр ирнең уллары калмаган булса, мирасның дүрттән бер өлешен алалар.</td><td>Әгәр калган булса, сигездән бер өлешен</td></tr>
</table>

<table>
<tr><td rowspan="2">Әни</td><td colspan="2">Әгәр вафат кешенең балалары яки ике яки аннан да күбрәк абый-эне, апа-сеңелләре калган булса, мирасның алтыдан бер өлеше тиеш.</td></tr>
<tr><td>Әгәр әле саналганнар булмаса, өчтән бер өлешне.</td><td>Әгәр вафат булган хатын-кызның ире һәм әтисе дә, әнисе дә калган булса яки вафат булган ир кешенең хатыны һәм әтисе дә, әнисе дә калган булса, калган өлешнең өчтән бер өлеше.</td></tr>
<tr><td>Әби</td><td colspan="2">«Пәйгамбәр ﷺ вафат булган кешенең әбисенә, әгәр аның әнисе исән булмаса, мирасның алтыдан бер өлешен бирде». Әбу Давыд һәм Нәсаи</td></tr>
<tr><td>Әти</td><td>Әгәр вафат булган кешенең уллары калган булса, алтыдан бер өлешне (күбрәк түгел) ала.</td><td>Хатын-кызлар белән бергә мирасның алтыдан бер өлешен ала, һәм аларның өлешеннән соң калган өлеш булса, бу өлешне дә ул ала.</td></tr>
<tr><td>Бабай</td><td colspan="2">Бабай да нәкъ шулай ук.</td></tr>
<tr><td colspan="3">Соңгы ике варис әгәр вафат булган кешенең уллары калмаган булса, һәр очракта да мирасның бүленгәннән калган өлешен алалар.</td></tr>
</table>

# БҮЛЕНГӘННӘН КАЛГАН ӨЛЕШНЕҢ (ТАГЪСЫБ) ШӘРИГАТЬТӘГЕ ХӨКЕМЕ

| Бүленгәннән калган өлешнең (тагъсыб) Шәригатьтәге хөкеме | | |
|---|---|---|
| Ир һәм әнинең абыйсыннан кала ир-ат җенесеннән булган барлык варислар да, бүленгәннән калган өлешне алучы варислар булалар, болар: | | |
| 1.Бертуган абый-энеләр, эти ягыннан абый-энеләр һәм аларның уллары (племянниклар) | 2.Вафат булган кешенең туган абыйсы яки эти ягыннан абыйлары һәм аларның уллары (икетуган абый-энеләре), аның этисенең абыйлары (дядя), бабасының абыйлары (дядя) һәм югарырак. | 3.Шулай ук уллары һәм улларының уллары (оныклары) һәм түбәнрәк. |

| Калган өлешне алучының хөкеме: | | |
|---|---|---|
| 1.Әгәр ул берүзе генә калса, ул бөтен мирасны да ала. | 2.Әгәр аның белән өлеш тигән кеше калса, ул өлешләр бүленгәннән соң калган өлешне ала. | 3.Әгәр мирасны өлешләргә бүлеп бетергәннән соң бернәрсә дә калмаса, калган өлешне алучы кеше бернәрсә дә алмый. Әмма вафат булган кешенең улы яки этисе калган очракта мирас тулысы белән бүленеп бетә алмый. |

| Әгәр вафат булган кешенең мирасының бүленгәннән калган өлешен алучылар ике яки аннан да күбрәк булса, әлеге өлешне түбәндәге тәртип белән алалар: | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1.Уллары | 2.Шуннан соң эти | 3.Абый-энеләр һәм племянниклар | 4. Абыйлар (дядя) һәм икетуган абый-энеләр | 5.Шуннан соң азат ителгән колның яклаучысы һәм аның туганнары. |

| Телгә алынганнар арасында беренчелек түбәндәгеләргә бирелә: | | |
|---|---|---|
| 1.Туганлык җепләре буенча иң якын кешегә. | 2.Әгәр барысы да якын туганнар булсалар, иң якын иткәненә. | 3.Әгәр барлык туган-нар да бертөрле халәттә булсалар, беренчелек аларның иң көчлесенә тиешле: әти ягыннан абый-эне алдында бер-туган абый-энегә. |
| Калган өлешне алучы белән беррәттән, ул һәм абый-энеләрдән тыш, вафат булучының апа-сеңелләре мирастан бернәрсә дә алмый. | | |

## [«ӘЛ-ГАУЛЬ» (БАРЛЫК ВАРИСЛАРГА ДА ӨЛЕШЛӘР ҖИТМӘГӘН ВАКЫТТА ӨЛЕШЛӘРНЕ АРТТЫРУ) ХӨКЕМЕ]

**[«Әл-гауль»(барлык варисларга да өлешләр җитмәгән вакытта өлешләрне арттыру) хөкеме]**

Әгәр варисларның өлешләре мирасның үзеннән артык булсалар, бу очракта варислар саны кими һәм башкаларның өлеше арттырыла.

| **[Мисаллар:]** |
|---|
| 1.Әгәр вафат булган хатын-кызның ире, әнисе һәм бертуган апа яки сеңлесе калган булса, мирасның өлешләре 6 була, әмма аны 8 гә кадәр арттыралар. |
| 2.Әгәр аларның әни ягыннан абый яки энеләре булса, нәкъ шулай ук эшләнә. |
| 3.Әгәр алар ике булса, өлешләр 9га кадәр арттырыла. |
| 4.Әгәр ике бертуган апа яки сеңел булса, өлешләр 10 га кадәр арттырыла. |
| 5.Әгәр вафат булган хатын-кызның ике кызы, әнисе һәм ире калган булса, өлешләр саны 12дән алып 13кә кадәр арттырыла. |
| 6.Әгәр алар белән әтисе калган булса, 15 кә кадәр. |
| 7.Әгәр вафат булган ир-атның ике хатыны, ике бертуган апасы яки сеңлесе һәм әнисе ягыннан ике апасы яки сеңлесе калган булса, 17гә кадәр. |
| 8.Әгәр вафат булган ир-атның эти-шнисе, ике кызы һәм хатыны калган булса, өлешләр саны 14тән алып 17гә кадәр арттырыла. |

| **Беренче мисал** | | 6 | 8 | | **Икенче мисал** | | 6 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Хатын | 1/2 | 3 | 3 | | Ир | 1/2 | 3 | 3 |
| Бертуган апа яки сеңел | 1/2 | 3 | 3 | | Бертуган апа яки сеңел | 1/2 | 3 | 3 |
| Әни | 1/3 | 6 | 6 | | Әни | 1/6 | 1 | 1 |
| | | | | | Әни ягыннан абый яки эне | 1/6 | 1 | 1 |

| **Өченче мисал** | | 6 | 9 |
|---|---|---|---|
| Ир | 1/2 | 3 | 3 |
| Бертуган апа яки сеңел | 1/2 | 3 | 3 |
| Әни | 1/6 | 1 | 1 |
| Әни ягыннан ике апа яки сеңел | 1/3 | 2 | 2 |

| **Дүртенче мисал** | | 6 | 10 |
|---|---|---|---|
| Ир | 1/2 | 3 | 3 |
| Ике бертуган апа яки сеңел | 2/3 | 4 | 4 |
| Әни | 1/6 | 1 | 1 |
| Әни ягыннан ике апа яки сеңел | 1/3 | 2 | 2 |

| **Бишенче мисал** | | 12 | 13 |
|---|---|---|---|
| Ир | 1/4 | 3 | 3 |
| Әни | 1/6 | 2 | 2 |
| Ике кыз | 2/3 | 8 | 8 |
| | | | |

| **Алтынчы мисал** | | 12 | 15 |
|---|---|---|---|
| Ир | 1/4 | 3 | 3 |
| Әни | 1/6 | 2 | 2 |
| Ике кыз | 2/3 | 8 | 8 |
| Әти | 1/6 | 2 | 2 |

| **Җиденче мисал** | | 12 | 17 |
|---|---|---|---|
| Ике хатын | 1/4 | 3 | 3 |
| Әни ягыннан ике апа яки сеңел | 1/3 | 4 | 4 |
| Ике бертуган апа яки сеңел | 2/3 | 8 | 8 |
| Әни | 1/6 | 2 | 2 |

| **Сигезенче мисал** | | 24 | 27 |
|---|---|---|---|
| Хатын | 1/8 | 3 | 3 |
| Әни | 1/6 | 4 | 4 |
| Ике кыз | 2/3 | 16 | 16 |
| Әти | 1/6 | 4 | 4 |

## БАШКА ХӨКЕМНӘР

Әгәр мирасның өлешләре мирасның үзенә караганда кимрәк булсаһәм соңгы варис булмаса, калган өлеш пропорциональ рәвештә һәр вариска кайтарыла.

Әгәр вафат булган ир кешенең өлеш варислары да калган өлешнең варисы да булмаса, мирас телгә алынган туганнардан тыш башка туганнарга күчә, һәм алар якын туганнар хөкемендә булалар.

Бернинди варислары калмаган кешеләрнең милекләре казнага күчә һәм гомуми мәнфәгатьләр өчен, шулай ук кешеләрнең шәхси мәнфәгатьләре өчен дә тотыла.

[Кеше вафат булгач, аның милке белән 4 йөкләмә бәйләнә (تدوم сүзендә җыелган)]:

| | |
|---|---|
| ت | Тәджхиз — җирләүгә тотылган чыгымнар |
| د | Дуюн — расланган һәм расланмаган бурычларны түләү өчен. |
| و | Вәсыйә — васыятьнамә, варислардан башка чит кешеләргә калдырылган милек, ул милекнең өчтән бер өлешеннән тотыла. |
| م | Мирас — өстә саналган варислар арасында калган милекне бүлү. Ә Аллаһ бу хакта яхшырак белә. |

**Мирасның сәбәпләре өч:**

| | | |
|---|---|---|
| 1.Туганлык | 2.Хакыйкый никах | 3.Химаячелек (яклау, канат астына алу) |

Мирасны алуга комачау итүче каршылыклар:

| | | |
|---|---|---|
| 1.Үтерү | 2.Коллык | 3.Дин аермасы |

Әгәр кайбер варислар әни карынында булсалар яки булмасалар һәм башкалар булса, милекне бүлгәнче варисны көтәргә кирәк. Әгәр калган варислар мирасны бүлүне таләп итсәләр, бу очракта фикх галимнәренең, Аллаһ Тәгаләә аларны кичерсен, фикерләренә муафыйк рәвештә гамәл кылырга кирәк.

## КОЛЛАРНЫ АЗАТ ИТҮ

[Коллыкка ике юл белән эләгәләр:]

| | |
|---|---|
| 1.Сугыш вакытында әсир итеп алыну | 2.Кол хатынның хуҗасыннан булмаган баласы |

| Коллык төрләре: | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. «Кинн» — тулы коллык | 2. «Мукатаб» — хуҗасы белән билгеле бер күләмдәге йолым акчасына азат итү турында килешенгән кол. | 3. «Мубагад» — «мукатаб», йолым акчасының билгеле бер өлешен түләгән кол. | 4. «Мудаббәр» — азат ителүе хуҗасының вафатына бәйле булган кол. | 5. Азат ителүе билгеле бер факторларга бәйле булган кол. | 6. Ирекkә җибәрелүе хакында васыятьнамә калдырылган кол. | 7. Баланың әнисе |

Бу колга азатлык биреп, аңа ирек бүләк итү. Бу иң яхшы гыйбадәтләрнең берсе, чөнки хәдистә әйтелә: «***Әгәр мөселман кешесе мөселман колны азат итсә, Аллаһ Тәгалә коллыктан азат ителгәннең һәр сөяге өчен азат итүченең һәр сөяген Уттан коткарыр***». Килешенгән хәдис.

Аллаһның илчесеннән ﷺ сорадылар: «*Ә нинди коллар барысыннан да яхшырак?*» *Ул җавап бирде:* «***Хуҗалары тарафыннан иң югары бәяләнә һәм иң кыйммәт тора торган коллар***». Килешенгән хәдис.

Колны азат итү тормышка ашырыла:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1.«Ирекккә җибәрәм»,— дигән яки шундый ук мәгънәле башка сүзләр белән. | 2.Хуҗа булу — тыелган кан туганын сатып алу, аны автомат рәвештә ирекле итә [мәсәлән, якынлык кылу тыелган хатын-кыз туганын сатып алса]. | 3.Колның гәүдәсенең бер өлешен чабып яки яндырып каты газаплау. | 4. «Әс-Сирая» — өлешне азат итү. Хәдистә хәбәр ителә: ***«Кем дә кем үзенең кол өлешен азат итсә, ул аны тулаем азат итәргә тиеш, әгәр аның милектәшләренә аның өлешеннән калган сумманы түләргә акчасы җитсә, кол ирекле була. Киресенчә булган очракта исә [әгәр ирекккә җибәрүченең акчасы җитмәсә], кол [әлеге кеше] аны азат иткән дәрәҗәдә генә азат булып кала».*** Килешенгән хәдис |

Әгәр колның азат ителүе хуҗасының вафаты белән бәйле булса, хуҗасы вафат булганнан соң ул мирасның өчтән бер өлешенә кермәү шарты белән ирекле була.

Джәбир сүзләреннән китерелә, *ансарлардан булган кеше үзенең үлеменнән соң колының азат ителүе турында белдерде, чөнки аның башка милке юк иде. Бу хәбәр Аллаһның илчесенә ﷺ килеп иреште, һәм ул әйтте: «**Кем аны миннән сатып ала**?» Һәм Нугаим ибн Габдуллаһ аны сигез йөз дирхәмгә сатып алды.*

Колның элеккеге хуҗасының бурычы булган, һәм Пәйгамбәр ﷺ әлеге акчаларны аңа биргән һәм әйткән: «***Үзеңнең әҗәтеңне түлә***». Килешенгән хәдис.

«Әл-китаба» — колның билгеле бервакыт эчендә билгеле бер сумма түләп, хуҗасыннан үз-үзен сатып алуы.

Аллаһ Тәгалә әйтте: «**...әгәр сез аларда игелекле сыйфатлар күрсәгез, аларга шундый хатны бирегез**» — ягъни диннәрендә тугърылык һәм яшәү өчен акча эшли алу сыйфаты.

Әгәр хуҗа кеше колны азат иткәннән соң яки килешү турындагы хатны биргәннән соң фетнә булуыннан курыкса, яки кол яшәү өчен акча эшли алмаса, Шәригать нигезендә ул азат ителми.

«Мукатаб» үзенең бәясен тулаем түләп бетергәннән соң гына ирек ала, чөнки хәдистә килә: «**Мукатаб соңгы дирхәмне түләп бетергәнче кол булып кала**». Әбу Давыд.

Пәйгамбәргә ﷺ барып тоташучы хәдисләрдә Ибн Габбас һәм Гомәрдән хәбәр ителә, Пәйгамбәр ﷺ әйткән: «***Әгәр кол хатын үзенең хуҗасына бала тудырса, аның вафатыннан соң ул ирекле була***». Ә Аллаһ бу хакта яхшырак белә.

**Искәрмә:** Шәригать кануннарын һәм аның дәлилләрен өйрәнүче кеше Шәригатьнең колларны азат итүгә зур игътибар бирүен һәм моңа чакыруын, бу гамәл өчен өчен зур әҗерләр вәгъдә итүен аңлар. Шуңа ишарәләүче кайбер мисаллар:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. Аллаһ Тәгалә хуҗа кешегә әгәр колның диндә тугърылыгын, мөстәкыйль рәвештә яши алачагын һәм акча эшләүгә сәләтен күрсә, аның хатын кабул итәргә боера. | 2.Пәйгамбәрнең ﷺ сүзләре: ***«Әгәр мөселман кешесе мөселман-колны азат итсә, Аллаһ Тәгалә коллыктан азат ителгәннең һәр сөяге өчен азат итүченең һәр сөяген Уттан коткарыр».*** | 3. Колның гәүдәсенең бер өлешен чабып яки яндырып каты газаплау факты буенча азат итү. | 4. Колны якын туганы сатып алу аны азат итә. | 5. Аллаһ тарафыннан гафу ителү өчен бик күп очракларда колны азат итүмәҗбүри рәвештә кирәк яки сайлау хокукы бирелә. | 6. Әгәр уртак булган колның бер хуҗасы үз өлешенә азатлык бирсә, колны тулаем азат итәргә кирәк. Бу кешегә колның башка хуҗаларына да калган бәяне түләп бетерү тиешле. |

## МИРАС КИТАБЫ БУЕНЧА СОРАУЛАР

| Сорау | Дөрес | Дөрес түгел |
|---|---|---|
| — Мирасның өлешләре турындагы фән җиңел, әмма исәпләүгә һәм истә калдырырга кирәк. | | |
| — Мирасның өлешләрен өйрәнгән вакытта мәсьәләләрне чишү тәҗрибәсеннән башка бары тик теоретик белемнәр генә кирәк. | | |
| — Мирасның өлешләре турындагы фән — ул математика. Ә математикада теманы ныгыту өчен практик күнегүләр һәм мәсьәләләр чишәргә кирәк. | | |
| — Кайбер очракларда варисның мирас малын алу өчен сәбәбе бар, әмма ул аны алмый. | | |
| — Хатын-кыз аерылышу периодында, идда вакыты үтмәгән булса, иреннән мирас ала. | | |
| — Никах кебек мирас сәбәбе тулаем аерылышканнан соң гамәлдән чыгарыла, нәкъ никах кебек, тулаем аерылышканнан соң, хәтта идда вакыты үтмәгән булса да. | | |
| — Мәсьәләләрнең нигезе Аллаһның Китабында каралган мирас өлешләреннән алынган һәм ул: ярты — чирек — сигездән бер — өчтән бер — өчтән ике — алтыдан бер. | | |
| — Галимнәрнең фикере бер булган өлешләрнең нигезе 18–36ны тәшкил итә. | | |
| — Вафат булган кешенең мирасын яртышар өлеш алган ике хатын-кызның берләшүе мөмкин түгел. | | |
| — Ярты өлешне мирас итеп алган варислар өчен шарт — шулкадәр үк өлеш мирасны алучы башка варисларның булмавы. | | |
| — Чирек өлешне мирас итеп алучылар турындагы бүлек «ир белән хатын бүлмәсе» дип атала, әмма берничәсенең берләшүе мөмкин түгел. | | |

| | | |
|---|---|---|
| — Әгәр үзе генә булса, хатын мирасның сигездән бер өлешен ала. Әгәр вафат булган ирнең берничә хатыны калган булса, алар дүрттән бер өлеш мирасны үзара бүлешәләр.<br>— Мирасның өчтән берен алучылар арасында — әни яки әби.<br>— Әни ягыннан апалар яки сеңелләр мирасның өчтән берен бары шул очракта гына алалар, әгәр аларның әни ягыннан бер яки берничә абый яки энеләре булса гына.<br>— Әгәр барлык варислар да калган өлешне алучы варислар булып алар арасында өлеш алучылар булмаса, бу очракта аларның санына нигезләнәләр.<br>— Бертуган абый яки энекәшнең улы бертуган абый яки энекәшнең кызыннан аермалы калган өлешне алучы була.<br>— Варислар арасында бернинди халәттә дә мирастан мәхрүм ителми торган варислар бар.<br>— Әгәр мирасны бүлү мәсьәләсендә өлешләрнең артуы (гауль) яки кимүе (родд) булса, бу очракта бөтен өлешләрнең дә суммасына нигезләнәләр.<br>— Бөтен җиде мәсьәләнең дә нигезе «гауль» юлы белән арта.<br>— «Өлешләрнең кимүе (родд)» сүзенең терминологик мәгънәсе — өлешләрнең нигездән азрак булуы.<br>— Әгәр «киметү» (родд) юлы белән мирасны бүлгәндә туганнарның бер генә категориясе булса, бу очракта аларның саны исәпкә алына.<br>— Әгәр «киметү» (родд) юлы белән мирасны бүлгәндә берничә категория туганнар булса, өлешләр берләштерелә һәм мәсьәләләрнең нигезе бөтен өлешләрнең кушылмасыннан чыгып билгеләнә.<br>— Дүрт төр нисбәт, бәйләнеш ул:<br>Әл-мумасалә (охшаш саннар [4:4]),<br>әл-мудахалә (зуррак сан кечерәк санга калдыксыз бүленә [6:3 яки 8:2]),<br>әл-мувафәка (охшамаган саннар, аларның зуррагы кечерәк санга калдыксыз бүленми, әмма ике санның да уртак бүлүчесе бар ([ 8:6/2 ]), | | |

| | | |
|---|---|---|
| әл-мубәянә (охшамаган саннар, биредә зуррак сан кечерәк санга бүленми һәм уртак бүлүче дә юк [7:5 яки 13:12]).<br>— Әл-мубәянә очрагында: бер сан икенче санга бүленә, һәм әгәр калдык калса, мәсәлән, 2:3, әлеге мәсьәләне чишү өчен бүлүче сан итеп 6 алына.<br>— Шәригать кануннарын һәм аның дәлилләрен өйрәнүче кеше Шәригатьнең колларны азат итүгә зур игътибар бирүен һәм моңа чакыруын, бу гамәл өчен өчен зур әҗерләр вәгъдә итүен аңлар.<br>— Колны азат итү — иң яхшы гыйбадәтләрнең берсе. | | |

— Ни өчен без мирасның өлешләрен өйрәнәбез? Һәрбер вариска хокук буенча нәрсә тиеш булса, шуны бүлеп бирү өчен ___, әлеге фәнне өйрәнгән өчен әҗерләр билгеләнгән___, ул бөтен белемнең яртысы булып тора___, барысы да___.

— мирас алуның сәбәпләре саны: 2___, 3___, 4___.

— Вафат булган хатын-кызның кол ире калган: мирас ала___, мирас алмый___.

— Кеше вафат булгач, аның милке белән 4 йөкләмә бәйләнә, һәм алар ошбу сүздә җыелган: عش لك رزق — رنحط - تدوم.

— Мирасның өлешләре фәнен өйрәнү: фарыз___, тиешле___, җәмәгать бурычы____, шәхси бурыч____.

— Ир-ат нәсел сызыгы буенча варислар саны: 10___, 15___, гомумән 10 һәм җентекле 15___.

— Ир-ат һәм хатын-кыз нәсел сызыклары буенча варисларның бердәм саны: 15___ 18___.

— Аллаһның Китабында билгеләнгән мирас өлешләре саны: 6___ 7___ 8___.

— Мәсьәлә нигезләренә кагылышлы бердәм фикер шул: саны чикләнгән____, чикләнмәгән____.

— мирасның яртысын алучы варисларның саны: 4___, 5___, 3___.

— Ир кеше хатыны мирасының чирегенен алсын өчен шарт булып вафат булган хатынның балалары булу тора: балалар бу ирдән___, бу ирдән яки башка ирдән___.

— Кыз мирасның яртысын ала, ошбу затларның булмавы шарт булып торганда: калган өлешне алучы варис___, шуның кадәр үк алучы башка варис___, балалары ___, бөтен саналганнар___.

— Мирасның икедән өч өлешен алалар: яртысына ия кешеләр___, ирдән кала яртысына ия кешеләр___.

— Мирасның өчтән ике өлешен алуның шартлары ул: яртысын алу өчен шартлар___, шуның кадәр үк алучы башка варис булмыйча, яртысын алу өчен шартлар.

— өлешләргә ия кешеләр берләшә, әгәр алар: 2___, икедән артык___, 3тән артык___.

— өчтән бер өлеш мираска ия булучылар саны: 2___, 3___, 4___.

— Әни кеше өчтән бер өлеш мирас ала, әгәр: нәсел калдыручы балалары булмаса___, абыйлары яки энеләре булмаса___, барлык саналганнар да___.

— Әни ягыннан абыйлар яки энеләр өчтән бер өлеш мирас ала, әгәр: вафат булган кешенең нәсел калдырырлык ир балалары булмаса ___, әти, бабайлары булмаса____, барлык саналганнар да___.

— Мирасны бүлү «гөмарийә» дип атала, әгәр вафат булган ирнең хатыны калса: әти-әнисе белән___, балалары белән___, әнисе ягыннан абый яки энеләре белән___.

— Әни ягыннан абый яки энеләре мирасның өчтән берен шушындый принцип буенча бүләләр: ир атка ике хатын-кыз өлешенә тигез өлеш___, ирләргә һәм хатыннарга тигез өлеш___.

— алтыдан бер өлеш мирасны алучы варислар саны: 3___, 6___, 7___, 5___.

— Хатын-кызның мөстәкыйль рәвештә соңгы өлешнең варисы бклган ничә ситуация бар: бу мөмкин түгел___, 1___, 2___.

— Соңгы өлешнең варислары төрләрен санагыз: 2____, 3____, 4_____.

— Соңгы өлешнең мөстәкыйль варислары төрләрен санагыз: 10____, 14____, 18____.

— Соңгы өлеш варисларының башкалар белән төрләрен санагыз: 2____, 3____, 4____.

— Ир, хатын, әни киртә белән капланалар: мәхрүм итү____, киметү____, фактор____.

— Каплану турында белмәүче: мирас малының өлеше турында сорый ала____, сорый алмый_____.

— Артучы (әл-гауль) нигез кагыйдәләре кагыла: алтыдан бер өлеш алучыга кагыла___, алтыдан бер өлеш алмаучыга кагыла____.

— Артмаучы нигез кагыйдәләре кагыла: алтыдан бер өлеш алучыга кагыла___, алтыдан бер өлеш алмаучыга кагыла____.

— Әгәр хуҗа кеше колны азат иткәннән соң яки килешү турындагы хатны биргәннән соң фетнә булуыннан курыкса, яки кол яшәү өчен акча эшли алмаса, аны азат итү яки хатка ризалык бирү Шәргатьтә канунлаштырылган____, канунлаштырылмаган___.

— Колның азат булуы аның хуҗасының вафаты белән бәйле булса, ул: мудаббәр___дип атала, азат итү турында васыятьнамә булу___; һәм хуҗасы вафат булганнан соң ирек ала, әгәр милекнең ошбу өлешләренә кермәсә: өчтән бер___, ярты____, дүрттән бер___.

— Колны азат итү тормышка ашырыла: сүз белән___, гамәл белән____, өлешләп азат итү (колның берничә хуҗасы булганда)___, якын туганы тарафыннан сатып алынуы___, барлык саналганнар да___.

— Коллыкка эләгәләр: ике юл белән___, бер юл белән___, күп ысуллар белән___, һәм коллыктан азат ителүнең ысуллары саны: ике ысул ____, бер ысул ____, күп ысул____.

**Мирасның сәбәпләрен үзенә туры килгән аңлатмасы белән тоташтыр:**

**— Никах** —Мирасның сәбәбе — хуҗаның үзенең колына күрсәткән шәфкате.

**— Хуҗа** — Дөрес никах. Ир хатыннан, хатын ирдән мираска ала.

**— Туганлык** — Якын туганлык. Варис булып вафат булган кешенең балалары, әти-әнисе, һәм якын туганнары тора.

**Вафат булган кешенең мирас малы белән бәйле 5 бурычны тәртип белән санагыз:**

**1.**
**2.**
**3.**
**4.**
**5.**

**Әлеге варисларның мирас алу сәбәпләрен атагыз:**

Әти:
Ир:
Кыз:
Әни ягыннан апа яки сеңел:
Әни ягыннан абый (дядя):
Бертуган абый яки энекәш:
Азат ителгән колның хуҗасы:
Әни ягыннан әби:
Оныкчык:
Әти ягыннан апа (тетя):

**Ир-ат нәсел сызыгы буенча варисларны тәртип белән санагыз:**

| | |
|---|---|
| 1. | 2. |
| 3. | 4. |
| 5. | 6. |
| 7. | 8. |
| 9. | 10. |
| 11. | 12. |
| 13. | 14. |
| 15. | |

**Хатын-кыз нәсел сызыгы буенча варисларны тәртип белән санагыз:**

| | |
|---|---|
| 1. | 2. |
| 3. | 4. |
| 5. | 6. |
| 7. | 8. |
| 9. | 10. |

**Варис булмаганнарның янәшәсенә (×) билгесе, ә варис булганнарның янәшәсенә (*) билгесе куегыз:**

Туган абыйның (дядя) оныгы___ Туган апа (тетя)___ Икетуган апа яки сеңел___

Әни ягыннан абый (дядя)___ Бабайның энисе (әни буенча)___ Бертуган абый яки энекәшнең улы__

Оныкның кызы (угыл буенча)___ Кызның кызы___ Бертуган абый яки энекәшнең кызы__

Мирас тиешле ата-бабаларны автор китабында күрсәткән тәртиптә санагыз:

1. 2. 3. 4. 5. 6.

«Мәсьәләләрнең нигезләрен» тәртип белән санагыз:

1. 2. 3. 4. 5.
6. 7.

Әле санаганнарның кайсылары «Мәсьәләләрнең нигезләре»нә керә:
Яртысы (1/2)
Дүрттән бер (1/4)
Сигездән бер (1/8)
Өчтән ике (2/3)
Өчтән бер (1/3)
Алтыдан бер (1/6)

Мәсьәләнең нигезе =...............................................................................................

Мирасның яртысын алучы варисларны тәртип белән санагыз:
1. 2. 3. 4. 5.

Бушлыкларны тулыландырыгыз:
Ир мирасның яртысын ала әгәр_______булмаса
Нәсел калдыручы яшь буын — ул _______
Әти мирасның 1/6 өлешен ала _______булганда
Әти мирасның 1/6 өлешен һәм калган өлешне ала _______булганда
Әни 1/6 өлешне ала әгәр _______
Бабай мирасны ала _______булмаганда
Әби мирасның 1/6 өлешен ала _______булмаганда
Әгәр вафат булган кешенең әтисе, әнисе, бабасы һәм әбисе калган булса, мирас алар арасыннан _______тиеш
«Әнинең баласы» _______керә
Әби мирасның 1/6 өлешен ала _______булмаганда
Әгәр вафат булган кешенең әтисе, әнисе, бабасы һәм әбисе калган булса, мирас алар арасыннан _______тиеш
«Әнинең баласы» _______керә
Улның кызы (яки улның кызлары) мирасның 1/6 өлешен ала _______ булганда һәм _______булмаганда
Бертуган апа яки сеңел (апалар яки сеңелләр) мирасның 1/6 өлешен ала _______ булганда һәм _______булмаганда
Әнинең баласы мирасның 1/6 өлешен ала _______ булганда һәм _______булмаганда

Мөстәкыйль соңгы өлеш варислары ул _______; _______ һәм _______тыш, ә хатын-кызлардан _______

Соңгы өлеш варислары (хатын-кызлар) башкалар белән бергә ул _______ яки _______ яки _______ _______ яки _______белән бергә

**Киртәләр (хаджб) 2 төрле була:** 1. 2.

**Кеше тарафыннан киртә куелу:** 1. 2.

**«Гауль» кермәгән нигезләр:**

**«Гауль» кергән нигезләр:**

6 нигезе _______кадәргә арта,

12 нигезе _______кадәргә арта,

24 нигезе _______кадәргә арта,

«Әл-мунасихат»:

Телдәге мәгънәсе «нәсх»,

Ә терминологик мәгънәсе: _______

**Тоташтырыгыз:**

| | |
|---|---|
| Коллык | — Мөселман кешесе имансыздан мирас алмас |
| Диндәге аерымлык | — Чөнки колның үзенең милке юк һәм ул үзе дә хуҗаның милке |
| Кеше үтерү | — Кем дә кем нәрсәне дә булса тизләнүе турында кайгыртса, ул шул әйбердән мәхрүм ителү белән җәзалана. |

**Коллыкның термины белән аның мәгънәсен тоташтыр:**

| | |
|---|---|
| «Кинн» | — Өлешчә кол, өлешчә иректә |
| «Мукатаб» | — Тулысынча кол |
| «Мудаббәр» | — Ирегә хуҗасының үлеменә бәйле |
| «Мубагад» | — Акчасын өлешләп биреп, үзенең ирекен сатып алырга тиеш |

# НИКАХ КИТАБЫ

# НИКАХ КИТАБЫ

Никах — ул хатын-кыз белән җенси якынлык кылу, балалар табу һәм башка файдалар максатында килешү төзү.

Никах рәсүлләр кануннарына карый. Хәдистә хәбәр ителә: ***«Әй, яшь егетләр! Гаиләсен тәрбияләп торырга сәләтле булган һәркайсыгыз гаилә корсын, чөнки никах күз карашларын түбән төшерә һәм гыйффәтлекне саклый. Гаиләне тәрбияли алмаган кеше исә ураза тотсын».*** Килешенгән хәдис.

Ул шулай ук әйтте: ***«Хатын-кызга дүрт нәрсә сәбәпле өйләнәләр: байлык, нәселе, матурлыгы һәм дине. Кулларың тузан белән каплансын, хатын-кызның динле булганына өйләнергә тырыш».*** Килешенгән хәдис.

Хатынлыкка сайларга кирәк: динле, нәселле, ярата торган һәм бәби табарга сәләтле хатынны.

Әгәр ир-ат билгеле бер хатынга өйләнергә карар кылса, ул, өйләнергә теләге тусын өчен, аңа карый ала.

| **Хатын-кызга карау рөхсәт ителгән шартлар барлыгы 6:** | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 1.Аның белән икәүдән икәү генә калмыйча | 2.Җенси ярсынулардан башка | 3.Әгәр ризалык турындагы фикер өстен булса | 4.Тәннең гадәттә күренеп торган өлешләренә карау | 5.Өйләнергә дигән нык карар | 6.Хатын-кызның бизәнмәве, матур күлмәкләр кимәве һәм ислемайлар сөртмәве |

Мөселман кешесенең кардәше кулын сораган кызны яучыларга хакы юк, кардәше моңа ризалык биргәнче яки әлеге кызга өйләнергә теләген кире какканчы.

Идда вакытын көтүче хатын-кызга һичнинди шартларда да ачык рәвештә яучыларга ярамый. Әмма тулы талак алган хатын-кызга ниятең барлыгын ишарәләү рөхсәт ителә, мәсәлән тол хатынга һәм башкалар, чөнки Аллаһ Тәгалә әйтә: **«Хатын-кызга өйләнергә ниятеңне барлыгын ишарәләүдә гөнаһ юк».** Ишарәләүгә мисал: *«Мин синең кебек хатынга өйләнергә теләр идем»* яки *«Сиңа өйләнү мөмкинлегеннән мәхрүм итмә мине»* һәм башкалар.

**Кагыйдә:** никахлашу рөхсәт ителмәгән хатын-кызның аерым ачык кулын сорау тыела. Никахка ишарәләүгә килгәндә исә аныклау кирәк.

Никахлашкан вакытта Ибн Масгуд хөтбәсен үткәрергә кирәк, ул әйтте: «Аллаһның илчесе ﷺ безгә тормышның барлык очракларына да ярый торган хөтбә өйрәтте: ***«Хакыйкатьтә, барча мактау Аллаһ Тәгаләгә, без Аны мактыйбыз, Аннан ярдәм һәм гафу сорыйбыз һәм калебләребезнең әшәкелегеннән һәм начар эшләрдән Аллаһта сыену эзлибез. Кемне Аллаһ туры юлга күндерсә, аны берәү дә ялгыш юлга җибәрә алмас, ә кемне ялгыш юлга кертсә, аны беркем дә туры юлга күндерә алмас. Шәһәдәт бирәм: Аллаһтан башка табынырга лаеклы зат юк, һәм Мөхәммәд — Аның колы һәм Рәсүле»*** — һәм өч аять укырга кирәк, галимнәр әлеге өч аятьне ошбу аятьләр дип күрсәтә:

| | | |
|---|---|---|
| **1.Әй иман китергән бәндәләр! Аллаһтан тиешле дәрәҗәдә куркыгыз һәм мөселман булып вафат булыгыз!** | **2.Әй кешеләр! Сезне бер кешедән бар иткән, аннан пар яралткан һәм аларның икесеннән туган күп ирләр һәм хатыннарны дөнья буйлап чәчкән Раббыгыздан куркыгыз. Бер-берегездән Аның исеме белән сораган Аллаһтан куркыгыз һәм туганлык җепләрен өзүдән куркыгыз. Чынлыкта, Аллаһ сезне күзәтә.** | **3.Әй иман китергән бәндәләр! Аллаһтан куркыгыз һәм бары тик дөресен генә сөйләгез.** |

Мәҗбүри:

| | |
|---|---|
| 1.**Тәкъдим** — опекун сүзе, мәсәлән: «Мин сиңа кияүгә бирәм» яки *«Мин сине...белән никахлыйм»* | 2.**Кабул итү** — кияүнең яки аның вәкиленең сүзе, мәсәлән: *«Бу никахны кабул итәм»* һәм башкалар. |

## НИКАХ ШАРТЛАРЫ

Ике якның да ризалыгы кирәк, ошбулардан башка:

| | |
|---|---|
| 1.Әтисе никахка мәҗбүр иткән кеч-кенә кыз бала. | 2.Хуҗасы никахка мәҗбүр иткән кол хатын-кыз. |

Никах өчен опекун кирәк. Пәйгамбәр ﷺ әйтте: ***«Опекунсыз никах юк»***. Дөрес хәдис, аны биш галим китерә.

Ирекле хатын-кызны кияүгә бирергә ошбу кешеләрнең хокуклары күбрәк:

| | | |
|---|---|---|
| 1.Әти һәм баба-лары | 2.Угыл һәм аның дәвамчылары | 3.Шуннан соң якын туганнары, ә алар арасында — соңгы өлеш варислары. |

Килешенгән хәдистә хәбәр ителә: ***«Инде кияүдә булган хатын-кызга, аның белән киңәшләшмичә, ә әле кияүдә булмаган яшь кызга, аның ризалыгын алмыйча, өйләнергә ярамый». Кешеләр сорадылар: «Әй Аллаһның рәсүле! Ул үзенең ризалыгын ничек күрсәтә ала?» Ул әйтте: «Дәшмичә».*** Пәйгамбәр ﷺ шулай ук әйтте: ***«Никах турында хәбәр итегез».*** Әхмәд.

Никахны шушы юллар аша белдерелә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| Ике иманлы ир кешенең шаһәдәте | Никахлашу турын-дагы хәбәрне тарату | Бубенда уйнап | Һәм башкалар |

Опекунга хатын-кызны үзенә тиң булмаган кешегә кияүгә бирү тыела. Гөнаһлы кеше иманлы хатын-кызга тиң түгел; ә гарәпләр бер берсенә тиң. Әгәр опекун бөтенләй булмаса яки озак вакыт читтә булса, яки кызны үзенә тиң кешегә киягә бирергә баш тартса,— никах килешүен казый төзи, бу хакта хәдистә хәбәр ителә: ***«Опекуны булмаган кешенең опекуны хаким була»***. Хәдисне, Нәсаидән башка, «Сунан» китабының авторлары китерде.

Никахлашучы кешеләрнең кем булуларын ачыкларга кирәк. Әгәр кешенең тагын кызлары булса, *«Сиңа үземнең кызымны кияүгә бирәм»*,— дип әйтергә ярамый. Кәләшне исеме, сыйфатлары белән әйтергә яки ишарә белән күрсәтергә кирәк.

Шулай ук никах өчен кияүдә дә, кәләштә дә нинди дә булса киртәләрнең булмавы кирәк. Алар никах вакытында тыелган нәрсәләр темасында телгә алыныр.

## НИКАХ ВАКЫТЫНДА ТЫЕЛГАН НӘРСӘЛӘР

Ике төре бар: бөтенләйгә тыелган, билгеле бер вакытка кадәр тыелган:

<table>
<tr><td rowspan="5">1.Бөтенләйгә тыелган</td><td rowspan="2">7 кан туганнар</td><td>1.Әни һәм аннан югарырак</td><td colspan="2">2.Кызлар һәм алардан түбәнрәк</td><td>3.Бөтен апалар һәм сеңелләр</td></tr>
<tr><td>4.Апа һәм сеңелләрнең кызлары</td><td colspan="2">5.Абый һәм энеләрнең кызлары</td><td>6.7.Әти һәм әни ягыннан апалар (тетя), шулай ук әти-әнинең апалары (тетя)</td></tr>
<tr><td>7 сөт туганнар</td><td colspan="4">Кан туганнар кебек үк.</td></tr>
<tr><td>4 никах буенча туганнар</td><td>1.Хатыннарның әниләре һәм алардан югарырак</td><td>2.Әгәр хатын белән җенси якынлык булган булса, хатыннарның кызлары һәм алардан да түбәнрәк.</td><td>3.Әтиләрнең хатыннары һәм югарырак</td><td>4.Улларның (кан һәм сөт улларның) хатыннары һәм алардан түбәнрәк</td></tr>
<tr><td>Боларның нигезендә ята:</td><td colspan="2">Аллаһ Тәгаләнең сүзләре: «Сезгә әниләрегез тыелды…» аятьнең ахырына кадәр</td><td colspan="2">Пәйгамбәрнең ﷺ сүзләре: «Кан туганлык тыйган нәрсәләрне сөт туганлык та тыя». Килешенгән хәдис.</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| **2. Билгеле бер вакытка кадәр тыелган** | Пәйгамбәрнең ﷺ сүзләрендә: ***«Берьюлы бер хатын-кызга һәм аның әтисе ягыннан апасына (тетя), шулай ук бер хатын-кыз һәм аның әнисе ягыннан апасына (тетя) өйләнергә ярамый».*** Килешенгән хәдис. |
| | Аллаһ Тәгаләнең сүзләре белән: **«...апасына да, сеңлесенә дә берьюлы өйләнү тыела».** |
| | Ирекле ир кешегә берьюлы 4 тән дә артыграк хатын белән, ә колга 2дән дә артыграк хатын белән яшәргә тыела.<br><br>Җарияләргә килгәндә исә, хуҗа кеше күпме тели, шулкадәр тота ала.<br><br>Әгәр апалы-сеңелле 2 хатынга өйләнгән имансыз кеше ислам динен кабул итсә, аңа бу ике хатынның берсен сайларга кирәк; әгәр аның 4тән дә артык хатыны булса, аңа алар арасыннан 4не сайлап алырга, ә калганнары белән аерылышырга кирәк. |

Шулай ук никахлашу тыела:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. Хаж кылучы хатынга, хаҗы тәмам булганчы. | 2.Идда вакытын көтүче хатынга, ул вакыт үтеп китмичә. | 3.Зина кылучы хатын зина кылучы иргә, тәүбә иткәнчегә кадәр. | 4.3 талак әйтелгән хатын икенче иргә кияүгә чыгып, якынлык кылып, аның белән аерылышып һәм янәдән идда вакытын көтеп бетергәнчегә кадәр. |

Җария сыйфатында апалы-сеңелле 2 хатынны тотарга рөхсәт ителгән, әмма әгәр аның берсе белән җенси якынлык кылынса, аның икенчесе бу иргә тыела, беренчесе ирекле булганчыга яки ирекле булганнан соң икенче берәүгә кияүгә чыкканчыга кадәр.

Никахны тыючы сөт туганлык имидән аерганчыга кадәр биш яки аннан да артыграк ашатудан соң билгеләнә.

Шулай итеп, бала һәм аның булачак балалары сөт әнинең балалары була һәм «сөт хуҗасына» абый һәм энекәшләргә әверелә.

Кан туганлык тыйган нәрсәләрне сөт туганлыгыда тыя.

## НИКАХ ВАКЫТЫНДА ШАРТЛАР

<table>
<tr><td colspan="3">Никах, сәүдә килешүләре һәм башка үзара мөнәсәбәтләр вакытындагы шартлар ике төргә бүленә:</td></tr>
<tr><td rowspan="2">1.Килешүне төзү факты буенча шартлар: аны үтәргә кирәк, хәтта ул турыда килешүне төзегән вакытта телгә алынмаса да, мәсәлән, хатыныңа карата яхшы мөнәсәбәттә булу.</td><td colspan="2">2.Өстәмә шарт, ул да ике төрле була:</td></tr>
<tr><td>А. Дөрес, аны үтәргә кирәк.</td><td>Б. Дөрес булмаган, аны үтәү тыела, хәтта ул хакта килешү төзегән вакытта сөләшенсә дә.</td></tr>
</table>

Ир белән хатынның бер-берсенә куйган шартлары ике төрле була:

| | |
|---|---|
| 1.Дөрес. Мәсәлән, хатынның иренә үзе исән вакытында икенче хатынга өйләнмәү, җарияләр тотмау, туган шәһәреннән яки иленнән алып китмәү, мәхернең күләмен арттыру һәм башка шартлар куюы. Болар барысы да Пәйгамбәр ﷺ сүзләренең асыл мәгънәсенә туры килә: ***«Үтәлергә иң лаек шартлар — ул никах килешүе шартлары»***. Килешенгән хәдис. | 2.Дөрес булмаган шартлар. Мәсәлән, вакытлача никах (мутга), хатын-кызның элеккеге иренә рөхсәт ителгән булуы өчен, һәм никах бүләгеннән башка булган каршы никахлар (шигар). |

Башта Пәйгамбәр ﷺ вакытлыча никахларны рөхсәт иткән иде, аннан соң ул аларны тыйды.

Ул шулай ук мухаллилне дә (элеккеге хатынны хәләл итүче), мухалләлә ләхуне дә (элеккеге хатынны кем өчен хәләл итәләр, шул) каргады.

Пәйгамбәр ﷺ шигарне дә (ягъни ике кешенең бер-берләренә үз тәрбияләрендә булган кызларны никах бүләгеннән башка кияүгә бирүләре)тыйды. Бу хактагы бөтен хәдисләр дә дөрес.

## НИКАХ ВАКЫТЫНДАГЫ КИМЧЕЛЕКЛӘР

Әгәр ир белән хатынның берсе икенчесендә никахка кадәр билгеле булмаган ниндидер кимчелек [никахның мәгънәсенә каршы килүче сыйфат] тапса, мәсәлән:

| | |
|---|---|
| 1.Юләрлек, махау яки башка шуның ише авыру, ул никахны килешүен өзә ала. | 2.Әгәр ир импотент булса, аңа бер елга кадәр кичектерү бирелә, әгәр бер нәрсә дә үзгәрмәсә, хатын аннан аерылырга хокуклы. |

Әгәр кол хатын-кыз ирек алса, ә аның ире кол халәтендә калса, аның сайларга хокукы бар:

| | |
|---|---|
| 1.Аның белән калырга. | 2.Аннан аерылырга. |

Чөнки бу хакта Гайшәдән килгән бик озын хәдистә хәбәр бирелә, анда ул Бәрирә тарихын сөйли: ***«Бәрирәгә, азат ителгәннән соң, үзенең иренә карата сайлап алу хокукы бирелде».*** Килешенгән хәдис.

Әгәр никах өзелгән булса:

| | |
|---|---|
| 1.Женси мөнәсәбәткә кадәр: мәхер түләнми. | 2.Женси мөнәсәбәттән соң: мәхер билгеләнә, һәм ир алдаган кешесе янына кайтырга тиеш. |

# НИКАХ БҮЛӘГЕ КИТАБЫ

## НИКАХ БҮЛӘГЕ КИТАБЫ

Никах бүләге — ул никах килешүе төзегәннән соң яки хаталану сәбәпле [мәсәлән, ялгышлык белән җенси мөнәсәбәткә керү (буталчыклык аркасында)] аның бер гамәлен кылганнан соң фарыз булган билгеле бер бүләк.

## [НИКАХ БҮЛӘГЕ ХӨКЕМЕ]

Аны җайлы итәргә кирәк (ләкин тулаем бетермәскә, һәм ул бары тик хатынныкы гына була).

Гайшәдән сорадылар: ***«Аллаһның илчесе ﷺ биргән никах бүләге нинди күләмдә иде?» Һәм ул җавап бирде: «Аның хатыннарының никах бүләге 12 окий һәм нашш иде». Ул сорады: «Син нашшның нәрсә икәнен беләсеңме?» Мин җавап бирдем: «Юк». Ул әйтте: «Ул окийнең яртысы. Ул 500 дирхәм»***. Мөслим.

***«Пәйгамбәр ﷺ Сафийяне коллыктан коткарды һәм аңа никах бүләге итеп ирек бүләк итте».*** Килешенгән хәдис.

Пәйгамбәр ﷺ бер ир-атка әйтте: ***«Тимер балдак булса да эзлә».*** Килешенгән хәдис.

Нинди генә кечкенә булмасын, кыйммәте булган һәм түләү сыйфатында бирелә ала торган бар нәрсә дә никах бүләге сыйфатында була ала.

Әгәр никах мәхерсез генә укылган икән, хатынга уртача мәхер тиеш.

Әгәр талак җенси якынлыкка кадәр бирелгән булса, хатын-кызга, ир-атның матди мөмкинлекләреннән чыгып, компенсация тиеш, Аллаһ Тәгалә әйтте: **«Әгәр хатыннарыгыз белән аларга кагылганчы аерылышсагыз һәм никах бүләген билгеләмәгән булсагыз, монда сезгә гөнаһ юк. Аларга тиешле**

**дәрәҗәдә түләгез, бай кеше — үз мөмкинлекләреннән, ярлы кеше үз мөмкинлекләреннән чыгып эш итсен. Изгелекләр эшләүчеләрнең бурычлары шул.»**

**Никах бүләге билгеләнә:**

| **1.Тулаем** | | **2.Яртылаш** ир тарафыннан талак әйтелеп җенси якынлыкка кадәр аерылышсалар. | **3.Бетерелә** | |
|---|---|---|---|---|
| А.Үлем булганда | Б.Җенси якынлык булганда | | А.Хатын инициативасы белән аерылышканда | Б.Яки хатында теге яки бу кимчелекләр булу сәбәпле аерылышканда. |

Хатынына талак биргән ир аңарга мораль зыян өчен компенсация сыйфатында акча түләргә тиеш, чөнки Пәйгамбәр әйтте: ***«Аерган хатыннарны тиешле дәрәҗәдә тәэмин итәргә тиешле. Аллаһтан куркучыларның бурычлары шул».***

## ИР БЕЛӘН ХАТЫН ТОРМЫШЫ

Ир дә, хатын да бер-берләренә Шәригать һәм гореф-гадәтләр хуплаганча мөнәсәбәт кылырга тиешләр: дустанә, зыян салмыйча һәм бер-берсе каршындагы бурычларны үтәүне калдырмыйча.

| 1.Хатын бурычлы: | | | 2.Ир бурычлы: | |
|---|---|---|---|---|
| А.Женси якынлыкта иргә буйсынырга | Б.Аның рөхсәтеннән башка йорттан чыкмаска һәм сәяхәткә китмәскә | В.Өй буенча ашарга әзерләү кебек эшләрне эшләргә | А.Хатынны тәэмин итәргә | Б. Аны гореф-гадәтләргә муафыйк рәвештә киендерергә. |

Аллаһ Тәгалә әйтте: **«Алар белән лаеклы рәвештә яшәгез»**, ә хәдистә әйтелә: ***«Хатыннарыгызга карата яхшы мөнәсәбәттә булыгыз».*** Килешенгән хәдис. Һәм ***«Сезнең арагыздан иң яхшыгыз — үз гаиләгезгә иң яхшы мөнәсәбәттә булганыгыз».*** Тирмизи.

Пәйгамбәр ﷺ шулай ук әйтте: ***«Әгәр ир хатынын ятакка чакырса, һәм ул аңа баш тарту белән җавап кайтарса, һәм ир аңа ачулы килеш йокларга ятса, фәрештәләр бу хатынны иртә булганчыга кадәр ләгънәт укырлар».*** Килешенгән хәдис.

Ир хатыннарына карата ошбу нәрсәләрдә гадел булырга тиеш: төннәрне бүлүдә, тәэмин итүдә, кием алуда һәм нәрсәдә мөмкин булса шунда.

Хәдистә әйтелә: ***«Кемнең ике хатыны булып, ул аның берсенә генә илтифат итсә, Кыямәт көнендә параличланган тән белән килер!»*** Килешенгән хәдис.

Әнәс сүзләреннән хәбәр ителә: ***«Сөннәткә муафыйк рәвештә, әгәр өйләнгән ир гыйффәтле кызга өйләнсә, ул хатыны белән җиде төн үткәрергә тиеш, шуннан соң гына хатыннарына чираттан барырга тиеш. Әгәр ул инде кияүдә булган хатынга өйләнсә, ул хатыны белән өч төн үткәрергә тиеш, шуннан соң ул хатыннарына чираттан барырга тиеш».*** Килешенгән хәдис.

Гайшә әйтте: ***«Пәйгамбәр ﷺ сәфәргә чыккан вакытта, хатыннары арасында жирәбә сала иде, һәм жирәбә чыккан хатыны Пәйгамбәр ﷺ белән бергә бара иде».*** Килешенгән хәдис.

Әгәр хатын ир белән төн үткәрү, тәэмин итү яки кием алу хокукыннан иренең рөхсәте белән баш тартса, бу рөхсәт ителгән.

***«Сәүдә бинт Замгат үзенең көнен Гайшәгә бүләк итте һәм Пәйгамбәр ﷺ Гайшә белән үзенең көнен дә, Сәүдә көнен дә үткәрә иде».*** Килешенгән хәдис.

<table>
<tr><td colspan="3">Әгәр ир хатынның аны тыңламавыннан курыкса [ягъни аның каршындагы бурычларын үтәмәвеннән курыкса], һәм моның билгеләре инде күренә башласа, болай эшләргә кирәк:</td></tr>
<tr><td>1. Аны вәгазьләргә.</td><td>2.Әгәр ул туктамаса, аның ятагын ташлап китәргә.</td><td>3.Әгәр инде ул вакытта да туктамаса, аңа җиңелчә генә сугарга кирәк. Хәдистә әйтелә: «Аллаһның илчесе ﷺ үз гомерендә беркемгә дә сукмаган: хатын-кызга да, колга да». Мөслим. Пәйгамбәр ﷺ әйтте: «Үзләренең хатыннарын колларны кыйнаган кебек кыйнамагыз һәм көн ахырында алар белән бер ятакка яткан кешеләр кебек булмагыз». Килешенгән хәдис</td></tr>
</table>

<table>
<tr><td>4.Әгәр ир белән хатын арасында бозылышу куркынычы булса, казый ир ягыннан да, хатын ягыннан да ситуацияне белүче судьяларны җибәрә. Әгәр аларның икесе дә аларны дуслаштырырга теләсә, аларны билгеле бер түләүгә яки башка әйбер бәрабәренә дуслаштыралар яки аералар. Судьялар нәрсә генә эшләсәләр дә, аларга ул рөхсәт ителә. Ә Аллаһ бу хакта яхшырак белә.</td><td>5.Әгәр хатын ул очракта да буйсынмаса, аңа бер идда вакыты дәвамында талак бирелә.</td></tr>
</table>

**Кыскача:** Аллаһ әйтте: **«әгәр алар сезгә буйсынсалар...»** һәм үз-үзен тотышын дөресләсә, **«аларга каршы юллар эзләмәгез»**, ягъни нәрсә булганын исләренә төшереп тормагыз,үткәннәргә кайтып: *«син болай эшләдең, ә мин сиңа болай дидем»,* дип әйтмәгез. Үткәнне үткәндә калдырыгыз.

**Сорау:** әгәр хатын ирнең аны күралмый башлавыннан курыкса, моның хөкеме нинди?
**Җавап: «Әгәр алар килешсәләр, аларның өстендә гөнаһ булмас»** — ягъни мөстәкыйль рәвештә.

**Ничек теләсәләр (дуслаштырыргамы, аерыргамы), шулай хәл итүче судьяларның билгеле бер шартлары бар:**

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1.Ир затыннан булу | 2.Якын туганлык | 3.Шәригатьне һәм ситуацияне белергә тиешләр | 4.Дуслаштыру теләге булырга тиеш. |

## ХАТЫН ТАЛӘБЕ БУЕНЧА АЕРЫЛЫШУ (ХУЛЬГ)

Гаиләдәге начар мөнәсәбәтләр нәтиҗәсендә хатын белән, аннан яки башка заттан акча түләтеп, аерылышу.

Мондый аерылышуның нигезенә Аллаһ Тәгаләнең сүзләре ятты: **«һәм әгәр сез алар Аллаһның чикләүләрен саклый алмаслар дип курыксагыз, әгәр ул талакны сатып алса, аларның икесендә дә гөнаһ юк».**

Әгәр иманлы хатынга ирнең әхлагы яки аның буй-сыны ошамаса, һәм ул, ире янында калып, ирнең хокукларын һәм үзенең аның каршындагы бурычларын үти алмам, дип курыкса, иренә аның белән аерылышкан өчен йолым акчасы түләсә, аңарда гөнаһ булмас.

Мондый талакның дөреслеге йолым акчасының аз яки күп булуына карамый, ә талакның биргән талагы дөрес булучыдан тора.

Әгәр Аллаһ куйган чикләүләрне үти алмавы хакында борчылмаган хатын-кызга килгәндә, аның хакында хәдистә килә: ***«Нинди генә хатын-кыз үзенең иреннән бер сәбәпсез талак сораса, аның өчен хәтта Җәннәтнең исе дә харам булыр!»*** Хәдисне «Сунан» китабының кайбер авторлары китерде. Мондый хатынны ирен тыңламаудан кисәтергә кирәк, әгәр моңа сәбәпләрбулмаса һәм аларның никахлары әйбәт булса.

# ТАЛАК КИТАБЫ

# ТАЛАК КИТАБЫ

**Талак** — ул тулы яки өлешчә никах җепләрен өзү.

<table>
<tr><th colspan="4">Талак төрләре:</th></tr>
<tr><th colspan="2">1.Шушыларны истә күздә тотып сөннәт буенча талак:</th><th colspan="2">2.Шушыларны күздә тотып бидгать булган талак:</th></tr>
<tr><td>Халәтләре:<br>Җенси якынлык кылынмаган госел коенганнан соң булган чисталыкта</td><td>Талакларның саны:<br>Бары бер генә талак</td><td>Халәтләре:<br>Хәез вакытында яки җенси якынлык кылынып госелләнгәннән соңбулган вакыт</td><td>Талакларның саны:<br>Бер тапкырга бердән дә артыграк талак</td></tr>
</table>

**Искәрмә:** талак мәсьәләләре белән фәтвә бирүче галимнәргә яки шәригать судына мөрәҗәгать итәргә кирәк.

<table>
<tr><th colspan="3">Талак бирүче кешенең ачуы өч дәрәҗәдә була:</th></tr>
<tr><th colspan="2">Бер фикердә</th><td rowspan="2">Талак хакында фикер каршылыклары булу, талак бирүче кеше әле телгә алынган халәтләрнең уртасында булса, кеше үзенең ни әйткәнен аңлый, әмма ачуы өстенлек ала.</td></tr>
<tr><td>Әгәр ачу башында бирелсә, талак дөрес була, кеше сүзләр әйтә һәм үз-үзен контрольдә тотарга сәләтле.</td><td>Талак дөрес түгел, әгәр талак аффект халәтендә бирелсә, кеше үзенең ни әйткәнен аңламый.</td></tr>
</table>

Талакның нигезенә Аллаһ Тәгаләнең сүзләре яткан: **«Әй Пәйгамбәр! Хатыннарыгызга талак биргән вакытта, билгеләнгән вакыт дәвамында аерылышыгыз».** Билгеләнгән вакыт дәвамында аерылышу хәез вакытында хатынына талак биргән Ибн Гомәр хәдисендә аңлатыла. Гомәр, Аллаһ аннан риза булсын, бу хакта Аллаһның илчесеннән ﷺ сорады, һәм ул җавап бирде: ***«Аңа хатынын кире кайтарырга һәм әлеге хәездән чистарынганчы, шуннан соң икенче хәездән дә чистарынганчы үз янында тотарга боерды. «Аңа хатынын кире кайтарырга һәм әлеге хәездән чистарынганчы,***

***шуннан соң икенче хәездән дә чистарынганчы үз янында тотарга боерды. Шуннан соң, әгәр теләсә, үз янында калдырсын яки аңарга кагылганчы талак бирсен. Аллаһ Тәгалә талакны әнә шундый вакыт аралыгында бирергә кушты».*** Килешенгән хәдис. Ә башка бер версиясендә: ***«Аңа хатынын кире кайтарырга боер, шуннан соң чиста яки авырлы вакытында талак бир».***

***«Аларны йортларыгыздан куып чыгармагыз, һәм алар да йортларыгыздан чыкмасыннар, әгәр алар ачыктан-ачык әшәке гамәлләр кылмасалар гына».***

Бу хәездән соң чистарынган вакытта яки җенси якынлык кылынган чиста вакытта талак бирергә ярамый дигәнне аңлата, әгәр хатын-кыз авырлы булмаса гына.

[әгәр талак бәләгатькә ирешкән, гакыллы, сайлап алу мөмкинлеге булган һәм эшләргә сәләтле булган ир тарафыннан] талакка ишарәләүче төрле сүзләр белән бирелгән булса, ул дөрес була:

| | |
|---|---|
| 1.Мәгънәсеннән талак аңлашыла торган аерым ачык сүзләр. | 2.Ишарә, әгәр ир шул рәвешле талак бирергә ниятләгән булса, һәм эш-хәл нәкъменә талакка күрсәткән булса. |

Талак дөрес:

| | |
|---|---|
| 1.Инде булган факт буларак | 2.Яки шарт белән бәйле рәвештә: мәсәлән: Шундый-шундый вакыт җитүгә син миннән аерылган булачаксың» — дигән сүзләр белән, һәм ошбу шартлар үтәлгәннән соң талак дөрес булачак. |

| Талакны шартлар белән бәйләүнең берничә хөкеме бар: | | |
|---|---|---|
| 1.Бары тик шарт кына: һәр төрле очракта да талак дөрес. Мәсәлән: *«Кояш баегач, син миннән аерылачаксың»*,— сүзләре. | 2.Бары тик ант: ант талакны тормышка ашырмый, әмма аның өчен түләргә кирәк. Мәсәлән: *«Әгәр мин Зәйд белән сөйләшә башласам, мин хатынымнан аерылам»*,— сүзләре Зәйд белән сөйләшүдән тыелуны аңлата. Бу ант булып санала, чөнки Зәйд белән сөйләшмәү һәм хатын белән аерылу арасында бернинди дә бәйләнеш юк. | 3.Ике пунктның да булу мөмкинлеге: бу очракта талак бирүченең ниятен белергә кирәк. |

## [ТУЛЫ ҺӘМ ӨЛЕШЧӘ (КАЙТАРЫП БУЛА ТОРГАН) ТАЛАК]

Ирекле кеше өч талакка хокуклы.

Әгәр талакларның өчесе дә бирелгән булса, хатын-кыз бу ир кешегә харам була, янәдән кияүгә чыгып чын никах килешүе төзеп, ире белән якынлык кылганчыга кадәр. Аллаһ Тәгалә әйтте: «Талак ике тапкыр гына бирелә ала» дан алып «Әгәр ул аның белән өченче тапкыр аерылышса, әлеге хатын башка кешегә кияүгә чыкканчыга кадәр аңарга өйләнү рөхсәт ителми» сүзләренә кадәр.

Тулы талак 4 очракта була:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1.Әле генә телгә алынган ситуация — 1нче очрак | 2.Әгәр талак җенси якынлыкка кадәр бирелгән булса. Аллаһ Тәгалә әйтте: «Әй иман китергән бәндәләр! Әгәр сез иманлы хатын-кызлар белән никах кылсагыз, ә соңыннан, аларга кагылганчыга кадәр, талак бирсәгез, алар сезнең каршыгызда идда вакытын көтәргә бурычлы түгел». | 3.Әгәр ул дөрес булмаган никахта бирелсә. | 4. Әгәр ул йолым бәрабәренә бирелгән булса. |

**Өлешчә (кире кайтарыла торган) талак вакытында хатын-кыз хатын статусын саклый, бары төннәрне бүлү мәсьәләсеннән тыш.**

Шәригать никах, талак турында, кире кайту хакында халыкка белгертергә һәм шаһитларны чакырырга боера, чөнки Аллаһ Тәгалә әйтте: **«Арагыздан ике гадел мөселманны шаһит итеп чакырыгыз».**

Хәдистә хәбәр бирелә: ***«Өч әйбер, аларны җитди итеп әйтсәләр дә, шаярып әйтсәләр дә, җитди кабул ителә. Болар — никах, талак һәм аерылган хатынның кире кайтуы».*** Хәдисне Нәсаидән кала 4 имам китерә. [Туры талак дөрес, ул чынлап әйтелсә дә, шаярып кына әйтелсә дә].

Пәйгамбәргә барып тоташучы Ибн Габбас хәдисендә хәбәр ителә: ***«Аллаһ минем өммәтемә хаталарны, онытылуларны, көчләп кылдырган гөнаһларны кичерә».*** Ибн Мәҗҗә. [Көчләп һәм кеше нәрсә әйткәнен аңламаган нык ярсу вакытында талак дөрес түгел].

## ӘЛ-ИЛЯЪ,
## ӘЗ-ЗЫХАР ҺӘМӘЛ-ЛИГАН

[Әл-иляъ Исламда тыелган].

**Әл-иляъ** — ул ирнең хатын белән бөтенләй яки 4 айдан да артык вакытка якынлык кылмау турында Аллаһ белән ант итүе.

Әгәр хатын үзенең хокукларын үтәлүен һәм якынлыкны таләп итсә, иргә әлеге бурычны үтәргә боералар һәм 4 ай вакыт бирәләр:

| | |
|---|---|
| 1.Әгәр ул җенси якынлык кылса, үзенең анты өчен түләргә тиеш. | 2.Әгәр баш тартса, аңа аерылышырга боералар. |

Аллаһ Тәгалә әйтте: **«Үзләренең хатыннары белән якынлык кылмаска ант иткән ирләр дүрт ай көтәргә тиешләр. Әгәр алар кире уйласалар, Аллаһ — Кичерүче, Рәхимле». «Әгәр алар аерылышырга карар кылсалар, Аллаһ — Ишетүче, Белүче».**

Әз-зыхар — бу хатынга әйтелгән сүзләр, мәсәлән, *«Син минем өчен әниемнең аркасы кебек»* — яки башка шундый үз хатынына үзен турыдан-туры тыя торган сүзләр. Бу тыелган һәм гөнаһлы гамәл булып тора [әмма бу талак түгел, ә ант, аның өчен түләргә кирәк].

Мондый сүзләр аркасында хатын тыелганга әверелми, әмма иргә Аллаһның кушканнарын үтәмичә торып, аңа якын килергә тыела: **«Үз хатыннарын үзләренә тыелган итеп игълан итәләр, ә соңыннан әйтелгәннәреннән кире кайталар,»** аятьнең ахырына кадәр.

| | | |
|---|---|---|
| 1.Мондый кешегә эш эшләргә комачау итүче кимчелекләре булмаган иманлы колны азат итәргә кирәк. | 2.Әгәр ул булмаса, ике ай рәттән ураза тотарга тиешле. | 3.Әгәр алай булдыра алмаса, 60 фәкыйрьне ашатырга. |

Зыхарның гади яки билгеле бер вакыт белән чикләнгән булуында, мәсәлән, Рамазан ае, аерма юк.

Үзеңә үзең җарияләрне, ризык, кием яки башка берәр нәрсәне тыюга килгәндә, аның өчен антны бозган өчен түләргә кирәк. Аллаһ Тәгалә әйтте: «Әй иман китергән бәндәләр! Аллаһ сезгә рөхсәт ителгән нигъмәтләрне тыймагыз» — һәм шушындый гамәлләр өчен түләргә кирәклеген телгә алды.

**Лиган**

Бу хатынны зина кылуда гаепләү процессы. Хатынын зинада гаепләгән иргә карата 80 тапкыр камчы белән суктыру җәзасы кулланыла, әгәр ул:

| | |
|---|---|
| Дәлилләр китермәсә: 4 иманлы шаһит, алар барында хатынга карата җәза кулланыла. | Үзенә ләгънәт чакырмаса, мондый очракта яла яккан өчен җәза кулланылмый. |

Үзеңә ләгънәтне Аллаһ «Нур» сүрәсендә телгә алган рәвештә чакырырга кирәк: **«үз хатыннарын гаепләүчеләр...»** аятьнең ахырына кадәр.

| | |
|---|---|
| 1.Ир хатынының зиначы булуын дәлилләп, Аллаһ исеме белән 5 шәһәдәт әйтә, 5нче шәһәдәттән соң ошбу сүзләрне әйтә: *«Мин ялган сөйләсәм, Аллаһның ләгънәте төшсен миңа».* | 2.Хатын аның ялганчы булуын дәлилләп, Аллаһ исеме белән 5 шәһәдәт әйтә, һәм 5нчесендә: *«Әгәр ирем дөресен сөйләсә, миңа Аллаһның ачуы төшсен»,* — ди. |

Лиганадан соң:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. Ирнең җәзасы гамәлдән чыгарыла. | 2.Хатынга карата да гаепләүләр төшерелә. | 3.Ир белән хатын аерыла һәм бер-берләренә мәңгелеккә харам булалар. | 4.Әгәр ли’анда бала хакында телгә алынса, ир кеше тумаган баланың әтисе булуын кире кага |

**Мөһим хөкемнәр:**

Аллаһ Тәгалә әйтте: **«Әй сез, иман китергән бәндәләр! Күп фаразлардан качыгыз, чөнки кайбер фаразлар гөнаһ булалар».** Әбу Хурайра, Аллаһ аннан риза булсын, сүзләреннән китерелә: Аллаһның илчесе ﷺ әйтте: ***«Фаразлардан сак булыгыз, хакыйкатьтә фаразлар — иң ялган сүзләр».*** Килешенгән хәдис.

Аллаһ Тәгалә әйтте: **«Әй иман китергән бәндәләр! Берләрегез икенчеләрегездән көлмәгез, чөнки алар сездән яхшырак булырга мөмкин. Һәм бер хатыннар икенче хатыннардан мыскыл итеп көлмәсеннәр, чөнки бәлки тегеләре боларына караганда яхшырактыр. Үз-үзегезне (бер-берегезне) кыерсытмагыз һәм бер-берегезне рәнҗетә торган кушаматлар белән атамагыз. Иман китергәннән соң имансыз дип аталу бик яман. Ә кемнәр тәүбә итмәде, гөнаһлы булырлар».**

Аллаһ Тәгалә шулай ук әйтте: **«Һәрбер хурлаучы һәм кыерсытучы кешегә кайгы».**

Әбу Хурайра, Аллаһ аннан риза булсын, сүзләреннән китерелә: Аллаһның илчесе ﷺ әйтте: ***«Әгәр кеше үзенең мөселман кардәшенә нәфрәтләнсә, аннан явызлык җитәрлек».*** Мөслим

# ТАЛАКТАН СОҢ ЯКИ ИРНЕҢ ҮЛЕМЕННӘН СОҢ КӨТҮ ВАКЫТЫ

## ТАЛАКТАН СОҢ ЯКИ ИРНЕҢ ҮЛЕМЕННӘН СОҢ КӨТҮ ВАКЫТЫ (ГИДДА) ҺӘМ КОЛ ХАТЫННЫҢ КӨТҮ ВАКЫТЫ (ИСТИБРА)

<table>
<tr><td colspan="3">Гидда — ир белән, талак яки үлеме сәбәпле, аерылышканнан соң көтү вакыты.</td></tr>
<tr><th colspan="3">Гидда мәҗбүри булган аерылышу төрләре:</th></tr>
<tr><td rowspan="2">1.Үлем сәбәпле аерылышу</td><td colspan="2">2.Исән вакытта талак юлы белән аерылышу. Мондый очракта хатынның 2 халәте бар:</td></tr>
<tr><td>А.Җенси якынлыктан соң талак</td><td>Б.Җенси якынлык кылынмыйча талак кылыну.</td></tr>
</table>

<table>
<tr><th colspan="5">1.Үлем сәбәпле аерылышу</th></tr>
<tr><td colspan="2">Әгәр ир вафат булса, нинди генә очракта да идда вакытын көтәргә кирәк.</td><td colspan="3">Үлем сәбәпле гидда вакытын көткәндә хатын-кыз траурда булырга тиеш:</td></tr>
<tr><td rowspan="3">А. Авырлы хатын-кызның гиддасы — аның карынында булган барлык яралгыларның да тууы, чөнки Аллаһ Тәгалә әйтте: «Авырлы хатын-кызларга көтү вакыты бала тудырганчыга кадәр билгеләнгән».<br>Бу үлем сәбәпле аерылышуга да, исән вакытта аерылышуга да кагыла.</td><td rowspan="3">Б. Әгәр хатын-кыз авырлы булмаса, аның гидда вакыты 4 ай һәм 10 көн тәшкил итә.</td><td colspan="2">А. Баш тартып:</td><td rowspan="3">Б. Үзе яшәгән һәм ире вафат булган йортта калып. Бары якты вакытта һәм кирәк өчен генә өйдән чыгарга рөхсәт ителә, чөнки Аллаһ Тәгалә әйтте: «Әгәр сезнең арагыздан кемдер вафат булса һәм үзеннән соң хатыннар калдырса, ул вакытта алар дүрт ай һәм ун көн көтәргә тиешләр».</td></tr>
<tr><td>Ясану-бизәнүдән</td><td>Ислемайлардан</td></tr>
<tr><td>Бизәнгеч әйберләрдән.</td><td>Хна тидерүдән һәм башкалар.</td></tr>
</table>

<table>
<tr><th colspan="7">2.Исән вакытта аерылышу:</th></tr>
<tr><td rowspan="3">А. Әгәр талак җенси якынлык кылганчы бирелгән булса, хатын-кыз гидда вакытын көтәргә бурычлы түгел, чөнки Аллаһ Тәгалә әйтте: «Әй иман китергән бәндәләр! Әгәр сез иманлы хатын-кызлар белән никах кылсагыз, ә соңыннан, аларга кагылганчыга кадәр, талак бирсәгез, алар сезнең каршыгызда идда вакытын көтәргә бурычлы түгел».</td><td colspan="6">Б. Әмма ләкин җенси якынлык булган булса:</td></tr>
<tr><td rowspan="2">1.һәм әгәр хатын-кыз авырлы булган булса, гидда вакыты, әлеге вакытның ни кадәр озын булуына карамастан, бала туу белән төгәлләнә.</td><td colspan="5">Әгәр ул авырлы булмаса:</td></tr>
<tr><td>2.һәм аның хәезе булса, аның гидда вакыты тулы өч цикл, чөнки Аллаһ Тәгалә әйтте: «Аерылган хатын-кызлар өч хәез вакыты көтәргә тиешләр.»</td><td>3.Әгәр аның хәезләре булмаса яки ул хәезләре булмый торган кыз икән, аларның гидда вакытлары 3 ай тәшкил итә. Аллаһ Тәгалә әйтте: «Хәезләре тукталган хатын-кызлар һәм әле хәезләре булмаган кызлар өчен, әгәр сез шикләнсәгез, талак өчен билгеләнгән көтү вакыты 3 айга тигез».</td><td>4.Әгәр аның хәезләре булса, әмма алар вакытлыча туктап торсалар, мәсәлән, күкрәк сөте ашатканда, бу очракта хатын-кызга хәез вакытын көтәргә һәм гидда вакытын көтәргә кирәк.</td><td>5.Әгәр хәез билгесез сәбәпләр аркасында тукталса, бу очракта, хатын-кызның авырлымы юкмы икәнлеген төгәл билгеләү өчен, 9 ай көтәргә кирәк, шуннан соң өч ай гидда вакытын көтәргә кирәк.</td><td>6.Әгәр хәез буенча гидда вакыты үткәч хатын-кызда авырга узу билгеләре күзәтелсә, шикләр бетерелгәнчегә кадәр кияүгә чыгарга ярамый.</td></tr>
</table>

Хәбәрсез югалган кешенең хатыны судья тарафыннан иренең вафаты турындагы карар чыгарылганны көтәргә тиеш, шуннан соң гидда вакыты көтелә.

Тәэмин итәргә кирәк бары:

| | |
|---|---|
| 1.Өлешчә (кайтарыла торган) талак әйтелгән хатынны. | 2.Авырлы булган хатын-кыз белән аерылышкан вакытта, чөнки Аллаһ Тәгалә әйтте: **«Әгәр алар авырлы булсалар, бала тапканчыга кадәрле аларны тәэмин итегез».** |

«Әл-истибра» га килгәндә, ул — хуҗасы җенси якынлык кылган кол хатынның көтү вакыты.

Әлеге хуҗадан соң, аның ире яки икенче хуҗасы кол хатын белән җенси якынлык кыла алмыйлар:

| | | |
|---|---|---|
| 1.Кол хатынның бер цикл хәезе үтмичә. | 2.Әгәр аның хәезе булмаса, бер ай көтмичә. | 3.Әгәр ул авырлы булса, бала тапканчыга кадәр. |

## ХАТЫННАРНЫ, ЯКЫН ТУГАННАРНЫ һӘМ КОЛЛАРНЫ ТӘЭМИН ИТҮ, ШУЛАЙ УК ОПЕКА

| Тәэмин итү фарыз булсын өчен шартлар: | | | |
|---|---|---|---|
| 1.Тәэмин итүченең байлыгы җитәрлек булу. | 2.Опекага алынганнарның мохтаҗ булулары. | 3.Бер диндә булулары, яклауга алудан тыш. | 4.Тәэмин итүче опекага алынучының варисы — ягъни мирастан өлеш, соңгы өлешне алучы яки туганы булуы. |

Ир кеше үзенең хатынын лаеклы дәрәҗәдә тәэмин итәргә, мөмкинлекләреннән чыгып аны киендерергә, яшәү урыны бирергә тиеш, чөнки Аллаһ Тәгалә әйтте: **«Байлыгы булган кеше үзенең байлыгына муафыйк рәвештә акчасын таратсын. Акчалары булмаган кешеләр, Аллаһ биргән нигъмәтләрне таратсын. Аллаһ кеше өстенә Үзе бүләк иткәннән дә күбрәк нәрсә йөкләми».** Әгәр хатыны моны таләп итсә, аны бу бурычын үтәргәмәҗбүр итәләр.

Мөслим китергән Җәбир хәдисендә хәбәр ителә: ***«Кабул ителгән гадәтләр буенча сез аларны ашатырга һәм киендерергә тиешсез».***

Ир кеше шулай ук тиеш:

| | |
|---|---|
| 1.Әгәр ул бай кеше булса, байлыгы булмаган балаларын һәм әти-әнисен тәэмин итәргә тиеш. | 2.Шулай ук мирасын алучы кешеләрне, мирасның бер өлешен аламы яки калган өлешне аламы, тәэмин итәргә тиеш. |

Хәдистә әйтелә: ***«Колны ризык һәм кием белән тәэмин итәргә һәм аның өстенә үти алмаслык эшне йөкләмәскә кирәк».*** Мөслим. Әгәр ул өйләндерүен сораса, хуҗа кеше аны өйләндерергә тиеш.

| | |
|---|---|
| 1.Үзенең мал-туарын ризык һәм су белән тәэмин итәргә. | 2.Аларга зыян салучы эшне йөкләмәскә. |

Хәдистә әйтелә: ***«Ашатырга тиешле кешеләрен һәлак иткән кешегә шул гөнаһ та җитә».*** Мөслим.

Опека – ул баланы аңа зыян салучы нәрсәләрдән саклау һәм аның интересларында гамәл кылу. Тәэмин итү фарыз булган кешегә опекага алу бурыч булып тора. Әмма:

<table>
<tr><td rowspan="2">1.Әни кешенең улына яки кызына хаклары күбрәк, әгәр аларга 7 яшьтән кимрәк булса</td><td colspan="2">2.Әгәр балага 7 яки аннан да күбрәк яшь икән:</td></tr>
<tr><td>А. Малай кешегә әти-әнисе арасында сайларга рөхсәт бирәләр, һәм ул кемне сайлады, шуның белән кала.</td><td>Б. Кыз бала, кем аңа файданы күбрәк китерә (әтиме яки әниме), шуның белән кала.</td></tr>
</table>

Тәрбиягә алынган кешене аны сакламаган һәм файда китерә алмаган кеше белән калдырмыйлар.

## ГАИЛӘ КИТАБЫ БУЕНЧА СОРАУЛАР

| Сорау | Дөрес | Дөрес түгел |
|---|---|---|
| — Никах — ул пәйгамбәрләрнең гореф-гадәте. | | |
| — Никах — ул сәламәтлек һәм чисталыкның нигезе. | | |
| — Әгәр ир-ат хатын-кызга яучыларга теләсә, ул аңарга, өйләнергә теләге тусын өчен карый ала. | | |
| — Мөселманга башка мөселманның яучылыгына каршы төшәргә рөхсәт ителгән. | | |
| — Безнең заман яшьләренә никах ирекле хаҗга караганда яхшырак. | | |
| — Балаларның санын чикләү — ислам өммәтенең югары дәрәҗәгә күтәрелүенең бер билгесе. | | |
| — Акыллы хатын-кызга үз-үзен кияүгә бирергә рөхсәт ителә. | | |
| — Исламның дәрәҗәсе күтәрелә, әмма беркем дә аннан югарыга күтәрелә алмый. | | |
| — Йөкле булу — аерылышырга тыелган ситуация. | | |
| — Әгәр ир хатыны белән якынлык кылганчы аерылышса, ул очракта хатын-кыз гидда вакытын көтми. | | |
| — Әгәр ир хәбәрсез югалса, шуннан соң хатыны аның үлеме турында белсә, аңа гидда вакытын ул югалган көннән санарга кирәк. | | |
| — Тәэмин итүче тәэмин ителүчеләрнең варисы: мирас өлешен алучы, калган өлешне алучы яки туганы булырга тиеш, әмма нәселнең нигезе булырга тиеш түгел. Алар варис булырга тиеш түгелләр. | | |
| — Әни кешенең балаларын опекага алырга өстенлекләре күбрәк. | | |
| — Никах вакытында рөхсәт ителү турында килешү төзү җитә. | | |
| — Хәез вакытында аерылышу тыелган. | | |

| | | |
|---|---|---|
| — Нигездә талак кире кайтарыла.<br>— Хатынның кире кайту шарты булып бу гамәлне идда вакытында эшләү тора.<br>— Шәригатьтә иляъ (ант) вакыты — 2 ай.<br>— Әз-зыхарның хөкеме (әни белән чагыштыру) — тыелган.<br>— Тулы талак мисалы — кече аерылышу: җенси якынлыкка кадәр талак.<br>— Ир белән хатынның һәр төр аерылышуы вакытында да гидда вакыты үтәлә. | | |

— Күзләрне һәм җенес әгъзасын гөнаһтан саклауның иң яхшы юлы: өйләнү___, хаҗ кылу___, ураза тоту___.

— Хатын итеп сайларга кирәк: динле ___, нәселе яхшы булганны___, яратучы___, бала табучы___, бөтен саналганнар да___.

— Тулы талак алган хатын-кызга өйләнергә ниятең барлыгына ишарә ясау: рөхсәт ителгән___, рөхсәт ителмәгән___.

— «Тәкъдим» — ул: опекун___, ир һәм аның вәкиленең____сүзләре.

— Гидда вакытын көтүче хатын-кызга ачыктан ачык тәкъдим ясау: тыелган___, кирәкмәгән эш___, рөхсәт ителгән___.

— Никах вакытында шаһитлар чакыру: кирәк___, фарыз___, рөхсәт ителә___.

— Гыйффәтле кызны аңа ошамаган иргә кияүгә мәҗбүриләп бирү: рөхсәт ителә___, рөхсәт ителми___, мәҗбүри___.

— Шәригатьнең әшәкелеккә алып баручы барлык чараларны кисәтүе: аерым ачык___, яшерен____.

— Ислам: хатын-кызның хокукларын яклый___, якламый___.

— Хәйләләр тыелганны: рөхсәт итә__, рөхсәт итми__.

— Ир-ат хатын-кызга 30.000 сум. никах бүләге бирде, әмма хатынның инициативасы (хульг) белән аннан аерылышты, хатын-кыз аңа 40.000сум түләде: рөхсәт ителә___, рөхсәт ителми____.

— Ният булу шарт булып тормаган талак: турыдан-туры___, турыдан-туры түгел___.

— Ниятсез дөрес булмаган талакка мисал: үз туганнарыңа бар__, син аерылган__.

— Ир хатынына аны куркыту нияте белән: *«Син аерылдың»*,— диде: талак дөрес___, дөрес түгел___.

— Әз-зыхар өчен түләү эшләнә: тәртип белән___, сайлап алып___.

— Әгәр ир хатынына: *«Син минем өчен тыелган»*,— дисә, бу: зыхар___, кире кайтарыла торган талак___, тулы талак___.

— Кем зыхар өчен түләүне үтәгәнчегә кадәр җенси якынлык кылса: ул гөнаһ кылды___, әгәр алга таба түләсә, аның өстендә гөнаһ юк___.

— Сөннәткә муафыйк рәвештә яки муафыйк булмаган рәвештә талак бүленә: сөннәт буенча талак___, бидгать___, барлык санап үтелгәннәр___.

— Нәрсә сөйләгәне һәм нәрсә эшләгәнен бөтенләй аңышмаган кешенең талагы: дөрес___, дөрес түгел___.

— Заманча аралашу чараларын кулланып барлык шартларын һәм әркәннәрен үтәп шаяруларсыз никах килешүе төзү: дөрес___, дөрес түгел____.

— Опекага алган хатын-кыздан, аның милеген тартып алу максаты белән котылу: бик авыр гөнаһ___, рөхсәт ителә___, тиеш түгел____.

— Шушы категория кешеләргә өйләнергә вакытлыча тыела: берьюлы апасына да, сеңлесенә дә___, 4 тән дә артыграк хатынга___, гидда вакытын көтүче хатын-кызга ___, көтү вакытында булган кол хатынга___, өч талактан соң үзенең элеккеге хатынына___, олы хаҗ яки гомрә үтәүче хатын-кызга___, имансыз кешегә мөселман хатын-кызына___, мөселман иргә имансыз хатын-кызга___, барлык саналганнар да___.

— Никах белән бәйле шартларның төрләре: шартлар дөрес була___, дөрес түгел___, тегесе дә, монысы да___.

— Әлеге шартларның кайсылары дөрес булмаган шартлар: «шигар» никахы__, элеккеге ир белән хатынны бер-берсенә хәләл итү өчен булган никах ___, вакытлыча никах____, мутга___, аерылышу нияте белән никахлашу___.

— Ирләрнең хокуклары: гомуми___, хатыныныкы гына булучы хокуклар___, ирнеке генә булучы хокуклар___, барлык саналганнар да____.

# РИЗЫК КИТАБЫ

# РИЗЫК КИТАБЫ

**Ризык белән бәйле гомуми кагыйдәләр:**

1.Нигездә бөтен ризык та рөхсәт ителгән.

2.Сәламәтлеккә зыян салмаучы һәртөрле чиста ризык рөхсәт ителгән.

3.Җирдә булган нәрсәләр: ризык, эчемлекләр, файдалы кием, безгә рөхсәт ителгән.

4.Нигездә ризык бары тик иманлы кешеләргә генә рөхсәт ителгән, калган кешеләргә юк.

5.Һәртөрле пычрак тыелган, әмма бөтен тыелган әйбер дә пычрак түгел.

6.Бөтен диңгез хайваннары да рөхсәт ителгән.

7.Бөек Хаким үтерергә тыйган яки боерган нәрсәләрне ризык итеп куллануырга тыела.

**Ризык кабул итү этикасы:**

— Пәйгамбәр ﷺ әйтте: ***«Әй малай! Аллаһның исемен телгә ал, уң кулын белән аша һәм үзеңә якын ятканны гына ал».*** Килешенгән хәдис.

— «Ризыкны алып киткән вакытта, Аллаһның илчесе ﷺ әйтә иде: ***«Күп тапкырлар Аллаһка мактау, Раббыбызга изге, мөбарәк һәм даими мактаулар, алардан башка без булдыра алмыйбыз».*** Бохари.

— Пәйгамбәр ﷺ әйтте: ***«Мин нәрсәгә дә булса таянып торып ашамыйм».*** Бохари.

— ***«Аллаһның илчесе ﷺ беркайчан да ризыктан гаеп тапмады. Әгәр ул аңа ошаса, ул ашады, әгәр ошамаса, калдыра иде».*** Килешенгән хәдис.

**— *«Аллаһның илчесе ﷺ өч бармагы белән ашый һәм ашап туйгач, аларны ялый иде».*** Мөслим.

— Аллаһның илчесе ﷺ бармакларны яларга һәм савыт-сабаны чистартып калдырырга кушты һәм әйтте: ***«Хакыйкатьтә, сез ризыгыгызның кайсы өлешендә сезгә бәрәкәт барлыгын белмисез».*** Мөслим.

Ризык ике төрле була: хайваннардан алынган һәм башка:

<table>
<tr><th colspan="2">Хайваннардан алынмаган булган ризык:</th></tr>
<tr><td>А. Бөртеклеләр, җиләк-җимешләр һәм башкалар – барысы да рөхсәт ителгән, зыян салучы нәрсәләрдән тыш, мәсәлән, агу</td><td>Б. Исерткеч эчемлекләрдән кала барлык эчемлекләр дә рөхсәт ителгән. Андый эчемлекләр аз күләмдә дә, күп күләмдә дә тыелган, чөнки хәдистә хәбәр ителә: «Барлык исерткечләр тыелган, әгәр нәрсәнең дә булса бер фарак күләмендәге өлеше исертсә, аның бер уч күләмендәге өлеше дә тыелган». [Әбу Давыд].<br><br>Әгәр шәраб уксуска әверелгән булса, ул рөхсәт ителгән.</td></tr>
</table>

<table>
<tr><td rowspan="8">Хайваннардан алынган ризыклар ике төрле була:</td><td colspan="2">А. Диңгез. Диңгездәге барлык тере һәм тере булмаган нәрсәләрне ризык итеп кулланырга рөхсәт ителгән, чөнки Аллаһ әйтте: «Сезгә диңгездә тотылган һәр нәрсә һәм ризыклар рөхсәт ителгән», агулы һәм пычрак хайваннардан һәм җирәнү тудырган хайваннардан тыш, мәсәлән, бака.</td></tr>
<tr><td rowspan="7">Б. Коры җирдә. Нигездә коры җирдәге бөтен ризык рөхсәт ителгән [мал, атлар, кәлтәләр, зебра, кролик, гиеналар, антилопа, страуслар, тавык һәм саранча], Бөек Хаким тыйган нәрсәләрдән тыш бар нәрсә дә:</td><td>1. Ибн Габбас хәдисендә хәбәр ителә: «Казык тешләре булган һәртөрле ерткыч хайванның итен куллану тыела». [Мөслим. Боларга керә: фил, эт, дуңгыз, маймыл, песи, аю].</td></tr>
<tr><td>2.«...һәм тырнаклары булган һәртөр кошларның итен». Мөслим. [ягъни: лачын, тилгән, ябалак һәм башкалар].</td></tr>
<tr><td>3.«Һәм йорт ишәкләренең итләрен куллану тыелган». Килешенгән хәдис.</td></tr>
<tr><td>4.«4 нәрсәне үтерү тыелган: кырмыска, бал корты, кырыгаяк һәм һөдһөдне». Әхмәд һәм Әбу Давыд. [Кагыйдә: изге китаплар тарафыннан үтерергә тыелган яки рөхсәт ителгән хайваннарны ризык итеп куллану тыелган].</td></tr>
<tr><td>5.«Бөтен яман нәрсәләрне ризык итеп куллану тыелган, мәсәлән, бөҗәкләр», — [һәм үләксә белән тукланучы хайваннар, мәсәлән, ләкләк, каргаһәм башкалар].</td></tr>
<tr><td>6.«Пәйгамбәр ﷺ пычрак нәрсәләр белән тукланучы хайванның итен һәм сөтен ризыкка кулланудан тыйды, аны туктатканчыга һәм өч тапкыр чиста ризык ашатканчыга кадәр». [Биредә сүз күп очракта пычраклар ашаучы хайваннар турында бара].</td></tr>
<tr><td>7.Шулай ук ите ризык итеп кулланылган хайванның да, ите ризык итеп кулланылмаган хайванның да балаларын, мәсәлән, качыр.</td></tr>
</table>

## [КЫСКАЧА: ДӘВАЛАУ]

Дәвалау турында кайбер хәдисләр:

— Пәйгамбәр ﷺ әйтте: ***«Өч нәрсә шифа бирә: бер йотым бал, банкалар куллануһәм кызган тимер белән бастыру, әмма мин үз өммәтемә кызган тимер бастыруны тыям».*** Бохари.

— Гайшә, Аллаһ аннан риза булсын, сүзләреннән китерелә: Пәйгамбәр ﷺ: ***«Кара тмин «саам»нан кала бөтен авырудан да дәва».*** *Шунда кемдер сорады: «Ә нәрсә ул «саам»?» Пәйгамбәр ﷺ җавап бирде:* ***«үлем»».*** Бохари.

— Ул әйтте: ***«Тальбина авыруның йөрәген тынычландыра һәм аның сагышының бер өлешен алып китә».*** Килешенгән хәдис. «Тальбина» — сөткә арпа оны яки көрпә салып пешерелгән аш. Әлеге ашка сөт белән охшашлыгы аркасында шундый исем биргәннәр.

— Ул әйтте: ***«Сезгә әлеге һинд кыстын кулланырга кирәк, чөнки ул җиде авырудан дәва булып тора, шул исәптән тамак ялкынсынуыннан да, һәм плевриттан да».*** Килешенгән хәдис.

— Ул әйтте: ***«Сез дәвалана торган иң яхшы нәрсәләр — хиджама һәм кыст әл-бәхри».*** Килешенгән хәдис.

— Ул әйтте: ***«Манныйдан трюфель(яки: манныйга охшаган), ә аның согы — күзгә дәва».*** Килешенгән хәдис.

— Ул әйтте: ***«Бизгәк — Җәһәннәм утыннан, аны су белән суытыгыз».*** Килешенгән хәдис.

— Ул әйтте: ***«Әгәр сез бер илдә чума авыруы барлыгын ишетсәгез, ул илгә кермәгез, әгәр чума сез яшәгән илдә кабынып китсә, ул илдән чыкмагыз».*** Килешенгән хәдис.

— Ул әйтте: ***«Кем иртән [ач карынга] җиде штук әджвә ашаса, ул көнне һәм төнне аңа агу да, сихер дә зыян сала алмас».*** Килешенгән хәдис.

Өшкерү (рукъя) хакында риываятьләр:

— Әбу Сагид әл-Худри, Аллаһ аннан риза булсын, бер халыкның аксакалын өшкерде, аны елан чаккан иде. Ул, авыруга төкеренеп, «әл-фатиха» сүрәсен укыды, һәм авыру сәламәтләнде. Әлеге гамәле өчен рәхмәт йөзеннән кешеләр аңа бүләк итеп бер көтү сарык бирделәр. Бу хакта белгәч, Пәйгамбәр ﷺ әйтте: ***«Әлеге сүрәнең рукъя икәнлеген сез каян белдегез? Сез бик яхшы эшләгәнсез. Миңа да үзегез белән өлеш чыгарыгыз!»*** Килешенгән хәдис.

— Гайшә, Аллаһ аннан риза булсын, сүзләреннән килә: ***«Аллаһның рәсүле ﷺ кәеф китүен (яки авыруын) сизсә, ул үз өстендә ике сүрә укый иде («әл-Фәләкъ» һәм «ән-Нәс») һәм үзенә сулышын өрә иде. Ә бик каты авырту сизгән вакытта, бу сүрәләрне аның өстендә мин укый идем, аның кулын алып, хәер-фатиха өмет итеп, тәне өстеннән йөртә идем».*** Килешенгән хәдис.

— Гайшә шулай ук әйтте: ***«Пәйгамбәр ﷺ йокларга ятарга теләгән вакытта, уч төпләренә өреп Коръәннең соңгы өч аятен укый иде һәм шуннан соң куллары белән тәнен сыпыра иде».*** Бохари.

— Ул шулай ук хәбәр итте: ***«Аллаһның илчесе ﷺ үз-үземә күз тигәннән укырга боера иде».*** Килешенгән хәдис.

— Ул шулай ук хәбәр итте: ***«Пәйгамбәр ﷺ һәртөрле агулы хайваннарның тешләвеннән, чагуыннан укып өшкерергә рөхсәт бирде».*** Килешенгән хәдис.

— Пәйгамбәр ﷺ ошбу сүзләр белән өшкерде:

اللَّهُمَّ رَبَّ النَّاسِ ، مُذْهِبَ البَأْسِ ، اشْفِ أَنْتَ الشَّافِي ، لاَ شَافِيَ إِلاَّ أَنْتَ ، شِفَاءً لاَ يُغَادِرُ سَقَماً

***«Йә Аллаһ, кешеләрнең авыруларын бетерүче Раббысы, шифа бир, Син — Шифа бирүче, Синнән башка шифа бирүче юк, шундый итеп шифа бир, аннан соң авыру калмасын».*** Килешенгән хәдис.

— Шулай ук:

امْسَحِ الباسَ رَبَّ النَّاسِ ، بِيَدِكَ الشِّفاءُ ، لا كاشِفَ لَهُ إِلاَّ أَنْتَ

***«Кешеләрнең Раббысы, әлеге чирне сөрт, Синең кулларыңда шифа, Синнән башка шифаны һичкем бирми».*** Килешенгән хәдис.

— Шулай ук: күрсәтү бармагына төкерергә, аны җиргә тидерергә һәм әлеге тузан белән авырткан урынны яки яраны сөртергә, ул вакытта ошбу сүзләрне әйтергә:

بِسمِ اللّٰهِ، تُرْبَةُ أَرْضِنَا، بِرِيقَةِ بَعْضِنَا، يُشْفَى بِهِ سَقِيمُنَا، بِإِذْنِ رَبِّنَا

***«Аллаһ исеме белән. Безнең җиребезнең тузаны кайсыбызның да булса селәгәе белән бергә, һәм безнең авыру кардәшебез Раббыбызның рәхмәте белән савыгыр».*** Килешенгән хәдис.

## ХАЙВАН ЧАЛУ һӘМ АУ

**Хайван чалу** — малның канын агызырга рөхсәт ителә:

| 1.**Муеннан**, әгәр мөмкин булса: | | 2.**Тәнен яралау юлы белән**, әгәр хайванны чалу мөмкинлеге булмаса. |
|---|---|---|
| А. Өске өлештән чалып (башка якын итеп) | Б. Яки аскы өлештән чалып (гәүдәгә ягын урыннан) | |

Итен ризык итеп кулланырга яраклы хайваннар, бары тик чалганнан соң гына хәләл була, балык һәм саранчадан тыш.

**Чалу шартлары:**

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1.Чалучы кеше мөселман булырга яки гакыллы һәм эшкә яраклы Китап әһеле булырга тиеш | 2.Малны чалганда бик үткен пычак белән чалу шарт | 3.Канын агызу | 4.Бөтен «хулькум»ны (сулыш юлларын) һәм «мариъ» (бугазын) кисәргә. | 5.Чалган вакытта Аллаһның исемен телгә алырга. |

Ау вакытында да шундый ук шартларны үтәргә кирәк, аерма бары тик шунда: хайван тәненең теләсә-кайсы өлешен яраларга мөмкин.

**Ау төрләре:**

| | |
|---|---|
| 1.**Рөхсәт ителгән**: кирәк вакытта һәм ризык итеп куллану максаты белән булган ау. | 2.**Тыелган:** күңел ачу өчен ау. |

Качучы һәм чалырга авыр булган хайваннарның барсы да ау табышы була.

Пәйгамбәргә ﷺ барып тоташучы хәдистә Рафига ибн Хадидж сүзләреннән килә: ***«Әгәр каны агып беткән һәм ул Аллаһ исеме белән теш һәм тырнаклардан тыш үткен нәрсә белән чалынган хайванны ашагыз. Тешләр сөякләргә керә, ә тырнаклар — эфиопиялеләрнең пычаклары***». Килешенгән хәдис.

**Өйрәтелгән этнең табышы рөхсәт ителгән, әгәр ул:**

| | | |
|---|---|---|
| 1.Ауга команда буенча китә. | 2.Команда буенча туктый. | 3.Эләккән табышны ашамый. |

Бу очракта хуҗа, этен ауга җибәреп, «бәсмәлә» сүзләрен әйтергә тиеш.

Гади ибн Хатим сүзләреннән китерелә, Аллаһның илчесе ﷺ әйтте: ***«Әгәр этеңне ауга җибәрсәң, Аллаһның исемен телгә ал:***

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 1.***Әгәр шуннан соң син этеңне куып җитсәң, ә табыш исән булса, аны чалырга кирәк.*** | 2.***Әгәр син аны куып җиткәндә табыш инде үлгән, әмма эт тарафыннан тиелмәгән булса, аны аша.*** | 3.***Әгәр синең этең белән янәшә чит эт тә булса, ә табыш үлгән булса, аны син ашама, чөнки аны кайсы эт үтергәнен белмисең.*** | 4. ***Әгәр син уктан атсаң, Аллаһның исемен телгә ал.*** | 5.***Әгәр шуннан соң син табышыңны көне буенага югалтсаң һәм тапкан вакытта үзеңнең угыңнын эзен генә күрсәң, аны, әгәр теләсәң, аша.*** | 6.***Әгәр ул суда батып үлсә, аны ашама».*** Килешенгән хәдис. |

Ә икенче бер хәдистә болай дип хәбәр ителә: ***«Хакыйкатьтә, Аллаһ безгә бөтен нәрсәне дә яхшы итеп эшләргә боерды һәм әгәр үтерергә туры килсә, үтерүне яхшы ысул белән башкарыгыз, һәм әгәр дә корбан чалырга уйласагыз, бу гамәлне дә яхшы итеп эшләгез, һәм сезнең һәрберегез [тиешле дәрәҗәдә] үзенең пычакларын үткенләсен һәм хайванны газаплanулардан коткарсын».*** Мөслим.

Ул шулай ук әйтте: ***«Чалынган малның яралгысын чалу аның әнисен чалу булып исәпләнә».*** Әхмәд.

## АНТ ҺӘМ НӘЗЕР

**Ант** — ул билгеле бер тәгъбир белән Бөек Аллаһны (яки Аның башка исемен яки атрибутын) телгә алып, нәрсәне дә булса раслау.

**Тәгъбир:** антның бер кисәге ярәмендә (уәу, бә, та, ха яки хәмзә).

**Кагыйдә:** ант әйткән вакытта нияткә таянырга кирәк, шуннан соң мотив, шуннан соң билгеләмә, һәм шуннан соң тагын сүзләр.

Ант Аллаһның исеме яки Аның сыйфаты телгә алынган очракта гына ант раслана.

<table>
<tr><th colspan="3">Антның төрләре:</th></tr>
<tr><td colspan="2">1.Аллаһ исеме белән ант итү:</td><td rowspan="2">2.Аллаһ исеме белән булмаган ант — ул ширек һәм ул раслана алмый.</td></tr>
<tr><td>А. үткәннәр хакында</td><td>Б. киләчәк турында</td></tr>
</table>

<table>
<tr><td colspan="6">Антны бозган өчен йолым кирәк булган ант мондый булырга тиеш:</td></tr>
<tr><td colspan="2">1.Киләчәктә булачак нәрсәләр турында</td><td colspan="2">2.Аллаһ исеме белән</td><td colspan="2">3.Ният белән</td></tr>
<tr><td colspan="6">Әгәр ант үткәннәрдә булган нәрсә белән әйтелсә:</td></tr>
<tr><td colspan="3">1.Шул хакта белеп, кеше ялганлый [Мөселманның милеген тартып алып үзенеке итәр өчен], һәм бу «һәлакәткә илтүче/ялган» ант (әл-гамус).</td><td colspan="3">2.Әгәр кеше үзен дөрес дип санаса, бу очракта ул конкрет максатсыз әйтелә торган «буш/мәгънәсез» ант (лягв) булачак, мәсәлән, «Юк, Аллаһ белән ант итәм», яки «Әйе, Аллаһ белән ант итәм».</td></tr>
</table>

Әгәр ант бозылган булса (аны истә тотып һәм үз иркең белән), мәсәлән, эшләмим дип ант иткән нәрсәне эшләү, яки эшлим дип ант иткән нәрсәне калдыру, бу очракларда кешегә йолым түләү йөкләтелә:

| 1.Сайлап ала: | | | 2.Шуннан соң рәттән: |
|---|---|---|---|
| 1.Колны азат итү | 2.10 фәкыйрьне ашату | 3.Яки аларны киендерү. | Әгәр боларның берсе дә булмаса, 3 көн рәттән ураза тота |

Габдеррахман ибн Самурат сүзләреннән хәбәр ителә, Аллаһның Рәсүле ﷺ әйтте: ***«Әгәр син ант әйтсәң, ә соңыннан башкача эшләү яхшырак икәнен күрсәң, яхшырак булганын эшлә һәм антыңа йолым түлә».*** Килешенгән хәдис.

Башка хәдистә хәбәр ителә: ***«Әгәр кеше нәрсә дә булса эшләргә ант итсә һәм болай дисә: «...әгәр моңа Аллаһның рөхсәте булса»,— әгәр антын бозса да, гөнаһ эшләми».*** Хәдисне биш шәех китерә.

| **Ашату һәм ашатылган кешеләрнең өч хөкеме бар:** | | |
|---|---|---|
| 1.Сәдаканың предметы билгеләнгән, әмма кемгә тиешлеге билгеләнмәгән, мәсәлән, зәкәт әл-фитр. | 2.Сәдаканың предметы һәм аның кемнәргә тиешлеге билгеләнгән, мәсәлән, зыян салган өчен штраф. | 3.Сәдака бирелергә тиешле кешеләр билгеләнгән, әмма предметы билгеләнмәгән, мәсәлән, антны бозган өчен йолым түләү |

Антларда түбәндәгеләргә нигезләнергә кирәк:

| **1.Дәгъва белдергәндә түгел:** | | | **2.Дәгъва белдергәндә:** |
|---|---|---|---|
| 1.Ант итүче кешенең нияте | 2.Ант итәргә этәргән мотив | 3.Ният һәм теләккә күрсәтүче сүзләр | Дәгъва очрагыннан тыш. Хәдистә әйтелә: ***«Антны ант итәргә сораган кешенең ниятенә муафыйк рәвештә бирәләр».*** Мөслим. |

**[Нәзер:]**

Нәзернең телдәге мәгънәсе: мөкәлләф тарафыннан нинди дә булса мәҗбүри булмаган гамәл кылуны үз өстенә алуы.

<table>
<tr><td rowspan="9">Нәзер төрләре:</td><td colspan="4">1.Аллаһ ризалыгы өчен түгел: зур ширек, мәсәлән, Аллаһ исеменнән башка гына сүзләр белән ант итү. Мондый нәзер кабул ителми, эшләү өчен мәҗбүри түгел, бозган өчен йолым түләү каралмаган, һәм мондый нәзер өчен Аллаһ каршында тәүбә итәргә кирәк.</td></tr>
<tr><td rowspan="8">2.Аллаһ ризалыгы өчен. Мондый нәзер кабул ителә һәм ике төрле була:</td><td colspan="3">А. Гомуми нәзер, ул һәр мөселманга кагыла: «Алар нәзерләрен үтиләр», чөнки мөселман кешесе Аллаһка аның барлык кушканнарын үтим, тыйганнарыннан тыелам, дип нәзер әйтә.</td></tr>
<tr><td rowspan="7">Б. Конкрет әйбергә яки аның хөкеменә карата шәхси нәзер:</td><td colspan="2">Әйткәнчегә кадәр — тыелган, чөнки Пәйгамбәр ﷺ аны әйтүдән тыйды, чөнки әгәр аңарда хәерлелек булса, Пәйгамбәр ﷺ үзе аны әйтер иде. Әмма Пәйгамбәр ﷺ үзе мондый нәзерләр әйтмәде һәм башкаларга да тыйды, бу аларның рөхсәт ителмәгәнлеген күрсәтә.</td></tr>
<tr><td rowspan="6">Әйткәч — үтәргә яки үтәмәгән өчен йолым түләргә кирәк. Аның хөкеме нәзернең категориясеннән тора:</td><td>1.Итагать итү нәзере: үтәлергә тиешле, ә бозган өчен йолым түләргә кирәк. Мәсәлән, тыелмаган вакытта ирекле намаз уку турындагы нәзер.</td></tr>
<tr><td>2.Тыңламау нәзере: үтәү тыелган. Мондый нәзерне бозарга һәм йолым түләргә кирәк. Мәсәлән, тыелган нәрсәләрне үтәү турындагы нәзер, әйтик, гайбәт.</td></tr>
<tr><td>3.Рөхсәт ителгәннән нәзер әйтү: үтәргәме яки йолым түләп бозаргамы дигән сайлау куела. Мәсәлән, билгеле бер рөхсәт ителгән кием кияргә нәзер әйтү.</td></tr>
<tr><td>4.Ачулы, ярсулы вакытта яки кирелек белән нәзер әйтү: рөхсәт ителгәннән нәзер әйтү хөкеме кебек үк, һәм күз алдында антны тота. Мәсәлән, шәһәрне чыгып китәргә нәзер әйтү.</td></tr>
<tr><td>5.Эшләнергә тиеш түгел гамәлләр хакында нәзер әйтү: үтәү тиеш түгел, йолым түләп бозу тиешле. Мәсәлән, намаз вакытында як-якка борылу турындагы нәзер.</td></tr>
<tr><td>6.Гади нәзер: аны әйтүче бернәрсәне дә атамый һәм аның өчен йолым түләргә кирәк. Мәсәлән, «Аллаһка нәзер әйтәм...»,— дип әйтү һәм дәшмәү.</td></tr>
</table>

Нәзер әйтү тиеш түгел [яки тыелган].

Пәйгамбәр ﷺ нәзер әйтүдән тыйды, ул болай диде: ***«Ул хәерлелек алып килми һәм аның ярдәмендә саран кешедән нәрсәнедер тартып алалар».*** Килешенгән хәдис.

Әгәр кеше нинди дә булса яхшылыклар хакында нәзер әйтсә, ул аны үтәргә тиеш, чөнки Пәйгамбәр ﷺ әйтте: ***«Аллаһка буйсыну нәзере әйтсә, аны үтәсен, ә Аллаһны тыңламаска нәзер әйткән кеше үтәмәсен».*** Килешенгән хәдис.

Әгәр нәзер ниндидер рөхсәт ителгән нәрсә хакында яки антны алыштырып килсә, мәсәлән, ачулы вакытта яки кирелек белән әйелгән яки тыңламау нәзере булса:

| | | |
|---|---|---|
| 1.Аны үтәү мәҗбүри түгел. | 2.Аны үтәмәгән өчен йолым түләргә кирәк. | 3.Тыңламау нәзерен үтәү тыела. |

| **Итагать итү, тыңламау һәм Аллаһ ризалыгы өчен булмаган нәзерләрнең аермасы:** | | |
|---|---|---|
| **1.Аллаһка итагать итү турындагы нәзер:** Расланa, ягъни аны үтиләр яки үтәмәгән өчен йолым түлиләр. Ләкин үтәү мәҗбүри. | **2.Аллаһны тыңламау нәзере:** Расланa, ягъни үтиләр яки үтәмәгән өчен йолым түлиләр. Әмма үтәү тыелган. | **3.Аллаһка булмаган нәзер:** Расланмый. Үтәү дә үтәмәгән өчен йолым түләү дә юк, әмма тәүбә итәргә кирәк, чөнки бу — олы ширек. |

| **Антны саклау дәрәҗәләре:** | | | |
|---|---|---|---|
| 1.Башта саклау: күп антлар бирмичә. | 2.Уртада саклау: кайбер искәрмәләрдән тыш, аны бозмау. | 3.Ахырда саклау: бозганнан соң йолым түләп. | 4.Аллаһ исеме белән булмаган антлар әйтү. |

**Ялган сөйләүне тыйган кайбер риваятьләр:**

Аллаһ Тәгалә әйтте: **«Үзең белмәгән нәрсәләргә иярмә. Чынлыкта, колаклар, күзләр һәм калеб — болар барысы да җавапка тартылачак.»**

Аллаһ Тәгалә әйтте: **«Аңа сүз әйтү җитә, янәшәсендә әзер күзәтче пәйда була.»**

Пәйгамбәр ﷺ әйтте: ***«Хакыйкатьтә, дөреслек тәкъвалыкка алып бара, һәм, хакыйкатьтә, тәкъвалык җәннәткә алып бара һәм кеше дөресен сөйләр, Аллаһ каршында дөресен сөйләүче дип язылганчыга кадәр. Һәм, хакыйкатьтә, ялган сөйләү гөнаһка алып бара, һәм, хакыйкатьтә, гөнаһ җәһәннәмгә алып бара һәм кеше ялганлый башлар, Аллаһ каршында иң нык ялганчы дип язылганчыга кадәр».*** Килешенгән хәдис.

## РИЗЫК КИТАБЫ БУЕНЧА СОРАУЛАР

| Сораулар: | Дөрес | Дөрес түгел |
|---|---|---|
| — Мөселман кешесенә Шәригать текстларында рөхсәт ителгәнлеге хакында телгә алынмаган ризыкны ашарга рөхсәт ителми.<br>— Диңгез хайваннары, үлгән булсалар да, әгәр алар сасымаган булса, ашарга рөхсәт ителгән.<br>— Крокодил итен кулланырга ярый, чөнки ул диңгез хайваны.<br>— Консервланган диңгез продуктларын ризык итеп кулланырга ярый, әгәр алар бозылмаган булса, мәсәлән, кипкән креветкалар.<br>— Исерткеч эчемлекләрдән шәраб дип аталганы гына тыелган.<br>— Күп күләмдәге эчемлекләр һәм ризыклар исертсә дә, аларны аз күләмдә кабул итү рөхсәт ителгән.<br>— Диңгез хайваннарын ризык итеп куллану өчен аларны чалу шарт булып тора.<br>— Әгәр чалган вакытта «нәхр» ысулы кулланылган булса, чалу дөрес түгел.<br>— Чалу мөмкин булмаган очраклардан тыш, хайваннарны яралау тыела.<br>— Хайваннарның итен ризыкка кулланырга рөхсәт булсын өчен аларны чалу шарт түгел, ә тиешле гамәл булып тора.<br>— Гамәл кыла ала торган кечкенә бала мал чала ала.<br>— Кеше сату һәм акча эшләү өчен киек аулый ала.<br>— Хаҗ кылучы кешегә балык ауларга тыелган.<br>— Йорт хайваннарын аулау рөхсәт ителгән.<br>— Мәккәдә булган, әмма хаҗ кылмаган кешегә коры җирдә киек аулау тыелган. | | |

— Нигездә һәрбер ризык рөхсәт ителгән, без бары тик Коръән һәм Сөннәттән килгән дәлилләр нигезендә тыелган ризыкны гына тыя алабыз.

— Кем дә кем нинди дә булса хайваннан яки үсемлектән алынган ризыкны тыйса, ул дәлилләр китерергә тиеш, чөнки нигездә һәртөрле ризык та рөхсәт ителгән.

— Нигездә хайваннан алынмаган һәртөрле ризык, әгәр сәламәтлеккә зыян салмаса, рөхсәт ителгән.

— Казык тешләре булган һәртөрле ерткыч хайваннар, тырнаклары булган һәртөрле кошлар тыелган. Үтерергә боерылган һәртөрле хайван итен һәм үтерергә тыелган һәртөрле хайван итен ризык итеп кулланырга тыелган.

— Ислам дине кешегә дә, хайваннарга да мәрхәмәтле булырга куша.

— Чала торган хайван рөхсәт ителсен өчен аның каны агызылырга тиеш.

— Нәзер әйтү язмышны үзгәртми, изгелекне үзенә тартмый һәм яманлыкны бетерми.

— Мал чалучыдан сарык качып китте. Ул «бәсмәлә» әйтте һәм пуля атты, пуля сарыкны үтерде: сарык үләксә___, рөхсәт ителгән___.

— Кеше үзенең мылтыгын чистартаканда ул ялгыш атып җибәрде һәм киеккә тиде: ул үләксә___, рөхсәт ителгән___.

— Мөселман кешесе мал чалганда аңлы рәвештә «бәсмәлә» әйтмәде: ул үләксә___, рөхсәт ителгән___.

— Йолым түләү мәҗбүри булмаган ант, ул: үткәннәр турында ант___, фараз өстен чыгу турында ___, бөтен саналганнар да____.

— Күбрәк нәрсә тыелган: Аллаһ исеме белән булмаган дөрес ант___, Аллаһ исеме белән ялган ант___.

— Сәламәтлеккә зыян салмаучы һәртөрле яхшы һәм чиста продуктлар һәм эчемлекләр: рөхсәт ителгән___, рөхсәт ителгәнлек хакында дәлилләр кирәк___.

— Тырнаклары булучы кошлар: рөхсәт ителгән____, тыелган____, аныклау кирәк: әгәр алар табышларын тырнаклары ярдәмендә ауласалар, тыелган, әгәр юк икән, рөхсәт ителгән ____.

— Әгәр яралы киек табылса һәм ул исән булса, шуннан соң чалынса, аның ите: рөхсәт ителмәгән___, рөхсәт ителгән____.

— Хайванны тоткынлыкта тотарга һәм аны ату өчен мишень итәргә: атарга өйрәнү өчен ярый___, ярамый___.
— Әгәр рөхсәт ителгән яхшы әйбер конкрет бер кешегә зыян китергәне билгеле булса, ул аңа: тыелган___, рөхсәт ителгән___.
— Рөхсәт ителгән___, рөхсәт ителмәгән___ чалынган мал, әгәр аның өстендә Аллаһ исеме әйтелмәгән булса
— Кеше күп итеп ант итәргә тиеш___, тиеш түгел____. Әгәр ниндидер бер мөһим нәрсә турында сүз булса, ант итәргә тиеш___, тиеш түгел____.
— Әгәр сүз ниндидер яхшы нәрсә хакында барса, кеше үзенең антын бозарга тиеш ___, тиеш түгел____.
— Бернәрсә дә әйтелмәгән нәзер өчен: йолым түләргә кирәк___, йолым кирәк түгел___.
— Тыңламау нәзере раслана ____, расланмый____, ләкин аны үтәргә ярый_____, ярамый_____, бозган өчен йолым түләнә___, түләнми____.
— Кем бөтен параметрлар буенча да үтәлә алмый торган нәзер әйтсә, ул нәрсә булдыра ала, шуны үтәргә тиеш, һәм калган нәрсәләр өчен йолым түләргә тиеш: дөрес____, дөрес түгел___.

| **Сорау:** | **Рөхсәт ителгән** | **Рөхсәт ителмәгән** |
|---|---|---|
| — Зебра | | |
| — Агулы хайваннар: елан, чаян, кәлтә. | | |
| — Үзенең итен куллану рөхсәт ителгән, ә баласының итен рөхсәт ителмәгән хайваннардан: качыр (ат һәм йорт ишәге балалары). | | |
| — Итен ризык итеп кулланырга ярый торган хайванны башка максатларда чалу. | | |
| — Мөселман кешесе үзенең өйрәтелмәгән эте ярдәмендә куян тота. | | |
| — Мөселман кешесе үзенең өйрәтелгән эте ярдәмендә киек тота, әмма эт аның бер өлешен ашый. | | |

# ҖИНАЯТЬЛӘР КИТАБЫ

## ҖИНАЯТЬЛӘР КИТАБЫ

<table>
<tr><td colspan="5">Җинаять — ул кешенең гәүдәсенә кул сузу, ул үз артыннан үч алу, материаль түләүләр яки йолымтудыра. Ике төрле була:</td></tr>
<tr><td rowspan="3">Гомергә каршы җинаять</td><td colspan="4">Кеше тәненең әгъзаларына каршы җинаять:</td></tr>
<tr><td colspan="2">А. Яралау</td><td rowspan="2">Б. Очлык-ларны кисү.</td><td rowspan="2">В. Гәүдәнең эшли торган ниндидер бер әгъзасын кисү.</td></tr>
<tr><td>Биттәге яки баштагы яра.</td><td>Тәннең башка өлешендәге яра.</td></tr>
</table>

<table>
<tr><td colspan="5">Хаксызга үтерүнең 3 төре бар:</td></tr>
<tr><td colspan="2">1.Явыз ният белән эшләнгән: алдан уйлап эшләнгән җинаять, гадәттә үлемгә китерә. Үтерелгән кешенең опекунына сайлау хокукы бирелә:</td><td rowspan="3">2. Явыз ният белән эшләнгәнгә охшаш:<br>Үлемгә китермәүче алдан уйлап эшләнгән җинаять</td><td colspan="2">3.Хата белән эшләнгән: уйламыйча эшләнгән җанять: турыдан-туры яки сәбәп белән. Соңгысы өчен үч алу каралмаган, ә:</td></tr>
<tr><td>А. Җавап итеп үтерү</td><td>Б. акча түләү, йолым</td><td rowspan="2">А. Үтерүче кешенең милкеннән йолым алу, ягъни бер колны азат итү, әгәр ул булмаса, ике ай рәттән ураза тоту.</td><td rowspan="2">Б. Туганнарына акча түләү: ул үтерелүченең барлык туганнары, якыннары да ераклары да. Акча алар арасында, аларның хәләтенә карап, бүленә һәм 3 ел дәвамында, һәр елны өчтән бер өлешен түләп.</td></tr>
<tr><td colspan="2">Чөнки Пәйгамбәр ﷺ әйтте: «Әгәр кемнеңдер туганын үтерсәләр, ул икенең берсен сайлый ала: үтерелгән кеше өчен акчалата түләү алу яки җавап итеп үтерү». Килешенгән хәдис.</td></tr>
</table>

| Кан үч алу шартлары: | | | |
|---|---|---|---|
| 1.Үтерүче кеше мөкәлләф (гакыллы, бәләгатькә ирешкән) булырга тиеш. | 2.Үтерелгән кеше үтерелүдән имин булган булырга тиеш. | 3.Үтерүче һәм үтерелүче кеше арасында тигезлек: ирекә һәм диндә. | 4.Тумау, ягъни әти-әниләр балаларга, оныкларга һәм аларның балаларына үч итеп үтерелергә тиеш түгел. |

| Үч алуны тормышка ашыру шартлары: | | |
|---|---|---|
| 1.Үчкә лаек кеше мөкәлләф (гакыллы, бәләгатькә ирешкән) булырга тиеш. | 2.Үч алуга карата туганнарның бердәм фикере булу. | 3.Үч алганда, җинаятьчегә җинаятеннән дә күбрәк зыян салып чикләрдән ашу. |

| Өч төр үтерү һәм аларның хөкемнәре: | | |
|---|---|---|
| 1.Явыз ният белән эшләнгән | 2.Явыз ният белән эшләнгәнгә охшаш | 3.Хата белән эшләнгән |
| Кан үч алу билгеләнгән | Кан үч алу билгеләнмәгән | |
| Яки үтерүче кеше ягыннан акча түләү | Туганнар ягыннан акча түләү каралган | |
| Үтерүче ягыннан ният белән кылына ала | | Ниятсез башкарыла |
| Җитди түләү каралган | | Җиңелчә түләү каралаган |
| Зур гөнаһ була | Гади гөнаһ була | Гөнаһ булмый |
| Йолым каралмаган | Йолым каралган (кәффәра) | |

**Йолымның ике кагыйдәсе:**

— Һәртөрле параличланган әгъза өчен дә йолым каралмаган. Мондый зыян өчен штрафны имам билгели, ике әгъзаның параличланганыннан кала: колаклар һәм борын.

— Гәүдәнең нинди дә булса әгъзасына карата, аны параличлап, җинаять эшләгән һәркем, компенсация түләргә тиеш, колак һәм борыннан кала, чөнки аларның матурлыгы хәтта параличтан соң да саклана.

Үтергән өчен һәм башка җинаятьләр өчен компенсация төрләре Гамр ибн Хазм хәдисендә аңлатыла: ***«Әгәр кешенең иманлы кешене хаксызга һәм явыз ният белән үтерүе исбатланса, ул җәзалап үтерелергә тиеш, үтерелгән кешенең туганнары аның белән башкача эшләргә теләмәсә. Һәм явыз ният белән һәм гаделсез рәвештә иманлы кешене һәлак иткән булуы расланса, аны үзен җәзалап үтерергә тиешле, әгәр үтерелгән кешенең туганнары аның белән башкача эшләргә уйламаса. Һәм:***

| | | | |
|---|---|---|---|
| ***Гомер*** | ***Үтерелгән кеше өчен йолым йөз дөя тора.*** | | |
| ***Борын*** | ***Әгәр кешенең борынын тулысы белән кисеп алсалар, йолым тулы түләнә,*** | ***Тел*** | ***Тулы йолым*** |
| ***Ирен*** | ***Ирен өчен — тулы йолым*** | ***Җенес әгъзасы*** | ***Тулы йолым*** |
| ***Күкәйлекләр*** | ***Тулы йолым*** | ***Умыртка баганасы*** | ***Тулы йолым*** |
| ***Күз*** | ***Тулы йолым*** | ***Аяк табаны*** | ***Йолымның яртысы*** |
| ***Баштагы тирән яра*** | ***Йолымның өчтән бер өлеше*** | ***Тәнгә тишеп керелгән яра*** | ***Йолымның өчтән бер өлеше*** |
| ***Сөякләре урыныннан күчкән баш җәрәхәте*** | ***15 дөя*** | | |
| ***Бармак*** | ***Кул яки аяктагы һәр чабып өзелгән бармак өчен — 10 дөя*** | | |
| ***Теш*** | ***Тешне сындырган өчен — 5 дөя*** | | |
| ***Яки сөякләр күренеп торырлык җәрәхәт ясау*** | ***5 дөя*** | | |

***Барлык сизү: ишетү, күрү, тәм сизү органнары өчен — тулы йолым.***

***Хатын-кызны үтергән өчен ир-атны җәзалап үтерү тиеш. Әгәр кешеләр йолымны алтын белән түләргә теләсәләр, алар йөз динар итеп түләргә тиешләр».*** Әбу Давыд

| Яраларның кайбер төрләре: | | | |
|---|---|---|---|
| **1.Башның тән аркылы тишеп кергән тирән җәрәхәте** | **2.Тәннең тишеп кергән тирән җәрәхәте** | **3.Сөякләре урыныннан күчкән баш җәрәхәте** | **4.Сөякләр күренеп торырлык җәрәхәт.** |

| Кешенең гәүдә әгъзалары берничә категориягә ия: | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1. **Бер генә**: тел. Хөкеме: тулы йолым. | 2. **Икеле**: күзләр. Хөкеме: ике күз өчен — тулы йолым, берсе өчен — ярты йолым. | 3. **Өчле**: борын (ике борын тишеге һәмбүлеме). Хөкеме: өчесе өчен дә — тулы йолым, аерым һәркайсы өчен — аның өчтән бер өлеше. | 4. **Дүртле**: күзләр өстендәге күз кабаклары. Хөкеме: барысы өчен дә — тулы йолым, берсе өчен — аның дүрттән бер өлеше. | 5. **Унлы**: кул бармаклары. Хөкеме: барысы өчен дә — тулы йолым, бер бармак өчен — аның уннан бер өлеше. |

| **Кан үче фарыз булсын өчен шартлар:** | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1.Үтерүче кеше мөкәлләф булырга тиеш. | 2.Үтерелүче кеше — кагылгысыз һәм үтерүче кеше белән тигез: диндә, коллыкта яки ирektә. Мөселманны имансыз өчен үч итеп үтермиләр, ә ирекле кешене — кол өчен. | 3.Үтерүче кеше үтерелгән кешенең ата-анасы булырга тиеш түгел. Ата-аналарны балалар өчен үч итеп үтермиләр. | 4.Мөкәлләф булган туганнарның бердәм фикере кирәк. | 5.Үч алган вакытта рөхсәт ителгән чикләр саклануына гарантия. |

Бер төркем үтерүчеләр бер үтерелгән кеше өчен үч итеп үтерелә ала, шулай ук җинаятьчегә шундый ук зарар китерү юлы белән үч итәргә рөхсәт ителгән, әгәр моны эшләгән вакытта рөхсәт ителгәннең чикләреннән үтелмәсә, чөнки Аллаһ Тәгалә әйтте: **«Без аңарда боердык: җан өчен — җан…».**

**Хатын-кызны үтергән өчен йолым:**

| | |
|---|---|
| 1.Ир-ат өчен түләнгән йолымның яртысы | 2.Өчтән бердән азрактан кала – монда алар тигез. |

**Үз-үзеңә кул салу турында:**

Аллаһ Тәгалә әйтте: **«Үз-үзегезгә кул салмагыз, чөнки Аллаһ сезгә карата мәрхәмәтле».**

Пәйгамбәр ﷺ әйтте: ***«Бу тормышта үз-үзенә кул салган кешене Кыямәт көнендә үз-үзенә кул салган нәрсә белән газапларлар».*** Килешенгән хәдис.

Ул әйтте: ***«Сезгә кадәр яшәгәннәр арасында яраланган бер кеше бар иде. Ул авыртуга түзә алмады һәм үзенең кулын чабып өзде. Ул күп кан югалтудан һәлак булды. Аллаһ Тәгалә әйтте: «Минем колым (үз-үзенә кул салып) Мине узып китте»».*** Бохари.

Үз-үзенә кул салуларның күбесе рухи төшенкелектән һәм өметсезлектән була. Аллаһ Тәгалә бу хакта әйтте: **«Ә адашканнардан тыш Раббысының рәхмәтеннән кем өмет өзә?»**

Кагылгысыз булган динсез бәндәләрне үтерүгә кагылышлы кайбер риваятьләр (гади халык яки мөселманнар белән килешү төзеп яшәүче кешеләр):

Пәйгамбәр ﷺ әйтте: ***«Кем дә кем мугахадны үтерсә, Җәннәтнең исен дә сизмәс».*** Бохари.

Ул әйтте: ***«Мөселманнар белән тынычлык солыхы төзеп яшәгән динсез кешене үтергән кеше, Җәннәтнең хәтта исен дә сизмәс».*** Әхмәд, Нәсаи.

Ул әйтте: ***«Кем дә кем гомеренә мөнәсәбәттә кешене куркынычсызлык белән тәэмин итсә, шуннан соң аны үтерсә, үтерелгән кеше динсез булса да, мин җинаятьче белән бергә түгел».*** Ибн Хиббан.

| Динсезләр белән килешү төрләре: | | |
|---|---|---|
| 1.**Алар тарафыннан намус белән үтәлгән килешү:** без җавап итеп әлеге килешүне тотарга тиеш. Аллаһ Тәгалә әйтте: **«Алар сезгә тугъры булганда, сез дә аларга тугъры булыгыз».** | 2.**Алар тарафыннан бозылган килешү:** мондый килешү өзелә. Аллаһ Тәгалә әйтте: **«Әгәр алар килешү төзегәннән соң үзләренең антларын бозсалар һәм сезнең динегезгә каршы төшсәләр, алар белән көрәшегез, чөнки алар өчен ант юк. Бәлки алар бу эшләрен туктатырлар».** | 3.**Алар тарафыннан бозылыр дип курыккан килешү:** читкә ташлыйбыз. Аллаһ Тәгалә әйтте: **«Ә әгәр син кешеләр ягыннан хыянәт булыр дип курыксаң, бөтенегез дә бертигез булсын өчен килешү бурычларын читкә ташла. Хакыйкатьтә Аллаһ хыянәтчеләрне яратмый».** |

# ҖӘЗАЛАР КИТАБЫ

# ҖӘЗАЛАР КИТАБЫ

<table>
<tr><td colspan="3">«Хадд» — бу Шәригать тарафыннан билгеләнгән җәза.</td></tr>
<tr><td colspan="3">Җәза ошбу кешеләргә карата гына кулланыла:</td></tr>
<tr><td>1. Мөкәлләф (гакыллы бәләгатькә ирешкән зат)</td><td>2.Законнарны үтәүче кеше</td><td>3.Тыелганлык турында белүче.</td></tr>
</table>

<table>
<tr><td colspan="2">Җәзаны куллана бары тик:</td></tr>
<tr><td>1.Имам яки аның вәкиле</td><td>2.Хуҗа кеше: аны камчы ярдәмендә куллана ала һәм бигрәк тә үзенең колларына карата.</td></tr>
<tr><td colspan="2">Колны камчы ярдәмендә җәзалау ирекле кешенең ярты җәзасына тигез.</td></tr>
</table>

<table>
<tr><td colspan="2">[Зина кылган өчен җәза:]<br>Җенес әгъзасына яки арт юлга якынлык кылу:</td></tr>
<tr><td>1.Өйләнгән яки кияүдәге кеше: өйләнгән ир-ат яки кияүдәге хатын-кыз (ирекле мөкәлләф булган) үзенең хәләл җефетеннән башка берәү белән якынлык кылса.<br>Мондый кешене таш белән атып үтерәләр (ир-атны да, хатын-кызны да).</td><td>2.Өйләнгән яки кияүгә чыкмаган: камчы белән 100 тапкыр суктыралар һәм бу илдән 1 елга сөрәләр (Хатын-кызны бары тик мәхрәме белән генә).</td></tr>
</table>

<table>
<tr><td colspan="2">Әмма әлеге шартлар булганда гына:</td></tr>
<tr><td>1.Гөнаһны дүрт мәртәбә тану.</td><td>2.Яки гөнаһ хакында ачыктан-ачык шаһитлык кылучы 4 иманлы шаһит булуы (ир-атлар).</td></tr>
<tr><td>3.Ире яки хуҗасы булмаган хатын-кызның йөкле булуы.</td><td>4.Яки ирнең хатыны кире какмый торган «Лиган»ы.</td></tr>
</table>

Аллаһ Тәгалә әйтте: «Әгәр никахлы булмасалар, зиначы ир белән зиначы хатынны йөз тапкыр камчы белән суктырыгыз».

Пәйгамбәргә ﷺ барып тоташучы бер хәдистә Губад ибн Самит хәбәр итә: ***«Миннән өйрәнегез! Миннән өйрәнегез! Аллаһ алар өчен башка юл билгеләде: әгәр зинаны беркайчан да никах белән яшәмәгән кешеләр кылса, аларны йөз мәртәбә камчы белән суктырып җәзаларга һәм шул җирлектән бер елга сөрергә кирәк, әмма әгәр никахта булган кешеләр зина кылсалар, аларны йөз тапкыр камчы белән суктырып җәзаларга һәм ташлар белән атып кыйнап үтерергә кирәк».*** Мөслим.

Ахырдан өйләнгән ир-атны яки кияүдәге хатын-кызны ташлар белән атып үтерү белән генә чикләнергә боерылды, бу хакта Магизһәм Гамидийки сөйләде.

Аллаһның рәхмәте белән зина гөнаһысыннан саклаучы куркынычсызлык чаралары:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1. Аллаһтан курку һәм дога. Аллаһ Тәгалә әйтте: **«Әгәр Син миннән аларның мәкерләрен читкә җибәрмәсәң, мин аларга юл куячакмын».** Ә Пәйгамбәр ﷺ әйтте: ***«Аллаһ ризалыгы өчен син нәрсәне генә калдырсаң да, Ул, һичшиксез, аны хәерлерәк нәрсә белән алыштырыр!»*** Әхмәд. | 2. Өйләнү белән ашыгу, әгәр мөмкинчелек булмаса, ураза тоту. | 3. Хатын-кызлар белән очрашудан качып булмаган урыннардан, мәсәлән, базарлардан, качарга тырышу һәм карашларны төшерү. | 4. Хатын-кызларга хиҗәб кияргә, ир-атлар белән йомшак итеп сөйләшмәскә, ир-атларга алар белән икәүдән-икәү генә калмаска һәм кул бирешеп күрешмәскә боерылды. | 5. Йосыф, аңа Аллаһның сәламе булсын, хакындагы сүрәне һәм риваятьне укырга.<br>6. Иманлы кешеләр белән бергә булырга.<br>7. *«Бурычка нәрсә алсаң, шуның белән түләрсең».* Зина — ул бурыч. |

| [Яла яккан өчен җәза] | | |
|---|---|---|
| Ул иң авыр гөнаһларның берсе. Кем дә кем өйләнгән ир-атка яла якса яки аңа каршы тулы булмаган шәһәдәт әйтсә: | | |
| 1.Аны 80 тапкыр камчы белән суктырып җәзалыйлар | 2.Алга таба аның шәһәдәтен кабул итмиләр | 3.Аны бозык бәндәләрдән саныйлар. |
| Өйләнмәгән ир-атка яла яккан өчен «тагъзир» җәзасы кулланыла.<br>Өйләнмәгән ир-ат ул: ирекле, бәләгатькә ирешкән, гакыллы, гыйффәтле мөселман. | | |

| [«Тагъзир»] |
|---|
| Ул хадд та, кәффәрә дә каралмаган һәртөрле гөнаһ кылынган очракта да фарыз [ягъни тыелганны кылган яки фарызны калдырган өчен җәза имамның теләге буенча билгеләнә]. |

| [Урлаган өчен җәза] | | |
|---|---|---|
| Әгәр кеше сакланган урыныннан алтын динарның чирегеН яки шул суммага туры килгән башка милекне урласа: | | |
| 1.Аның уч төбеннән уң кулын чабып өзәләр. | 2.Әгәр ул урлашуын кабатласа, табан өлешеннән сул аягын чабып өзәләр. | 3.Әгәр шуннан соң да урлашуын дәвам итсә, аны төрмәгә ябалар, чөнки бары тик бер кулны һәм бер аякны гына чабып өзәргә ярый. |
| Аллаһ Тәгалә әйтте: **«Карак ир һәм карак хатынның кулын чабып өзегез...».**<br><br>Пәйгамбәребезгә ﷺ барып тоташучы бер хәдистә Гайшә, Аллаһ аннан риза булсын, хәбәр итеЛә: ***«(Каракның) кулын бары тик динарның дүрттән бер өлеше кадәр бәядәге әйбер урлаган өчен генә чабып өзәләр».*** Килешенгән хәдис.<br><br>Икенче бер хәдистә килә: ***«Урланган җиләк-җимеш һәм пальманың агачының үзәген урлаган өчен кулны чабып өзмиләр».*** «Сунан» китабы авторлары китерде. | | |

| [Спиртлы эчемлекләр кулланган өчен җәза] | | | |
|---|---|---|---|
| «Мускир» — моңа кешегә рәхәтлек китерә, исертә, ярсыта, югарыга күтәрә, гакылын томалый торган нәрсәләрнең барысы да керә. Һәм бу эчемлекләргә дә (шәраб), коры матдәләргә дә (наркотиклар) кагыла.<br><br>«Хәмр» — ул виноградтан, хөрмәләрдән, бодайдан, арпадан һәм башкалардан ясалган гакылдан яздыра торган нәрсәләр.<br><br>Пәйгамбәр ﷺ әйтте: ***«Бөтен исерткеч нәрсәләр — ул хәмер».*** Ул шулай ук әйтте: ***«Барлык исерткеч эчемлекләр дә тыелган».*** Һәм ул әйтте: ***«Зур күләмдә исерткән нәрсәләрнең аз күләме дә тыелган».***<br><br>Мондый эчемлекләр рәхәтлек алу өчен дә, сусауны басар өчен дә (чөнки алар эчәсене тагын да ныграк китерәләр) һәм дарулар сыйфатында да тыелган. Исерткеч матдәләр — ул барлык яман гамәлләрнең дә нигезе. Аллаһ Тәгалә ул турыда болай диде: **«Хакыйкатьтә, исерткеч эчемлекләр, комарлы уеннар, таш потлар һәм бага торган уклар да шайтанның яман эшләреннән. Аннан ерак торыгыз — бәлки сез уңышка ирешерсез».** Алар наркотик һәм шуныңише матдәләргә караганда да куркынычрак һәм зур хикмәт белән тыелган, боларга керәләр: | | | |
| 1. Шайтан гамәлләреннән иң яманы | 2.Кешеләр арасында дошманлык һәм нәфрәт тарата | 3.Аллаһны зекер итүдән һәм намаздан читкә юнәлтә | 4.Исерек кешене гакылдан яздыра һәм аны тыелганны кылудан бернәрсә дә туктата алмый. |

**Спиртлы эчемлекләр эчүче кешенең хөкеме:** судья аңа карата тагъзир куллана, 40 тан да ким булмаган тапкыр һәм, әгәр дә кирәк дип табылса, күбрәк тә тапкыр камчы белән суктыру. Гомәр, Аллаһ аннан риза булсын, үз вакытында 80 тапкыр камчы белән суктырырга боерды.

## [Талаган өчен җәза]

Аллаһ Тәгалә юлбасарлар турында болай ди: **«Хакыйкатьтә, Аллаһка һәм Аның илчесенә каршы сугышучы һәм җир йөзендә бозыклык кылучылар, үтерелергә яки агачка кадакланырга яки аларның капма-каршы куллары һәм аяклары чабып өзелергә яки алар илдән куылырга тиешләр».**

Монда сүз кешеләргә ташланучы, юлларда талау, үтерү һәм урлау белән шөгыльләнүче юлбасарлар турында бара:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1.Үтергән һәм талаган кешенең үзен дә үтерәләр һәм агачка кадаклыйлар. | 2.Үтергән, әмма таламаган кешене үтерәләр, ләкин агачка кадаклامыйлар. | 3.Талаган, ләкин үтермәгән кешенең уң кулын һәм сул аягын чабып өзәләр. | 4.Үтермичә һәм таламыйча кешеләрне куркыткан кешене илдән куалар. |

## [Баш күтәрүчеләргә җәза]

Баш күтәрүчеләр (хариджитлар) — бу көч һәм куәтләре булып, имамга каршы чыгыш ясаучы һәм моңа аңлатмалары булган кешеләр

Бәреп төшерү теләге белән имамга каршы чыккан кешеләр баш күтәрүчеләр дип атала.

Имам тиеш:

| | | |
|---|---|---|
| 1.Баш күтәрүчеләр янына кеше җибәрергә. | 2.Гаепләүләргә каршы җавап бирергә тиеш. | 3.Аларның шикләрен таратырга. |

| | |
|---|---|
| 1.Әгәр тукталсалар, аларны калдырырга кирәк. | 2.Әгәр тукталмаслар һәм каршы көрәшә башласалар, аларга каршы көрәшү фарыз була. |

Имамның кул астындагы ярдәмчеләре әлеге көрәштә ярдәм итәргә тиешләр.

Әгәр әлеге көрәш баш күтәрүчеләрнең һәлак булуына һәм аларның милекләрен бозуга китерсә, саклана торган як алар өчен җаваплылыкта булмый.

Әгәр саклանучы яктан берәрсе булса да һәлак булса, ул шәһит була.

Качып китүче баш күтәрүчеләрне куып бармыйлар, яралыларны — үтермиләр, милекне — ганимәт малы буларак үзләштермиләр, аларның балаларын әсирлеккә алмыйлар

Бер як та сугыш барышында үтерелү сәбәпле дә, милеккә салынган зыян өчен йолым түләми.

## МӨРТӘТЛЕКНЕҢ ХӨКЕМЕ

Мөртәт — ул Ислам диненнән ваз кичкән һәм үзенең гамәле, сүзләре, инануы яки шикләре белән имансызлыкка төшкән кеше.

Галимнәр, Аллаһ аларны кичерсен, Аллаһның колын Ислам диненнән нинди гамәлләр чыгаруын тәфсилләп аңлаттылар, һәм алар тарафыннан телгә алынган бар нәрсәләр дә Пәйгамбәр ﷺ алып килгәннәрне яки аларның бер өлешен инкарь итүгә кайтып кала.

Мөртәтне [шунда ук җәзалап үтерергә кирәк, әгәр имам әлеге карарны кичектереп торуда файда күрмәсә] 3 көн дәвамында тәүбәгә килергә чакыралар һәм, әгәр ул Ислам диненә кире кайтса, исән калдыралар. Киресенчә булганда исә, аны кылыч ярдәмендә җәзалап үтерүгә хөкем итәләр.

| **Мөртәтлеккә китерүче гамәлләр:** | | | |
|---|---|---|---|
| 1.Сүз: Аллаһ Тәгаләне һәм Аның Пәйгамбәрне ﷺ яки Ислам динен хурлау. | 2.Гамәл: потка сәҗдә кылу. | 3.Инану: Аллаһның тиңдәшләре бар дип инану. | 4.Шик: Мәсәлән, яһүдиләрнең һәм христианнарның инанмаулары |

| **Мөртәтнең тәүбәсе ничек башкарыла:** | | |
|---|---|---|
| 1.Ике тапкыр шәһадәт әйтү. | 2.Инанырга баш тартып инкарь итүен икърар итү. | 3.Инанмавыннан баш тарту. |

| **Ислам диненнән чыгаручы гамәлләрнең башында ошбу 10 гамәл тора:** | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1. Аллаһка тиңдәшлек кылу. Аллаһ Тәгалә әйтте: **«Сиңа һәм синнән алда килгән халыкларга әйтелде: «Әгәр син Аллаһка тиңдәшлек кылсаң, синең бар эшең дә файдасыз булыр».** Бирегә шулай ук Аллаһтан башка бүтән затка корбан китерү дә керә. | 2.Аллаһ һәм үзең арасында яклау бирүче, ярдәм итүче, өметләргә җавап бирүче арадашчылар барлыгын икърар итү. | 3.Мөшрикләрне имансыз итеп танымау яки аларның имансызлыкларында шикләнү, яки аларның юлын дөрес дип исәпләү. | 4.Пәйгамбәребезнең сөннәтеннән дә яхшырак һәм камилрәк җитәкчелек бар икәнлегенә ышану. | 5. Пәйгамбәребез ﷺ алып килгән кануннарга карата нәфрәт, хәтта кеше нәфрәт уяткан нәрсәсен үтәсә дә. |
| 6.Пәйгамбәребез ﷺ алып килгән диннән яки Аллаһның әҗереннән яки җәзасыннан көлү, мыскыл итү. | 7.Сихерчелекне куллану яки аны кулланганнан канәгатьләнү алу. Монда төрле сөйдергечләр ясату да, бозым эшләү дә керә. | 8.Имансызларга мөселманнарга каршы булган эшләрендә ярдәм күрсәтү, булышу. | 9.Кайбер кешеләргә Мөхәммәднең ﷺ Шәригатеннән чыгу рөхсәт ителгән дип ышану. | 10.Аллаһның динен өйрәнмичә, дини кануннарны үтәмичә әһәмият бирмәү. |

# ХӨКЕМ ЭШЕ, ДӘГЪВӘ, ДӘЛИЛЛӘР ҺӘМ ШӘҺӘДӘТ ТӨРЛӘРЕ КИТАБЫ

# ХӨКЕМ ЭШЕ, ДӘГЪВА, ДӘЛИЛЛӘР ҺӘМ ШӘҺӘДӘТ ТӨРЛӘРЕ КИТАБЫ

**Кагыйдә:** һәртөрле идарә һәм гамәлдә дә ике төрле әркән булу кирәк: 1.көч, һәм 2.ышаныч.

Хөкем эше кешеләргә кирәк һәм җәмәгать бурычы булып тора [әгәр кешеләрнең бер өлеше шуның белән шөгыльләнсә, башкалар өстеннән җаваплылык төшерелә. Әгәр барча иманлы бәндәләр хөкем эшеннән баш тартсалар, алар барысы да гөнаһ эшләгән булырлар, шуңа күрә:]

| | | |
|---|---|---|
| 1.Имам хөкем эшен, Шәригать кануннарын һәм аларның кешеләр арасында барлыкка килгән төрле ситуацияләрдә куллана белүче бер кешене билгеләргә тиеш. | 2.Ул яхшы судья билгеләргә тиеш. Һәм ул мөселман, мөкәлләф, ир затыннан һәм гыйлемле, белүче кеше. | 3.Әгәр хөкем эшен белүче башка кеше булмаса һәм әгәр бу эш тагын да мөһимрәк эшләрдән игътибарын юнәлтмәсә, аны белүчегә ул шәхси бурычка әйләнә. |

Пәйгамбәр ﷺ әйтте: ***«Дәгъвачы кеше дәлилләр китерергә, ә гаепне кире кагучы — ант китерергә тиеш».*** Әд-Даракутни.

Ул шулай ук әйтте: ***«Мин ишеткәнем буенча хөкем итәм».*** Килешенгән хәдис.

Һәм ул әйтте: ***«Кем дә кем нинди дә булса милеккә дәгъва белдерсә, ул дәлилләр китерергә тиеш:***

| | | |
|---|---|---|
| 1.***Яки ике иманлы шаһитне.*** | 2.***Яки бер ир-ат һәм ике хатын-кызны.*** | 3.***Яки бер ир-атны һәм дәгъва белдерүче нең антын китерергә тиеш».*** |

Чөнки Аллаһ Тәгалә әйтте: **«Шаһит буларак үзегезнең арагыздан ике ирне китерегез. Әгәр ике ир-ат булмаса, ул вакытта үзегез шаһит буларак танырга риза булган бер ир-атны һәм ике хатын-кызны».**

***«Пәйгамбәр ﷺ дәгъвачының анты һәм бер шаһитнның сүзләре нигезендә карар чыгарды»*** — «Сунан» китабы авторлары китергән дөрес хәдис.

<table>
<tr><td colspan="3">Әгәр дәгъвачы дәлилләр китермәсә:</td></tr>
<tr><td rowspan="2">1.Җавапка тартылучы ант әйтә һәм үзен аклый.</td><td colspan="2">2.Әгәр җавапка тартылучы ант әйтүдән качса:</td></tr>
<tr><td>А. Хөкем җавапка тартылучының качуы нигезендә чыгарыла.</td><td>Б. Яки антны дәгъвачыдан таләп итәләр. Әгәр дәгъвачы ант әйтеп җавапка тартылучы кеше анттан качса, дәгъвачы нәрсәгә дәгъва итсә, шуны ала.</td></tr>
</table>

<table>
<tr><th colspan="3">Әйберләрне кемнеке булса да итүнең 3 төре бар:</th></tr>
<tr><td>1.Раслау: кеше әйберне үзенеке итә.</td><td>2.Икърар: кеше, үзенә каршы барып, әйбернең кешенеке икәнен таный.</td><td>3.Шәһәдәт: кеше, 3нче затка каршы, әйбернең 2нче затныкы булуын шәһәдәт итә. .</td></tr>
</table>

<table>
<tr><td colspan="2">Дәгъвалашучы ике якның берсе хак икәнлегенә күрсәтүче хәлнең булуы дәлилгә керә. Мәсәлән,</td></tr>
<tr><td>1.Дәгъвалау предметы аларның икесенең берсендә булуы. Әгәр ул ант китерсә, әлеге әйбер аныкы була.</td><td>2.Икенче мисал: ике кеше берсенеке генә булырга мөмкин булган милек өчен дәгъвалаша, мәсәлән, балта остасының йомычка өчен дәгъвасы яки тимерченең эш коралы өчен дәгъвасы һәм башкалар.</td></tr>
</table>

<table>
<tr><th colspan="2">Шәһәдәт 2 төрле була:</th></tr>
<tr><td>1.Үз өстенә җаваплылык алу</td><td>2.Тормышка ашыру.</td></tr>
<tr><td colspan="2">Үз өстенә җаваплылык алу һәм тормышка ашыруның хөкеме:</td></tr>
<tr><td>1.Кеше хокукларына карата шәһәдәт өчен үз өстенә җаваплылык алу — ул җәмәгать бурычы.</td><td>2.Аны тормышка ашыру — индивидуаль бурыч.</td></tr>
</table>

<table>
<tr><td colspan="3">Шаһит кешенең тышкы яктан да, эчке яктан да иманлы булуы шарты белән.<br><br>«Гәдль» — ул башкалар шаһит итеп танырга риза булган кешеләр, чөнки Аллаһ Тәгалә әйтте: «...сез шаһит итеп танырга риза булган кешеләр».<br><br>Шаһит үзе белмәгән нәрсәләр хакында шаһитлык китерергә тиеш түгел:</td></tr>
<tr><td>1.Үз күзләре белән күрмәсә.</td><td>2. Кемгә каршы шаһитлык бирә, шул кешедән шәхсән үзе ишетмәсә.</td><td>3.Яки мәгънәсен билгеләү мөмкин булган фактор булмаса, ә ул фактор аның аерып алгысыз өлеше булса.</td></tr>
</table>

Пәйгамбәр ﷺ ниндидер бер кешедән сорады: ***«Син кояшны күрәсеңме?»*** Теге кеше җавап бирде: *«Әйе».* ***«Ул вакытта шулай аерым ачык булган нәрсәләр хакында гына шаһитлык ит яки бөтенләй итмә».*** Ибн Гәди. Аллаһ Тәгалә әйтте: **«Ялган сүзләр сөйләүдән качыгыз».**

Шаһитлык кылуга комачау итә торган нәрсәләр арасында: ялган гаепләүдә шикләнү [әгәр андый шикләнү булмаса, дәлил кабул ителә], мәсәлән,

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1.Балалары файдасына ата-ананың шаһитлыгы. | 2.Киресенчә. | 3.Ир белән хатынның бер-берләре файдасына шаһитлык итүләре. | 4.Кешенең үзенең дошманына каршы шаһитлык итүе. |

Хәдистә хәбәр ителә: ***«Монафыйк ирнең һәм монафыйк хатынның, шулай ук дошманына каршы шаһитлык итүченең, хезмәтченең хуҗасына каршы дәлилләре кабул ителми»***. Әхмәд, Әбу Давыд.

Башка бер хәдистә хәбәр ителә: ***«Кем мөселман кешесенең милеген тартып алу өчен Аллаһка ялган ант китерсә, шуңа Аллаһның ачуы төшәр».*** Килешенгән хәдис.

## БҮЛҮ

<table>
<tr><th colspan="3">Бүлү</th></tr>
<tr><td colspan="3">Ике төрле була:</td></tr>
<tr><td rowspan="2">1.Мәҗбүри бүлү, ул зыян китерми һәм түләүләр түләргә кирәкми, мәсәлән ике бертөрле әйберне, зур торак йортларны һәм иркен биләмәләрне бүлү.</td><td colspan="2">2.Ике якның да ризалыгы белән бүлү: ул хуҗаларның берсенә зыян китерергә мөмкин һәм бу очракта түләргә кирәк. Мондый бүлү вакытында барлык катнашучыларның да ризалыгы кирәк.</td></tr>
<tr><td>1.Әгәр ике якның берсе сатуны таләп итсә, аның бу таләбен канәгатьләндерергә кирәк.</td><td>2.Әгәр алар үзләренең өлешләрен арендага бирсәләр, ул очракта алар өлешенең аренда түләвен түләргә кирәк, ә Аллаһ бу хакта яхшырак белә.</td></tr>
</table>

## ГАЕБЕҢНЕ ТАНУ

| Гаебеңне тану |
| --- |
| Гаебен тануга ишарәли торган сүзләр әйтеп, кешенең үз гаебен тануы [гаебен танып килүе], бу очракта аның мөкәлләф булуы шарт.<br><br>Бу гаепне дәлилләүнең иң яхшысы һәм ул үз эченә барлык юнәлешләрне дә ала: гыйбадәт кылу, кешеләр белән мөнәсәбәт, никах кылу, җинаять кылу һәм башкалар.<br><br>Хәдистә хәбәр ителә: ***«Гаебен таныган кешегә аклау юк»*** [Ибн Хаджар һәм башкалар әлеге хәдиснең нигезе юк диделәр, әмма автор, Аллаһ аны кичерсен, «Әл-усуль әль-джәмига» китабында фикх кагыйдәсе буларак китерде]. Кеше, үтәү яки үтәмәскә рөхсәт алу юлы белән җаваплылыктан котылу өчен, башка кешеләрнең хокукларын һәм үзенең бурычларын танырга тиеш. Аллаһ бу хакта яхшырак белә. |
| Безнең хуҗабыз һәм Пәйгамбәребезгә ﷺ, аның гаиләсенә һәм аның сәхәбәләренә дә Аллаһ Тәгаләнең рәхмәтләре һәм бик күп тапкырлар сәламнәре булсын.<br><br>Китапка комментарийларны Аллаһта мохтаҗ булган һәм үзенең динен һәм тормышын дөресләргә өметләнүче кеше Габдеррахман ибн Насыр ибн Сигъди язды.<br><br>Аллаһ аны, аның ата-анасын һәм барлык мөселманнарны ярлыкасын.<br>Төп китаптан күчереп язылды: Зөл-хиҗҗә/һиҗри1359 ел<br>Һәм барча мактау Аллаһка, Аның рәхмәте белән генә изге эшләр кылына. |

| Сорау | Дөрес | Дөрес түгел |
|---|---|---|
| — Ир-атны хатын-кыз өчен үтермиләр<br>— Опекунга сайлау мөмкинлеге бирелә: үч алу, йолым, гафу итү.<br>— Бер төркем җинаятьчене бер кеше өчен үтермиләр.<br>— Хөкем эше белән идарә итү — ул иң яхшы идарә, чөнки нәкъ менә аның аркылы хокукларны, гомернең кагылгысызлыгын яклыйлар һәм гаепләне җәзага тарталар һәм башкалар.<br>— Теләсә нинди судта дәлилләр кирәк.<br>— Безнең Шәригать«Китап әһелләре» һәм «Тәвәккәллек һәм гафу итү» арасында тора.<br>— Атеислар һәм динсезләр кан үче тагын да күбрәк үтерешләр китереп чыгарырга мөмкин, дип уйлыйлар, чөнки үтерүче башка кешене үтерсә, ә без үтерүчене үтерсәк, без ике кешене югалтабыз. Әмма безнең җавап мондый: *«Аллаһ сезнең күзләрегезне томалаган. Аллаһ Тәгалә әйтә:* **«Үч алу сезнең гомерегезне саклап калыр»**, *чөнки үтерүче, үзен җәзалап үтерәчәкләрен белә торып кеше үтерергә базмаячак. Әгәр без Зәйдне Гәмрны үтергән өчен җәзалап үтерсәк, Халид Бәкрны үтермәячәк»*, әгәр без үтерүчене исән калдырсак, үтерешләр саны артачак.<br>— Яралаган өчен үч алу төгәл яраларга мөмкин булган һәр яра өчен билгеләнгән.<br>— Әгәр үтерүче кеше нык бозык кеше буларак билгеле булса, аны җәзалап үтерү хәерлерәк.<br>— Җәза билгеләүнең файдасы бөек һәм чиксез, ул шулай ук туктатып торучы һәм чистартучы фактор да. | | |

— Пәгамбәрне яманлаучы — имансыз: нинди генә очракта да үтерелә___, тәүбәгә чакырыла__

— Хөкем эше белән идарә итүнең хөкемнәре: индивидуаль___, җәмәгать ___ бурычы.

— Дәлилләрне яшереп калдыру: тиешле түгел___, тыелган___.

— Өченче зат турында фәтва бирү ярый___ ярамый___. Өченче затны хөкем итү ярый___ ярамый___.

— Хөкем эше — ул индивидуаль___ җәмәгать___ бурычы. Әгәр бу рольгә бер генә кеше туры килсә, бу очракта аның өчен хөкем эше: индивидуаль___ җәмәгать___ бурычы, чөнки кешеләр арасында аларны хөкем итүче башка кеше юк.

— Ялган шәһәдәт: иң зур гөнаһ___, зур гөнаһ___, кече гөнаһ___.

## ЭЧТӘЛЕК


Кереш сүз ... 5
Авторның кереш сүзе ... 9
Ике шәһәдәт бүлеге ... 15
Тәһәрәт китабы ... 19
Пакьлану төрләре ... 22
Савыт-саба ... 24
Истинҗа һәм бәдрәфкә йөрү кагыйдәләре ... 26
Пычракны чистарту һәм пычрак әйберләр ... 29
Тәһәрәт шартлары ... 31
Күн оекларны һәм бәйләвечләрне сыпыру (мәсех итү) ... 33
Тәһәрәтне бозучы гамәлләр ... 35
Госелне мәҗбүри итүче гамәлләр госелнең тасвирламасы ... 36
Тәяммүм (җир ярдәмендә тәһәрәт алу) ... 37
Хәез ... 39
Тәһәрәт китабы буенча сораулар ... 41
Намаз ... 49
Намаз шартлары ... 50
Намазның тасвирламасы ... 55
Сәһү сәҗдәсе, тиләвәт һәм шөкер сәҗдәләре ... 66
Намазны бозучы гамәлләр һәм намаз эчендә үтәлмәсә яхшырак булган гамәлләр ... 68
Ихтыяри намаз ... 70
Намаз укырга тыелган вакытлар ... 72
Җәмәгать намазы һәм аны үтәү ... 76
Нигезле сәбәпләре булганнарның намазлары ... 78
Җомга намазы ... 80
Бәйрәм намазы ... 82
Намаз китабы буенча сораулар ... 84
Җеназа китабы ... 91
Җеназа китабы буенча сораулар ... 97
Зәкәт китабы ... 101
Мал-мөлкәттән зәкәт ... 103
Фитр сәдакасы (Ураза гаете зәкәте) ... 107
Зәкәт тиешле булган кешеләрнең категорияләре ... 109
Кыскача ... 112
Зәкәт китабы буенча сораулар ... 116
Ураза китабы ... 121
Кыскача ... 125
Ураза китабы буенча сораулар ... 130

Хаҗ китабы ... 135
Пәйгамбәрнең хаҗы тасвирланган Җәбир хәдисе ... 135
Хаҗ йолалары ... 145
Ихрам вакытында тыелган гамәлләр ... 146
Тәваф һәм атлап йөрү шартлары ... 149
Штраф сәбәпле, Корбан гаетендә һәм бала тугач корбан чалу ... 152
Кыскача ... 154
Хаҗ китабы буенча сораулар ... 156
Сәүдә китабы ... 163
Сәүдә шартлары ... 164
Чыганакларны һәм җимешләрне сату ... 169
Сәүдә килешүен ихтыяри рәвештә бозу ... 171
Аванс ... 172
Расланган килешүләр: залог, гарантия, ышаныч язуы ... 173
Банкротлык яки башка сәбәпләр аркасында милеккә арест салу ... 176
Якларның килешүе ... 178
Вәкаләтләү, партнерлык һәм издольщина ... 179
Эшкәртелмәгән җирләрне үзләштерү ... 182
Кешене эшкә алу һәм аренда ... 183
Табылдык һәм ташландык ... 185
Ярыш ... 187
Кеше милкен үзләштерү ... 188
Түләүсез файдалану һәм сакларга тапшыру ... 189
Милекне алуга өстенлекле хокук ... 190
Тартып алына алмый торган милек (вакф) ... 191
Хәйрия килешүләре: күчтәнәч, бүләк, васыятьнамә ... 193
Сәүдә килешүләре китабы буенча сораулар ... 195
Мирас китабы ... 201
Өлеш тиешле кешеләр ... 202
Бүленгәннән калган өлешнең (тагъсыб) Шәригатьтәге хөкеме ... 204
«Әл-гауль» (барлык варисларга да өлешләр җитмәгән вакытта өлешләрне арттыру) хөкеме ... 206
Башка хөкемнәр ... 208
Колларны азат итү ... 209
Мирас китабы буенча сораулар ... 212
Никах китабы ... 223
Никах шартлары ... 225
Никах вакытында тыелган нәрсәләр ... 227
Никах вакытында шартлар ... 229

Никах вакытындагы кимчелекләр ... 230
Никах бүләге китабы ... 233
Никах бүләге хөкеме ... 233
Ир белән хатын тормышы ... 235
Хатын таләбе буенча аерылышу (хульг) ... 237
Талак китабы ... 241
Тулы һәм өлешчә(кайтарып була торган) талак ... 243
Әл-иляъ, әз-зыхар һәмәл-лиган ... 244
Талактан соң яки ирнең үлеменнән соң көтү вакыты (гидда) һәм кол хатынның көтү вакыты (истибра) ... 249
Хатыннарны, якын туганнарны ... 252
һәм колларны тәэмин итү, шулай ук опека ... 252
Гаилә китабы буенча сораулар ... 254
Ризык китабы ... 259
Кыскача: дәвалау ... 261
Хайван чалу һәм ау ... 264
Ант һәм нәзер ... 266
Ризык китабы буенча сораулар ... 271
Җинаятьләр китабы ... 277
Җәзалар китабы ... 285
[Зина кылган өчен җәза:] ... 285
[Яла яккан өчен җәза] ... 287
[«Тагъзир»] ... 287
[Урлаган өчен җәза] ... 287
[Спиртлы эчемлекләр кулланган өчен җәза] ... 288
[Талаган өчен җәза] ... 289
[Баш күтәрүчеләргә җәза] ... 289
Мөртәтлекнең хөкеме ... 290
Хөкем эше, дәгъва, дәлилләр һәм шәһәдәт төрләре китабы ... 295
Бүлү ... 297
Гаебеңне тану ... 298